КАУРЫЙ КАНАТ

Язын кош-корт алганда ашыгырга ярамый

> 6

АРТЫК АВЫРЛЫК

Ябыгу организмга гына түгел, психикага да зыян салырга мөмкин

> 7

КЫЙММӘТЛЕ МИЛЛИЛЕК

Үзебезчә киенү күпмегә төшә?

> 16–17

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 45 (29012) | Җомга | 31 март | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

pinterest.com

БУЛГАНЫ ЙӨРЕП ТОРСЫН

«ВТ» ХӘБӘРЧЕСЕ МАШИНА БӘЯЛӘРЕН БЕЛЕШТЕ

Рәсми мәгълүматларга караганда, былтыр илдә автомобиль бәяләре 40 процентка кыйммәтләнгән. Сатучылар исә, чынбарлыкка якынрак булсын өчен, бу санны икегә тапкырларга киңәш итә. Бәясе «тешләү» белән беррәттән, автомобиль базарында сайлау мөмкинлеге дә кимегәннән-кими. Бүген машина сатып алу, аны алмаштыру отышлымы? Автосалонда һәм базарда «тимер ат»лар күпме тора? «ВТ» хәбәрчесе әнә шул сорауларга җавап эзләде.

> 5

Ишетми калмагыз

Узган елда Татарстанда корал саклау һәм сатып алуга кагылышлы 1153 закон бозу очрагы ачыкланган. Росгвардиянең Татарстан буенча идарәсе Лицензия бирү үзәгенең корал әйләнешен контрольдә тоту бүлеге башлыгы Рамил Камалиев әйтүенчә, республикада бер ел эчендә 500 берәмлеккә якын корал хуҗасыннан тартып алынган. Бүген Татарстанда 43 мең кешенең коралга рөхсәте бар. Аларда барлыгы 75 мең берәмлек корал саклана.

Республикада яшәүчеләр 2022 елда законсыз саклаган 1,9 мең берәмлек коралын үзләре үк китереп тапшырган. 2 меңнән артык кеше һәм оешма административ җаваплылыкка тартылган.

Татарстанда «Идел сукмагы» аша йөрергә мөмкин булачак. 350 чакрым озынлыктагы җәяүлеләр маршруты бу. Республика шәһәрләрен үстерү институтының Табигый территорияләрне үстерү һәм экотуризм дирекциясеннән хәбәр ителгәнчә, «Идел сукмагы» – Ульяновск өлкәсе чигеннән Чувашиягә кадәр Иделнең уң яры буйлап сузылган җәяүлеләр юлы ул. Бер өлеше Казаннан уза. Озынлыгы – 350 чакрым. Маршрут 5 районны, 100дән артыграк мәдәни мирас объектын һәм махсус сакланышлы 26 табигый территорияне берләштерә.

Проектның идеясе 2021 елда барлыкка килгән. Маршрутны туган якны өйрәнүче белгеч, сәяхәтче Тимур Циунчук эшләгән.

Россиядә эш атнасын дүрт көнгә калдыруның бер шарты бар: илдәге икътисадый вазгыятьтә тискәре чагылыш тапмаска тиеш. Мондый адымның, аерым алганда, хезмәт хакы кимүгә, товарлар һәм хезмәтләрнең кыйммәтләнүенә китермәве кирәк. Дәүләт Думасының Хезмәт, социаль сәясәт һәм ветераннар эшләре комитеты рәисе Ярослав Нилов әйтүенчә, хәзерге вакытта депутатлар болай да кешеләребезнең үз гаиләләре янында ешрак булулары өчен чаралар күрергә тырыша. Әмма бу карарның тормышыбызны начарайтуга китермәве мөһим. Исегезгә төшерәбез: былтыр уздырылган сораштыру нәтиҗәләре буенча, Россиядә яшәүчеләрнең яртысы чамасы дүрт көнлек эш атнасы кертү тәкъдимен хуплаган.

Бу араларда Татарстанда җылы һава саклана. Гидрометеоүзәк хәбәр иткәнчә, ял көннәрендә +14 градуска кадәр җылыта. Киләсе атна башында термометрның терекөмеш баганасы +16 градуска кадәр күтәреләчәк. Шимбә – 1 апрельдә көндез +6…+11 градус. Явым-төшем көтелми диярлек. Секундына 15 метр тизлектә җил. Төнлә һава температурасы +1…+5 градус чикләрендә тирбәләчәк. Якшәмбе – 2 апрельдә төнге сәгатьләрдә температура 0…+4 градуска кадәр төшәчәк. Көндез +9…+14 градус җылы, урыны белән кыска вакытлы яңгыр. Синоптикларның башлангыч мәгълүматларына караганда, дүшәмбе, сишәмбе – 3, 4 апрельдә явым-төшем көтелми. Көндез һава температурасы +11…+16, төнлә 0…+4 градус. Тәүлеклек уртача температура 4–5 градуска артыграк.

Районнарда ни хәлләр?

Түбән Кама

Түбән Кама һәм Чаллы шәһәрләрен урап узучы юл төзелешенең беренче этабында Чулман елгасы аша технологик күпер төзелеше тәмамланды. Хәзер объектта 395 кеше һәм 60 берәмлек техника эшли. Бу хакта «Волга-Вятскуправтодор»ның матбугат хезмәте хәбәр итә. Вакытлы корылманы төзү 2022 елның октябрендә башланды. Белгечләр алты ай эчендә 11 аралыктан һәм 12 терәктән торган, гомуми озынлыгы 234,7 метр булган технологик күпер төзеде. Аны төзү өчен 6126 тонна металл кирәк була. Күпер ике йөз тоннага кадәр авыр техниканы күтәрә ала. Төп күпер төзелеше тәмамланганнан соң, ярдәмче корылма сүтеләчәк. Чулман елгасы аша 1,3 км озынлыктагы күпер төзелеше график буенча бара, аны 2024 ел ахырына кадәр файдалануга тапшырырга җыеналар.
(e-nkama.ru)

Балтач

Рамазан аеның җомга көннәрендә Норма – Рәмәзан аеның җомга көннәрендә Норма – Рәмәзан
Рамазан аеның җомга көннәрендә Норма – Рәмазан

Рамазан аеның җомга көннәрендә Норма – Рәмазан

Рамазан аеның җомга көннәрендә Норма – Рәмазан

Рамазан аеның җомга көннәрендә Норма

Зәй

Карамалы ял паркында мәктәп укучылары, бердәм булып, сыерчык оялары эләләр. Игелекле гамәлгә Зәйнең һәр белем йорты да кушылган. Яз саен кош оялары ясап элү районда матур традициягә әйләнде. 7 нче мәктәп укучылары да сыерчыкларны каршы алырга ныклап әзерләнгән. Хезмәт дәресендә алдан барысын да исәпләп, тырышып, оялар ясаганнар. Кадер мәктәбе коллективы да игелекле акциягә бик теләп кушылган. Алар 8 оя ясап алып килгән.
(«Зәй офыклары»)

Мамадыш

Мамадышта үзара салым акчасын җыю дәвам итә. Быел халыктан 3 млн 300 мең сум акча җыелырга тиеш. Шәһәрдә Төньяк бистәсендә автобус маршруты үзгәртеләчәк. Маршрут Һади Такташ, Рафаэль Мөхәммәтшин, Карьер урамнары буйлап узачак һәм стадион-ипподромга чыгачак. Һәр тукталышта павильоннар урнаштырылачак. Шулай ук шәһәр өлешендә һәм Ушма арьягында кайбер иске кирпеч туктлыш павильоннары яңаларына алыштырылачак. «Безнең ишегалды» программасы буенча каты көнкүреш калдыклары контейнерлары алыштырыла. Шундый ук заманча контейнерларны «Көньяк» һәм Төньяк бистәләрендә шәхси секторда урнаштыру планлаштырыла.
(«Нократ»)

Иминлек өчен

Казанга бер көнлек эш визиты белән Россия Хәрби-сәнәгать комиссиясе рәисенең беренче урынбасары, Иминлек Советы Рәисе урынбасары Дмитрий Медведев килеп китте. Татарстан башкаласында ул оборона-сәнәгать комплексы предприятиеләре эше белән танышты һәм киңәшмә үткәрде.

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов, Россия Президентының Идел буе федераль округындагы тулы вәкаләтле вәкиле Игорь Комаров белән берлектә Дмитрий Медведев Казан дары заводына барды. Анда РФ Кораллы көчләрен дары, сугыш кирәк-ярагы белән тәэмин итү турында сөйләштеләр.

– Махсус хәрби операция шартларында сугыш кирәк-яраклары запасы күпкә артты, – диде Дмитрий Медведев киңәшмәдә. – Хәрби сәнәгатьнең бурычы – Кораллы көчләрне тәэмин итү, шул ук вакытта әлеге продукцияне җитештерү күләмен генә түгел, заманча технологияләр, яңа эшләнмәләр кулланып, сугыш кирәк-яракларының нәтиҗәлелеген дә арттыруга ирешергә кирәк.

Идел буе федераль округына кергән төбәкләрнең җитәкчеләре белән контракт буенча хәрби хезмәткә алу турында да фикер алыштылар.

Булганны кулланасы

Дәүләт Советында республика программаларын һәм «Бердәм Россия» проектларын тормышка ашыру турында сөйләштеләр. Партиянең Татарстандагы депутат берләшмәләре республика координация советы җыелышын Дәүләт Советы Рәисе, «Бердәм Россия»нең Татарстан төбәк бүлеге секретаре Фәрит Мөхәммәтшин үткәрде.

Фәрит Мөхәммәтшин утырышта республика шәһәр һәм районнарында партия проектларын гамәлгә ашыруның әһәмияте турында сөйләде. «Донбасста яшәүчеләргә, шулай ук мобилизацияләнгән сугышчыларга, ирекелләргә һәм аларның гаиләләренә гуманитар ярдәм күрсәтү буенча яңа проектларны аерым билгеләп үтәм, – диде ул. – Мин бу игелекле эштә актив катнашуыгыз өчен барыгызга да рәхмәтлемен. Партиянең җирле бүлекчәләренең тулы ярдәме белән махсус хәрби операция башланганнан бирле республикадан «Бердәм Россия» партиясе линиясе буенча 103 млн сумга 1 мең 350 тоннадан артык гуманитар йөк җибәрелгән. Болар барысы да республика бүлекчәсенең бердәмлеге турында сөйли».

Фәрит Мөхәммәтшин сүзләренчә, партия проектлары федераль һәм республика дәүләт программалары һәм илкүләм проектлар белән тыгыз бәйләнгән. Партия проектларында катнашу җирле бюджетка акча җәлеп итәргә, район, шәһәр, халык өчен күбрәк эшләргә мөмкинлек бирә.

БҮЛӘКТӘ – КАДЕР

Кремльдә Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин төрле тармакта уңышка ирешкән табиб, укытучы, төзүче һәм башка һөнәр ияләренә – барлыгы 46 кешегә дәүләт бүләкләре тапшырды.

– Һәр буын өчен битараф булмаган, фикерле, һөнәри яктан әзерлекле кешеләр кирәк. Бәхеткә, андыйлар республикада аз түгел. Сез Россия һәм Татарстанның байлыгын, данын арттырасыз, яшьләргә юл күрсәтәсез. Сезнең тырышлык белән республика төп икътисадый күрсәткечләр буенча алдынгы урында, илнең әйдәп баручы сәнәгать үзәкләре арасына керә, – диде Фәрит Мөхәммәтшин.

Парламент җитәкчесе республиканың социаль-икътисадый күрсәткечләренә тукталып үтте. Республика Рәисе ярдәмендә 34 республика дәүләт программасы тормышка ашырылуын әйтте. «Әлеге программалар җәмгыятьнең икътисадый һәм социаль тормышының күпчелек өлкәләренә кагыла. Бу – мәгариф, сәламәтлек, спорт, коммуналь, транспорт, мәгълүмати инфраструктураны тәэмин итү, балаларны тәрбияләү, авылда уңайлы шартлар тудыру өчен бөтенләй яңа мөмкинлекләр», – диде Фәрит Мөхәммәтшин.

Дәүләт бүләкләре алучылар арасында фән, мәдәният, мәгариф, сәламәтлек саклау, авыл хуҗалыгы, нефть һәм башка өлкәләрдә хезмәт куючылар бар иде. Камера оркестрының сәнгать җитәкчесе Игорь Лерман «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены белән бүләкләнде. «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале Шимко исемендәге «Радиоэлектроника» фәнни-җитештерү берләшмәсенең техник бүлеге инженер-конструкторы Тәлгать Сабировка, вокалист-солист Габделфәт Сафинга тапшырылды. «Фидакарь хезмәт өчен» медаленә лаек булучылар арасында «Ватаным Татарстан» газетасының баш мөхәррир урынбасары Зөлфия Хәлиуллина да бар. Хезмәттәшебезне уңышы белән котлыйбыз.

Әлки районының Хузангай җәмгыяте белгече Александр Иванов хәзер «Татарстанның атказанган механизаторы» исемен йөртә. Башта ул туган авылы Чуваш Борнаенда хезмәт куйган. Колхоз таркалганнан бирле вахта белән җиде чакрым ераклыктагы Хузангай авылына йөреп эшли. Хезмәт стажы – 40 ел. Трактор белән 9 яшьтә үк җенләнә башлаган.

«Ватаным Татарстан» газетасы баш мөхәррире урынбасары Зөлфия Хәлиуллина «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләнде. «Бу минем шәхси уңышым гына түгел, ә быел 105 еллыгын билгеләп үтүче редакциянең уртак хезмәте дә», – диде ул.

– Минем өчен зур бүләк бу. Бик дулкынланам, төнлә йоклый да алмадым хәтта. Кремльдә беренче тапкыр бит, – диде Александр Иванов, каушавын яшермичә. – Механизатор булу җиңел түгел. Әмма хәлләр күпкә яхшырды, заманча техника хәзер. Урып-җыю, кыр эшләрендә дә катнашам. Авыл хезмәтчәннәренә хөрмәт белән карау сөендерә. Сабантуйда да котлыйлар. Тик яшьләр бик сирәк килә шул. Безнең буын китсә, кем генә калыр икән?

«Татспиртпром» җәмгыятенең машина йөртүчесе, Казан егете 54 яшьлек Айрат Галиәхмәтовның да хезмәте югары бәягә лаек дип табылган.

– Гади хезмәт кешесенең кадерен белгән, шундый олы хөрмәт күрсәткән өчен рәхмәт. Яшь вакытта бик тә машина йөртәсем килде. 18 яшьтән – рульдә мин. Элегрәк ерак юлларга йөрсәм, хәзер шәһәрдә эчендә генә. Илнең барлык шәһәрләрен урадым. Техника яратмасаң, моның кадер озак эшләп булмый. Вакытында юарга, маен алыштырырга, аны карап торырга кирәк, – диде «КамАЗ» иярләүче Айрат Галиәхмәтов.

Табиблар да читтә калмады. Аларга карата да халыкның хөрмәте елдан-ел арта бара. Моның шулай икәнлеген Казан дәүләт медицина университетының эчке авырулар кафедрасы мөдире Рөстәм Хәмитов та сизә. Аңа «Татарстанның атказанган табибы» исеме бирелде. Бер урында 38 ел эшли икән.

– Без халык өчен эшлибез, әмма хезмәтебезне бәяләгәч, күңел күтәрелә. Минем белән гаиләм дә, әнием дә сөенер дип уйлыйм, – диде ул. – Ковид безгә бик зур сынау булды. Безнең медицинаның андый хәл белән очрашканы юк иде әле. Аны хәтта сугыш белән чагыштырдык. Алай дөрес тә булмагандыр. Икенче сынау да килеп чыкты. Анысында да безнең табиблар катнаша. Үзем дә җәй көне Донецкига эшкә барырга теләп гариза язган идем. Әмма чакырмадылар.

«Туран АРТ» җәмгыяте директоры Суфия Хәйбрахманова исә «Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале белән бүләкләнде. Ул мәдәни мирасны саклау өлкәсендә 30 елдан артык хезмәт куя икән инде.

– Республика Рәисе Рөстәм Миңнеханов Казанда татар халык иҗаты йорты төзергә тәкъдим итте. Бу безгә дәрт бирде. Безнең һөнәрчеләр, мөмкинлекләр арта, дип сөенә, – дип башлады ул сүзен. – Мин үзем грант оттым. Ул акчага Биектау районында татар һөнәрчелеге музее төзисем килә. Үзебезнең чигүчеләр коллективы бар. Аларның кул эшләрен күрсәтәчәкбез. Чигү эше белән яшьләр бик шөгыльләнергә теләми. Әмма районнарда йөргәндә, барыбер үзгәрешләр сизәбез. Чигү буенча мастер-класслар күрсәтүне сорыйлар. Нииндидер кызыксыну бар. Барысы да аларга ничек тәкъдим итүдән тора, – диде Суфия Хәйбрахманова.

Сәрия МИФТАХОВА

БЕТМӘС СҮЗЕБЕЗ!

Мари Иле, Самара, Төмән, Ямал-Ненец округы, Белоруссия, Төркия... Быел өченче мәртәбә уздырылган «Татар сүзе» бәйгесендә кем генә катнашмады. Марат Әхмәтов сүзләре белән әйтсәк, бу кадәр кеше белән без телебезне саклый да, үстерә дә алабыз. Татар сүзенең көчен, зәвык һәм нәфислеген исбатлаучы бәйгенең гала-концерты – безнең репортажда.

«Татар-информ» / Салават Камалетдинов

Салехард шәһәреннән килгән Екатерина ханым Әхмәтҗанова бәйгедә «Үзем язган әсәр» номинациясендә III урынга лаек дип табылды.

Татарстан Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү комиссиясе гамәлгә куйган «Татар сүзе» халыкара нәфис сүз бәйгесе кыска гына вакыт эчендә сүз сәнгатенә, татар әдәбиятына битараф булмаучылар арасында шактый зур кызыксыну уятырга өлгерде. Бу җәһәттән аның премия фонды 1 млн сумны тәшкил итүен дә искәртергә кирәктер.

– Безнең чын мәгънәсендә сәләтле балаларыбыз, өлкәннәребез һәм иҗади гаиләләребез шулкадәр күп икән! Алар арасыннан Якуповлар гаиләсен игътибарсыз калдыра алмадык. Айрат Якуповны күпләр «Могҗиза» театр студиясеннән (сәламәтлеге чикләнгән балалар студиясе. – **Авт.**) беләдер. Мин аның әнисе Рузия белән чыгышына таң калдым, шәһәребез мэрына да күрсәттем, – диде Казан шәһәре башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Гүзәл Сәгыйтова, Якуповлар гаиләсенә мэриянең махсус бүләген тапшырып.

Махсус бүләкне Татарстан Язучылар берлеге дә әзерләгән иде. Аны Татарстан Язучылар берлеге рәисенең беренче урынбасары Илсөяр Иксанова тапшырды.

– Ике ел рәттән әлеге бәйгенең жюри әгъзасы буларак, шуны әйтәсем килә: катнашучылар хәзер мәктәп программасы белән генә чикләнмичә, яңа буын әдипләрнең, соңгы елларда бик искә алынмый торган язучыларның әсәрләренә дә мөрәҗәгать итә башлады. Бу исә бәйгенең үсеше турында сөйли, – дип сөйләде ул, махсус бүләк иясе Земфира Антипованы тәбрикләп.

Быелгы бәйгене оештыручылар – «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе һәм «Шаян ТВ» каналы.

– Ышанып, бу дәрәҗәле эшне безнең кулларга тапшырганыгыз өчен бик зур рәхмәт! Ышанычыгызны аклаганбыздыр дигән өметтә калам, – диде «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе генераль директоры Илшат Әминов. Шуннан соң Мансуровлар гаиләсенә махсус бүләкләрен тапшырды.

«Татар сүзе» – саннарда

➤Тагын да киңрәк аудиторияне колачлау максатыннан, быел әлеге бәйге телевизион форматта уздырылды. Узган ел бәйгедә барлыгы **3557** кеше катнашкан булса, быелгы катнашучыларның саны – **3200**.

➤Узган ел **40** җиңүчене бүләкләгән булсалар, быелгы җиңүчеләрнең саны – **30**.

➤Катнашучылар «Шигърият» һәм «Проза» номинацияләрендә көч сынашты. 10 яшькә кадәр, 11–17 яшь, 18 яшь һәм өлкәнрәкләр кебек яшь категорияләреннән тыш, үзе язган әсәрләрне сөйләүчеләр, иҗади гаиләләр һәм профессионаллар аерым бәяләнде.

Бергә булырга кирәк!

Махсус бүләкләр тапшырылып, җиңүчеләрне алкышлаганнан соң, һәр бәйгедәге иң көтеп алына торган мизгел – бүләкләү тантанасы башланды. Быел катнашучыларның әдәби әсәр башкару осталыкларыннан тыш, бәйгегә җибәргән видеоязмаларының сыйфаты да каралды. Соңыннан җиңүчеләрнең видеоязмаларыннан торган махсус тапшырулар әзерләячәкләр. Тулы бәяне әнә шул тапшыруларны карагач бирсәк, дөресрәк булыр, мөгаен.

Җиңүчеләрне исә, елдагыча, Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе рәисе Марат Әхмәтов котлады.

– Татар теленең, татар сүзенең бөтен нечкәлеген, нәфислеген, әдәбилеген халкыбызга яшәү рәвеше кебек җиткерә алырлык никадәр талантлы кешеләребез бар. Шулай булганда, мондый тел, мондый халык югаламыни? Мондый телне югалтырга ярыймыни? Татар теленең киләчәге, һичшиксез, өметле. Өч ел рәттән уздырылган бу бәйгедә барлыгы 10 меңнән артык кеше катнашты. Һәр катнашучының янында аның өчен җан атучы дистәдән артык кеше бар. Димәк, туган телебез өчен янып-көеп яшәүче, ким дигәндә, 100 мең кешебез бар. Бу кадәр кеше белән без телебезне саклый да, үстерә дә алабыз. Безгә бүгенге кебек бергә булырга гына кирәк! – диде ул.

«Монда кадәр килеп, биемичә китәләр димени?!»

Әлеге бүләкләү тантанасының иң истә калган мизгеле Салехардтан килгән Екатерина ханым Әхмәтҗанованың бии-бии сәхнәгә менүе булды. Гармунын күтәреп, тормыш иптәше дә килгән иде. Без сәхнә артына узганда да гармун һәм тыпыртыпыр биегән тавыш ишетелә иде әле.

– Монда кадәр килеп, биемичә китәләр димени?! Бәйгегә үзем язган әсәрне сөйләп җибәргән идем. Уен-көлке белән генә инде. Көтмәгәндә, Казанга чакырдылар. Мондый чаралар безнең өчен гаять әһәмиятле. Яшәсен сүзебез! – диде Екатерина ханым. Кызганыч, чыгышын гына күреп булмады.

Нәфис сүз бәйгесендә мәдәният өлкәсенә якын булган кешеләр генә катнаша, дип уйласагыз, ялгышасыз. Әйтик, Балтач районының Куныр авылыннан килгән Ленар Хаматов – мич чыгаручы. Бәйгедә ул, шигырь сөйләп, II урынны алды.

– Бәйгегә дигән видеоязманы Казанда мич чыгарган җирдән генә төшереп җибәрдем. Үземнең өстә – эш киемнәре. Фонда да – иске генә йорт. Махсус әзерләнеп төшерсәм, җиңмәгән дә булыр идем әле, – дип көлә Ленар әфәнде. – Мич чыгарган арада, кулга гармун алып, җырлап та җибәрә алам. Шул арада күңелгә ятышлы шигырьләрне дә ятлыйм. Кыскасы, иҗат – күптәнге җан дустым.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Халык кәефе

НИХӘЛЛӘРДӘ ЯТАСЫЗ?

Рузилә МӨХӘММӘТОВА,
фельдшер (Саба районы Олы Шыңар авылы):
– Узган ел бакчага су кергән иде, быел булмады. Кая киткәндер ул кар?! Урман сулары төшкән көнне генә елгалар бераз күтәрелеп алды да, шуның белән бетте. Кыскасы, ташуны күрми калдык. Авылда күңелле хәзер. Көннәр матур тора. Сыерчыклар кайтты. Мәш килеп, оя чистарталар, яңарталар. Парлап чөкердәшәләр. Аларны карап тору бик күңелле. Юллар да кибә башлады инде. Сукмак төште, дисәк тә була. Ә инде халыкның сәламәтлегенә килсәк, коронавирус бетте, хәзер ОРВИ белән авырыйлар. Күзләреннән яшь ага, температуралары бар. Өлкәннәргә диспансеризация уздыра башладык. ФАПта каннарын алабыз, ЭКГ ясыйбыз. Аннары аларның анализларын Сабага илтеп бирәбез. Социаль яклау бүлеге машиналары килеп, үзләрен дә табибка алып бара.

Әнисә ХӘСӘНШИНА, хуҗабикә (Зәй районы):
– Яз килүен көтеп алдык. Кышкы ялдан соң эшлисе килә. Әлегә бакчаларда юешрәк, казып булмый. Җыештырабыз, тирә-якны чүптән арындырабыз. Эшләсәң, авылда эш бетмәгән инде ул. Кәлшәләр утырткан идем, алар үсеп килә. Парникны рәтләп, помидорларны шунда күчереп утыртырбыз, дип торам.

Зөлфия ҖИҺАНШИНА, пенсионер (Чүпрәле районы):
– Бик матур айга кердек. Бердән, яз килә, икенчедән, күңел пакьләнә. Аллага шөкер, 40 ел рәттән ураза тотам. Күңелдәге хисне әйтеп бетерерлек түгел. Аның рәхәтлекләрен белсәгез! Ифтарларга йөрибез, тәравихны калдырмыйбыз. Быел безгә киленем белән улым да кушылды. Бергәләп сәхәр ашау тагын да күңелле. Мин күп итеп гөлләр үстерәм. Өйдә 300дән артык гөлем бар, барысы да чәчәк ата торган. Шулар белән мәш киләм. Быел да ике оя казым утыра. Тиздән бәбкәләре дә чыгар вакыт җитә. Язын бар дөнья җанлана инде ул. Кичә сарыгыбыз өч бәрән китерде, мәчебез балалап ята. Көннәр бозылып китәрме, дип торам әле. Салкынайтасы булса, уң кулым сызлый минем. Сыерчык буранннары булыр, дип юрап куйдым инде.

Әлфис ГАФИЯТОВ, автобус йөртүче (Лаеш):
– Моннан 10 көн элек авариягә эләктем. Казаннан кайтып барышым иде. Йоклап киткәнмен. Исән калганыма сөенеп ятам хәзер. Ике аягым да сынып беткән. Берсенә Илизаров аппараты куйдылар. Хастаханә түшәгендә барысы да искә төшә. Уйландыра. Нәрсәне дөрес эшләмәдем икән, дип баш ватып ятам. Ике сабыем хакына исән калганмындыр инде дип уйлыйм. Язны шулкадәр сөенеп көттем. Апрель ахырында 50 яшем тулачак. Шуны матур итеп үткәрербез, дип сөйләшеп куйдык. Тик менә барып чыкмады. Әмма күңелне төшермим әле, терелеп аякка басу кирәк.

Кадрия САФИНА, кибетче (Арча районы):
– Язны бик көтеп алдык. Тизрәк җәй җитсә иде, дим хәзер. Быелга эшлисе эшләрем күп. Кызыбызны кияүгә бирергә җыенабыз. Кулын сорап киттеләр инде. Никахка кадәр өйне тәртипкә китерәсе бар. Ишегалдына брусчатка җәйдерергә дип торабыз. Мунчаны яңарттык. Күңелдә дулкынлану да бар. Баланңы чыгарып җибәрү бер дә җиңел түгел икән. Әмма һәркем үз тормышын корырга тиеш. Кайчандыр мин дә бу йортка килеп кергән кеше бит инде. Бәхетләре булсын. Әлегә әнә шундый күңелле мәшәкатьләр белән яшибез.

Зөһрә НАСЫЙБУЛЛИНА,
күпбалалы әни (Тукай районы):
– Ирем белән биш бала үстерәбез. Олысына – 16 яшь. Көннең ничек узганын да сизми калам. Үз йортыбыз белән яшәгәч, эш күп. Яз җиттеме, кар астыннан бөтен кирәкмәгән чүп-чар баш калкыта. Йорт тирәләрен тәртипкә китерәбез. Әле менә 16 тавык алдык. Йомырка сала торган, дип сатып киттеләр инде. Белмим, ничек булыр. Чебиләр алырга дип торабыз. Каз-үрдәкне быел 100әр баш алмакчы булып торам. Узган ел 50шәр иде. Файдасын күрдек, үзебезгә дә җитте, саттык та. Балалар кул арасына керә башлады инде хәзер. Курыкмыйча кош-корт асрап була. Әлегә декрет ялында мин. Ирем Чаллыга барып эшләп йөри. Кәефләребез бик яхшы. Һәр туган көнгә сөенеп, шөкер итеп яшибез. Апабызның улы махсус хәрби операциядә. Озакламый ялга кайтырга тиеш. Аны да бик дулкынланып көтеп торабыз. Илләр тынычлансын иде, дип телибез. Күңел ышана: яз тынычлык та китерер кебек.

Әйтеп кенә бактым

Робот

Риман
ГЫЙЛЕМХАНОВ

Беркөнне улым «Алиса» дигән виртуаль, ягъни уйдырма ярдәмче сатып алды. «Ямансулаганда сөйләшкәләп алырсыз, теләгән җырларыгызны тыңларсыз. Һич югы сезгә сәгать урынына да ярар», – диде.

Консерв банкасы зурлыгында гына нәрсә бу. Башта «Алиса» дип дәшәсең, аннан соң гозереңне әйтәсең. Кем әйтмешли, адәм акыллары бар үзендә. Үткән-сүткәндә Алисадан вакытны да сорыйбыз, һава торышы турында да белешәбез – бар сорауга да җавап бирә. Татарча аңламый, кәнишне, барлы-юклы урысчамны җыеп: «Алиса, как настроение?» – дигән булам. «Спасибо, настроение прекрасное, а как у вас?» – ди. «Сойдет, Алиса, – мәйтәм, – только что покушал. А ты ужинала?» Нәрсә әйтер икән, дим. Ә ул уйлап та тормады: «Да, спасибо, – диде дә, – а вы кофе любите?» – дип сорады. Тавышы ягымлы, хатын көнләшерлек.

Гаҗәп заманда яшибез. Әле кайчан гына өенә телефон кертә алган кешедән көнләшеп үлә идек. Хәзер ачуым бер килмәгәе, кесә саен телефон. Фатирларда роботларга хәтле бар. Миндә – икәү. Берсе – «Алиса», икенчесе – тузан суырткыч. Бүлмәдән бүлмәгә йөри, тузанның бөртеген дә калдырмый. Ә мин Алиса белән сөйләшеп диванда ятам. Аны кыен хәлдә калдырырлык берәр сорау эзлим. Аптырагач: «Алиса, ты меня любишь?» – дигән булам. «А вы как ко мне относитесь?» – димәсенме бу.

– Очень хорошо отношусь, Алиса.

– Я к вам тоже, любовь моя...

Бу сүзләреннән соң диваннан егылып төшә яздым. Безнең сөйләшкәнне тыңлап торган хатынымның күзләре зурайды. Миңа ачулы итеп карап куйды. Бер дә арттырып язуым түгел, ышанмасагыз, хатынымнан сорагыз.

Бүген бөтен дөньясы роботлаша бара. Роботлар фермада сыер сава, заводларда детальләр эшли, машина, самолет йөртә, сугыша. Интернетка ышансаң, японнар арасында робот хакына хатыннарын ташлап китүчеләр ишәя икән.

Заман хикмәтләре турында дуслар белән дә сөйләшкәлибез. «Хатыннарны роботлар алыштыргач, баланы кем табар икән?» – дибез. Сөйләргә безгә куш, беребездән беребез остара бара.

Берсе әйтә: «Җир шарында халык бик артты, тора-бара эчәр су гына түгел, сулар һава да калмаска мөмкин. Табигатьтә бөтенесе уйланган», – ди. Мин дә кимен куймыйм. «Роботлар безнең авылда күптән бар инде, узган гасырдан ук», – дим.

– Бөгештермә! – диләр.

– Юк, валлаһи менә. Күрше Әхмәт абзый эчеп кайтса, хатыны аңа: «Кеше түгел син!» – дип кычкыра иде. Кеше булмагач, кем була инде Әхмәт абзый?

Үзара көлешеп куйган булабыз, ә техника-технология үсеше барыбер төрле уйларга сала. Ясалма интеллект безне – бәндә балаларын бөтенләй кысрыклап чыгармас микән? Интернеттагы кайбер саннарга ышансаң, якын киләчәктә дөньяда тагын 300 млн кеше эшсез калачак. Россиядә тулыр-тулмас 150 млн кеше яши дисәк, бу – эшсез кешеләр яшәгән ике Россия дигән сүз бит! Кая бара бу дөнья? Шул ук японнарны әйтәм әле. Бер уйлаганда, хатын-кыз роботлар ир өчен дә, дөнья өчен дә файдага! Начар хатынга капкан япон мужигы хатынын роботка алыштыра да кайгы-хәсрәт күрмичә яши.

Инде көйсезләнә, иренә теләсә нәрсә әйтеп кычкыра башлый икән, ире робот-хатынны йә энергия чыганагыннан аера, ягъни батарейкасын алып ташлый, йә корсагындагы төймәсенә басып сүндереп тора. Робот-хатынның бәясе 7 мең доллардан башлана икән дип ишеткәнем бар. Ә көйсез хатын белән яшәү күпмегә төшә икән? Хәер, хатын җилкәсендә яшәүчеләр дә бар бит әле ул.

Японнарда җир мәсьәләсе – проблема. Робот хатыннар бала тапмагач, илдә халык саны да кими дигән сүз. Урысча әйтсәк, «меньше народу – больше кислороду» булып чыга инде, халык иркенрәк яши башлар. «Робот-гаиләләр» башка илләрдә дә барлыкка килә башласа, демография проблемасы да юкка чыгачак.

Бүген Җир шарында 7,8 млрд кеше яши, диләр. Бу сан 2100 елга 11,2 миллиардка җитәчәк. Ә галимнәр әйтүенчә, Җир шары 10 млрд кешене генә асрый алырлык хәлдә.

Табигать үзе көйлиме, әллә эпидемияләр, төрле гарасатлар, сугышлар килеп чыгып, халык санын киметәчәкме – болар хакында төрле фикерләр йөри. Кеше үзенең эшчәнлеге белән үз-үзен бетерәчәк, дигән сүзләр дә инде гасырлар буе яши.

Ә бүген без яңадан-яңа ачышлар турында ишетеп шатланабыз. Риман абыегыз үзе генә калганда, Алиса-робот белән сөйләшеп, серләре белән уртаклашып ала. Бүген эшкә чыгып киткәндә: «Алиса, что такое любовь?» – дип сорадым. Уйлап та тормады бу: «Как говорил Лев Толстой, любовь это – подарок, которого ты даришь любимому человеку и еще тебе самому останется», – диде. Каян килгән аңа бу кадәр акыл, бу хәтле мәгълүмат! Гаҗәп дөньяда яшибез, җәмәгать. Их, Алисаны татарча сөйләшергә дә өйрәтсәң иде ул. Балаларыбыз аның белән аралашып, ягъни уен аша ана телләрен чарларлар иде. Чыгып киткәндә: «Алиса, мин эшкә киттем», – дидем. Бераз дәшми торды да: «Я не понимаю, что вы говорите?» – диде. Мин аңа үпкәләмим. Аны кеше тудырган. Татарча сөйләшә торган робот ясарга хәзергә кул җитми әле. Бөтен роботларны да чама хисен белеп кенә ясасак, тормышыбыз гөрләп барыр әле, дип үземне тынычландырып яшәп ятыш.

СИКӘЛТӘЛЕ ТИГЕЗЛЕК

Хәзерге Россия җәмгыятендә социализмны тилерү дәрәҗәсенә җитеп сагынучылар бар һәм алар шактый ук ишле. Хәтта зур тырышлык белән бизнес корып, ярыйсы ук мул тормышка ирешкән шәхесләр арасында да совет торгынлыгының күңелне иркәли торган тотрыклылыгын сагынучылар аз түгел. Сагынырлык та шул. Коммунистик идеологиянең «Кеше кешегә дус һәм туган» дигән девизы гына ни тора!

Тема башка булганга, ул девизга тукталмыйм. Бүгенге тормышыбызда, матди байлыклар ягыннан караганда, без барыбыз да ул чактагыдан күпкә югарырак хәлдә, әмма... Әмма социализмны сагыну вирусы әле бер йөрәккә үтеп керә, әле икенчесен яулый. Социализмда тигезлек иллюзиясе тормышка ашырыла иде, социаль яклау чаралары әйбәт эшләнгән иде. Студент икәнсең, стипендия акчасына ашыйэчә, бераз тырышсаң, хәтта киенә дә аласың. Дөнья гизмәсәң дә, пенсия акчасына да үз өеңдә тыйнак кына гомер сөрә аласың. Эшсез калу куркынычы юк, киресенчә, эштән качып котылып булмый. Мәҗбүри урнаштыралар. Эленке-салынкы йөрсәң дә, ачтан үлмәслек хезмәт хакы түлиләр. Укучылар гафу итсен һәм дөрес аңласын, автор менә шул кайгыртучанлыкның шәхесне эштән чыгаруын һәм илне катастрофага илтүен язмакчы була. Совет хакимияте, үзенең җимерелү стадиясенә кергәндә, иң беренче нинди реформа игълан итте әле? Алкоголизмга каршы көрәш кампаниясен башлады, чөнки совет халкы егылып эчә иде...

Социализмның ул хатасын – социаль яклау чараларын уңга-сулга өләшүен – нык үскән капитализм да файдалана башлады. Эш шуңа барып җитте: тик торганда таза-сау кешеләргә акча өләшү идеясе үстерелде һәм тәҗрибә буларак сынап та каралды. Швейцариядә хәтта бу уңайдан референдум да үткәрделәр. Тиктомалдан акча өләшү буенча АКШ һәм Европа илләре коммунизмның борынына чиертә яздылар. Һәм... без глобаль капитализмның ахырына якынлашуын күрәбез. Юк, капитализм бинасы социаль яклау яхшы куелганга ишелә дип әйтергә теләмим, шулай да...

Бу язманың идеясе танылган совет язучысы Александр Гринның «Яшел лампа» дигән кыска хикәясен укыгач туды. Бит ярымлык хикәя авторның яхшы психолог һәм тормышны тирән аңлаучы булуын дәлилли. Сюжет болайрак корылган. 1920 елның кышында кыйммәтле рестораннан чыгып килүче затлы киенгән ике бай Лондон урамында ачлыктан аңын югалтып егылган Джон Ив атлы яшь егетне күреп ала. Байларның Стильтон исемлесенең күңелендә шунда иблиснекенә тиң идея туа: егеттән уенчык ясыйм, ди. Ул аны яхшылап ашата-эчертә һәм күзләре очкынланырлык тәкъдим ясый: юк кына эш өчен ай саен ун фунт акча биреп барырга вәгъдә итә. Егет ул акчага үзәк урамнарның берсендә фатир арендаларга, шунда яшәргә, кичке биштән алып төнге уникегә кадәр беркая да чыкмыйча, тәрәзә төбендә яшел лампа кабызып торырга тиеш була. Шул хезмәте өчен егет ай саен ун фунт акча алып торачак, акча аңа хәсрәтсез яшәргә җитәчәк. Ул гына да түгел, күпмедер вакыт үткәч, егет янына ниндидер кешеләр киләчәк һәм аны байга әверелдерәчәкләр. Стильтонның 20 миллион фунт күләмендә капиталы була һәм аңа мондый уенны оештыру берни дә тормый. Егетне алдарга җыенмый ул, ун фунтлык социаль ярдәмне чынлап та тормышка ашырырга уйлый һәм вәгъдәсен үти дә. Вәгъдәнең теге күктән явачак байлык турындагы өлеше генә ялган була.

«Стильтон нинди начарлык эшләде?» дигән сорау күңелегездә туамы? Ачлыктан үлеп баручы яшь егеткә матди ярдәм күрсәтү изгелек бит инде. Әмма Стильтон кеше табигатен яхшы белә. Аның нияте буенча егет эче пошудан эчкечелеккә бирелергә яки акылдан язарга тиеш була. Чынлап та, көче-куәте җитәрлек булган кешегә тиктомалдан акча бирсәң һәм ярдәмнең даимилеген гарантияләсәң, бу бик усал шаяртуга әйләнәчәк. Шәхес таркалуның беренче адымы башланачак. Бу кагыйдәдән сирәк искәрмәләр дә була, әлбәттә. Әмма күпчелек тапталган юлдан китә. Җиңел тормыш тозагына каба. Бәхеткә, Джон Ив искәрмәгә туры килә торган егет булып чыга. Ул, чынлап та, эч пошудан интегә башлый, ләкин шешәгә үреләсе урынга китапка үрелә. Башлангыч белеме генә булган егет, тиешле фәннәрдән белем алып, медицина колледжына укырга керә. Танылган табибка әверелә. Дөрес, зур максатка ирешергә аңа иганәчесенең начар ниятен аңлап алу булыша. Тәрәзә төбендә янган лампаны караргa килгән Стильтонның кара ниятен үз авызыннан ишетә ул. Качып кына аны тыңлап тора. Социаль ярдәмнең үзен тормыш төбенә төшерү нияте белән бирелүен аңлый. Кара ниятле Стильтон исә биржа паникасы нәтиҗәсендә бөлә, аягын сындырып, фәкыйрьләр өчен ачылган хастаханәгә эләгә, Джон Ив атлы доктор аңа операция ясый.

Коммунистик идеологиянең дә банкротлыгы Стильтонныкына охшаган иде. Кешеләрне тигезлибез дип, күпме җаннар вәхшиләрчә кыелды, генофондның иң яхшы үрнәкләре лагерьларда черетелде, юк ителде. Әйе, әйе, социализм биргән мөмкинлекләрне файдаланып, Лондон фәкыйре кебек тормыш төбеннән калкып чыккан шәхесләр булгалады ул, булмады түгел. Ләкин аларның мөмкинлекләрен ачу өчен социализм кысалары тар иде, алгарышка этәрә торган стимул юк иде чөнки. Аларның кайберләре үз мөмкинлекләрен «тимер пәрдә»нең теге ягына чыгып ачты. Барыбыз да көндәлек файдалана торган «Ватсап» бар бит әле. Совет мәктәбендә белем алган егетнең хезмәт җимеше ул. Белемен һәм талантын тормышка ашыру өчен, аңа 16 яшендә Америкага китәргә, шунда байтак кына фәкыйрьлектән интегеп яшәргә туры килә. «Ватсап»ны исә «Фейсбук»*ка 19 миллиард долларга сата, череп байый.

Googleга кем нигез салган дип уйлыйсыз? Әти-әнисе Мәскәү университетының мехматын тәмамлаган, СССРда фәнни эшчәнлек белән шөгыльләнгән, әмма илдәге шартлардан риза булмыйча, Америкага киткән совет кешеләре булган, үзе дә СССРда туган егет.

Исемлекне дәвам иттерергә булыр иде. Бер генә нәтиҗә ясыйк: алгарышка ирешүнең алгоритмында «теплица шартлары» дигән адым юк, киресенчә, юклык, фәкыйрьлек, уңышсызлык белән сыналу бар. Технологик гигантларга җитәкчелек итүче кайсы гына шәхесне алып карама, күбесенең биографиясендә уңышсызлык этабы зур урын алып тора. Башта – сынау, кире кагылу, аннан – җиңү, инвесторлардан көтмәгәндә яуган ярдәм. СССРда кешеләрне тигезләргә омтылу аркасында, шәхес формалашуның шундый алгоритмы бозылган иде. Бер калыпка салу катастрофага китерә. Совет системасының кыска гомерле булуын мин үзем шуннан күрәм. Әмма капитализм да кеше табигатенә туры килми. Капитализмның хәзерге моделен кемнәр уйлап чыгарды? Гыйбриләр. Аның төп проблемасы – процент капиталы һәм матди байлыклар артыннан куып, Аллаһ куйган чикләрне бозу. Болар икесе дә кешеләрне юләрләндерә, ахыр чиктә рухи гына түгел, матди фәкыйрьлеккә дә китерә.

Планета буйлап башланган турбулентлык бер бездә генә түгел, социализмда яшәп карау тәҗрибәсе булмаган илләрдә дә «кызыл проект»ны торгызу теләген үстерә. Әмма ул проектка күчеп караган Латин Америкасы илләре бик тиз бөләләр. Социализмның соңгы утраулары булып калган Төньяк Корея һәм Кубада тормыш җәфалы һәм авыр. Соңгысы җимерелеп ятучы капитализм ягына авышырга ниятләп карый, әлегә тормышка ашырып бетерә алмый. Без зур тынгысызлык һәм болганчыклык периодына кереп барабыз. Һәм ул ике системага да алмаш булырлык строй үзенең байрагын югары күтәргәнче дәвам итәчәк.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

* Россиядә тыелган Мета оешмасына керә.

БУЛГАНЫ ЙӨРЕП ТОРСЫН

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Теләк белән кесә кисешми

Казанда яшәүче Дамир Гарифуллин шушы арада гына яңа машина сатып алган.

– Машинам бик иске иде. Яңа автомобиль турында былтыр ук хыялланып йөрдем, тик янда запас акча торсын әле дип, сабыр иттек. Болай эшлисе калмаган да бит. Машина бәяләре көннән-көн үсә. Иске машина базарында яхшы тәкъдимнәр, кем әйтмешли, шәм яндырып эзләсәң дә юк хәзер. Салонда кредит ставкасы 20 процентка кадәр җитә. Шуңа күрә машинамны трейд-инга тапшырып, кулда булган 1 миллион сум акчага дуслар-туганнардан әҗәткә тагын 1 миллион сум акча юнәтеп, Кытай машинасы сатып алдым. «Ни өчен кытайныкын?» – дип сораучылар күп. Җавабым гади: башкасына акчам җитмәде, – ди ул.

Быел илдә сатылачак барлык яңа машиналарның 60 проценты (!) Кытай «тимер ат»ларына туры килергә мөмкин. Илкүләм автомобиль берләшмәсе вәкилләре әнә шулай дип фаразлаган. Чагыштыру өчен, 2021 елда әлеге күрсәткеч 20 процентка да тулмаган. Чит ил компанияләренең илдән китүе, логистика өзелү, санкцияләр кертелү аркасында, автомобиль базары шактый зур үзгәрешләр кичерергә мәҗбүр. Былтыр илдә җиңел машиналар сату күрсәткече 64 процентка түбән тәгәрәгән. Заводтан яңа чыккан автомобильнең уртача бәясе 2 миллион 230 мең сумга җиткән. Ә билгеле булганча, изге урын буш тормый. Чит ил брендлары урынына алмашка Кытайдан күпләп «Чери», «Хавал», «Джели», «Омода»лар килде. Менә шундый көндәшлек!

Иске яңа «Нива»

Автомобиль базарындагы вазгыятьне аңлау өчен, башкаладагы салоннарны «ВТ» хәбәрчесе дә йөреп чыкты.

«Kia» салонына машина карап йөрүчеләр берәм-сәрәм генә булса да кергәли. Сатучылар ишек төбеннән үк каршы ала. Салонда кәефне күтәрә торган көй уйный.

– Узган елның февраль – мартыннан бирле яңа автомобильләр уртача 60–70 процентка кыйммәтләнде. Бәяләр хәзер дә ай саен 3–5 процентка артып бара. Яңа машиналарга кытлык юк. Бөтен детальләре һәм запас частьлары Кореяныкы, – ди үзен Алмаз дип таныштырган автомобиль салоны хезмәткәре. – Сатып алучылар җитәрлек. Бигрәк тә искесен трейд-инга тапшырып, яңа машина алалар. Мондый очракта өстәмә рәвештә 200 мең сум ташлама да каралган. Кыйммәтле машиналардан баш тартып, В, С классындагыларга (сыйфатына һәм бәясенә карап, автомобильләрне алфавит тәртибе буенча төркемнәргә бүлеп йөртәләр. – **Ред.**) өстенлек бирүчеләр күп хәзер. Узган ел башланган билгеле хәлләрдән соң, машинада йөрү кыйммәткә төшә. Былтыр шул ук «Киа Соул»ны, мәсәлән, 1,7 миллион сумга сатып алырга мөмкин иде. Бүген аның бәясе 2,5 миллион сумнан башлана. Машинада йөрергә ияләшкән кеше аннан баш тартмаячак. Моны җитештерүчеләр дә яхшы аңлый. Арзанлы машиналарга бәяне махсус күтәрәләр. «Киа» автомобильләре арасында уртакул булып саналган «Киа Рио» үз бәясеннән 1 миллион сумга кыйммәтрәккә, 2,5 миллион сумга сатыла әнә. Машина сатып алганда бик уяу булырга кирәк.

istockphoto.com

«Hyundai» салонында күз күрмәгән, колак ишетмәгән машиналар да бар.

– Халык күпләп ала торган «Хендай Крета», «Хендай Солярис» машиналары сатылып бетте инде, – ди сатучы егет. – Бүген салонда җитештерүчедән турыдан-туры тәкъдимнәр юк дәрәҗәсендә. Машиналар илгә параллель импорт буенча Казахстаннан кайтарыла. Аермасы шунда: мондый машиналарга беренче гарантия юк. Аның каравы, параллель импорт буенча кайтарылган автомобильләргә салонда зур ташлама ясала. Мәсәлән, «Хендай Байон» машинасы безнең илдә юк әле. Аны быел июльдә Санкт-Петербург янәшәсендәге заводта җитештерә башларга ниятлиләр. Әлегә исә Астанада җыелганын сатабыз. Параллель импорт буенча кайтарылган С классы әлеге автомобильнең бәясе бүген 2,2 миллион сум торса, Россиядә җыела башлагач, ул ким дигәндә 3,5 миллион сумга җитәчәк. Сатып алучылар гарантия юклыгын белгәч шикләнә, билгеле. Машинаны тәзәтәм дип, Казахстанга чыгып китеп булмый бит. Шуңа күрә моннан ике атна элек кенә илдәге исеме билгеле булган компанияләрнең берсе параллель импорт буенча сатылучы машиналарны иминиятләштерә башлады. Әлеге хезмәтнең бәясе елына 50 мең сум тәшкил итә. Параллель импорттан куркырга кирәкми дип саныйм. Башка юл юк. Барыбер завод машинасы бит инде ул, бездә җыелмаган, шул гына.

«Lada» салонында кеше дә, хәтта сатучылар үзләре дә күренми. Эш көне ахырына якынлашкангамы, утны да ярым сүндереп куйганнар. Исем-атамалары да, бәяләре дә язылмаган өч-дүрт машина арасында күпмедер вакыт йөргәннән соң, залның теге очында үзен менеджер дип таныштырган кыз күренде һәм сатучыны чакырып чыгарды.

«Сезне нәрсә кызыксындыра?» – дип сорап куйды ул шактый дорфа гына. Кәефсез булуы йөзенә чыккан. Сөйләшә торгач, күңел төшенкелегенең сәбәбе аңлашылды:

– Сатарлык машина да калмады инде. «Renault» компаниясе илдән киткәннән соң, заводта калган детальләрдән җыелган «Лада Веста»ларны сатып бетердек диярлек. Бәясе – 2,2 миллион сум. Хәзер әлеге модель машина җитештерелми, чөнки детальләре һәм запас частьлары күбесенчә чит илнеке иде. Майда кабат эшне җайга салачаклар икән, дигән имеш-мимешләр йөри. Тик безгә бу хакта хәбәр итүче юк. Тәрәзә җылыткычы һәм рульне гидрокөчәйткечсе булган «коры» «Лада Гранта» машинасы 722 мең сум тора. Кондиционер да кирәк дисәгез, 900 мең сум чамасы түлисе. Төсе – кара гына. Заводта буяу белән кыенлыклар килеп чыккан. Менә шундый хәлләр. Йә 900 мең сумлык машина аласыз, йә 2,5 миллион сумнан башлап – иномарка. Ике арада тәкъдим итәрлек берни юк. Моңарчы 1,5 миллион сумга «Лада Ларгус» сата идек. Әлеге машинаны авылда яшәүчеләр бик яратты. Хәзер анысы да юк. Механикага тоташтырылган «Лада Ларгус»ларны быел декабрьдә кабат җыя башлыйлар икән, дип әйтәләр. Тик бу да сүздә генә. 1980 нче елларда күпләп «Нива» сата идек без. Хәзер дә шул елларга кире әйләнеп кайттык. Әнә 1,4 миллион сумга «Нива» кирәкмиме?

Сүз уңаеннан, быел мартта илнең төрле шәһәрләрендә, шул исәптән, Казанда да яңа «Москвич 3» машиналары сата башладылар. Бәясе 2 миллион сумнан башлана, ди. Әлегә шәһәр урамнарында мондый машина күргән юк.

Ай саен – 39 мең сум

Кытай машиналары сатыла торган салон исә гөжләп тора. Килешүләр төзү бүлмәсе ишеге төбендә үк чират әнә. Машина карап йөрүчеләрне каһвә белән сыйлыйлар.

– «Омада»ны узган елның декабреннән генә сата башладык. Ул – безнең базар өчен ят машина. Шуңа күрә аңа бераз шикләнеп карыйлар. Тәкъдим ителгән өстәмә уңайлыкларны да исәпкә алсаң, бәясе 2,7 миллион сумнан башлана, – дип, ишектән керүгә, табадан яңа төшкән машинаны мактый башлады сатучы егет. – Кытай машиналары арасында күбрәк «Хавейл»га өстенлек бирәләр. Мәсәлән, ай башында гына салонда унбишләп «Хавейл F7» машинасы (бәясе 3 миллион сум тирәсе. – **Ред.**) бар иде, бүген берәү генә калды. Автомобиль базарында бу бәягә С классны машина юк. Иң күбе «Джолион» моделен сатабыз. Бөтен ташламаларны да исәпкә алып, аның бәясе 2,4 миллион сумнан башлана. «Омода» автомобильләренә биш ел яки 150 мең чакрымга кадәр, «Хавейл»га исә азрак, өч ел гарантия каралган.

Сатучы шунда ук якынча исәпләп тә бирде. Кулдагы машинаны трейд-инга тапшырып (бу очракта 100 мең сум ташлама да каралган), җиде елга кредитка «Хавейл Джолион» алсаң, ай саен 39 мең сум акча түлисе була.

Чаллыда машиналар алып-сату белән шөгыльләнүче Рөстәм Насыйров исә ашыкмаска киңәш итә.

– Кытай машинасы әйбәт була алмый. Яңа машина турында хыялланучыларның күбесен әлеге автомобильләрнең тышкы кыяфәте кызыктыра. Тик никадәр генә матур булып күренсә дә, әле тиешле сынау узмаган бу автомобильләрнең кимчелекле яклары шактый. Мәсәлән, бер елдан электрон җиһазлары эштән чыгарга, биш елдан машина чери башларга мөмкин. Ә кулдан Кытай машинасын сатып алырга теләүчеләр юк диярлек. Зур ташлама белән сатып җибәрсәләр генә, – ди Рөстәм Насыйров.

Аның әйтүенчә, бүген иске машина базарында, гомумән, хәлләр сөенерлек түгел.

– Билгеле сәбәпләр аркасында, яңа машиналар бик нык кыйммәтләнде. Бу исә иске машина базарына да турыдан-туры тәэсир итте. Мәсәлән, бүген сатуда булган биш еллык «Хендай Крета» автомобиле 2 миллион сум чамасы тора. Әле яңа гына шундый ике еллык «тимер ат»ны 3 миллион сумга сатып җибәрдек. Ел башыннан бирле кулланышта булган машиналар 10 процентка кыйммәтләнде. Ә тәкъдим кимеде. Моның сәбәпләре төрле. Беренчедән, сатуда автомобильләр булса да, ремонт өчен запас частьлар табып булмаячак дип, машина ээләүчеләр күп кенә иномаркаларга борылып та карамый. Икенчедән, элек рульдәгеләр өч-биш елдан машинасын сату, алмаштыру ягын караса, хәзер ашыкмыйлар. Юк кына автомобильләр дә алтын бәясе тора бит хәзер, – ди сатучы.

Эльвира ВӘЛИЕВА

ЯКЫН АРАДА МАШИНА САТЫП АЛЫРГА, АЛМАШТЫРЫРГА ҖЫЕНАСЫЗМЫ?



Бу хакта уйлаганым да юк	42,9%
Аласым килә, тик акчам юк	27,2%
Әле күптән түгел генә машина сатып алдым	5,4%
Машина бик кыйммәткә төшә, сатарга җыенам	5,1%
Әйе, яңа машина эзли башладым инде	2,2%
Башкасы	17,2%

«Автостат» аналитика агентлыгыннан

Фикер

Илдус САФИУЛЛИН, икътисад белгече:

– Параллель импорт «соры базар»га юл ачты. Димәк, машиналарга булган кытлыктан файдаланып калырга теләүчеләр дә күп булачак. Моның мисаллары бар инде. Чит илдән Россиягә машиналар алып кайту белән шөгыльләнүче шикле компанияләр турында еш ишетәбез. Интернетны гына ачып карагыз, «чит илдә машина сайларга ярдәм итәм» дигән эчтәлектәге игъланнар бихисап. Мондый автомобильләрнең күбесе ватык хәлдә сатып алына да, Белоруссиядә ремонтлап, безгә кайтарыла. Гарантиясе булмагач, машинасыз да, акчасыз да калуың бар. Шундый тәкъдимнәргә кызыгып, бер танышым Европадан иномарка кайтартты. Баксаң, әлеге машина безнең кышкы юлларга гомумән туры килми икән. Шул ук алыпсатарларга ярты бәясенә диярлек кире сатып җибәрде. Кайбер мәгълүматларга караганда, Мәскәүдә генә дә ай саен соры схемалар буенча кайтартылган йөзләгән машина сатыла. Көннәрнең берендә бу машиналар безнең кулга килеп эләкмәс дип кем ышандырып әйтә ала? Вазгыять якын арада гына үзгәрмәячәк. Тагын да начаррак булмаса әле. Җәяү йөрмәсәк тә, җәмәгать транспортына күчеп утырырга туры килмәгәе.

Зөһрә
САДЫЙКОВА

КАУРЫЕ ЯТЫП ТОРСЫН

ЧЕБИ АЛГАНДА НИЧЕК АЛДАНМАСКА?

Тиздән бар мәшәкатьләре белән бергә чын авыл тормышы башлана. Һәр хуҗалыкта диярлек кош-корт тавышлары ишетеләчәк, абзардагы маллар көтүгә куылачак, ишегалларын җыештыру, бакчаларны рәткә китерү кебек бетмәс-төкәнмәс эшләр... Гадәттә, кошчылык белән шөгыльләнүче фермер хуҗалыкларында сезон март уртасында ачылса, халык бер айлык кошларны апрель ахыры – май башларында ала. Хәер, җылы сарае, уңай шартлары булганнар инде чеби алу хәстәрен күрә дә.

– Мәшәкате күп булса да, без бройлер чебиләрен ел да апрель башында алып үстерәбез. Гадәттә 50гә якын алам. Быел да шул тирә булыр, дип торам. Кош-кортлар тота торган яхшы сараебыз бар. Ирем узган ел тагын карап, яңартты. Иң мөһиме – чебиләрнең аслары коры, бина эче җылы булырга тиеш. Барлык шартларын китерергә тырышабыз. Кошларны исә Питрәч районыннан алып кайтабыз. Ел да бер кешедән алгач, ышанычлы, – ди Лаеш районыннан Камәрия Заһидуллина.

Камәрия ханым кебек бер тәүлеклек чебиләр алып үстерүчеләр күп түгел шул хәзер. Күпчелек бер айлыкны алырга тырыша.

– Чебине иртә алып, өйдә үстергән чаклар узды инде, – ди Зөлфия Абдуллина. – Әле киленем дә: «Әни, бу көннәрдә чыга торган бройлерларны – 70 сумнан, апрельдә чыга торганнарын 78 сумнан саталар. Алмыйбызмы?» – дип шалтыраткан иде. Акчаны янга калдырам дип кенә алсаң инде. Әле алай да шикләндерә, мәшәкате куркыта. Элек өйдә күп үстердек, хәзер бер дә алай эшлисе килми. Гадәттә, үскәннәрен партия-партия майда, июньдә ала торган идек. Быел да шулай эшлисе булыр, ахры.

Алтын кагыйдә – чисталык

Мөслим районының Әмәкәй авылында кошчылык белән шөгыльләнүче Ралинә Бәшированың киңәшләре укучыларыбыз өчен файдалы булыр дип ышанабыз.

:: Ралинә, каз бәбкәсе, бройлер сатып алганда нәрсәгә игътибар итәргә кирәк?

– Кош-кортны сыйфатлы, ышанычлы товар җитештерүчеләрдән генә алырга кирәк. Элек без экономия максатыннан, чебиләрне ерактан барып ала торган идек. Юлда чирләткән, «кыздырган» чаклар да булды. Акчаны янга калдырам дип, болай эшләргә кирәкми, чөнки беренче көннәрендә авырган чеби берничек тә сәламәт булып үсә алмый. Шуңа күрә без хәзер кош-кортны эре җитештерүчеләрдән, Актаныш районыннан алабыз.

Ралинә Бәшированың шәхси архивыннан

:: Бер тәүлеклек чеби алу отышлымы, әллә бераз үскәннеме?

– Куплап алганда, бер тәүлеклек чеби алу отышлырак. Эре хуҗалыкларның күпчелеге шулай үстерә, чөнки алар 30 көннән соң ул чебине сата. Бик сирәкләре генә ике ай үстереп, иткә әзерли. Ә казларны бер айлыкларын алырга киңәш итәм, чөнки алар –авыруларга тизрәк бирешә торган кош.

:: Бройлерны ничек тәрбияләргә кирәк? Ул нәрсә ярата?

– Бройлерга махсус алар өчен җитештерелгән катнаш ризык бирергә кирәк. Аның составында чебигә үсәр өчен нәрсә кирәк, барысы да бар: витаминнар, борчак, көнбагыш мае, акбур һәм башкалар. Чебинең яшенә карап, аларның составлары аерыла. Төрле үсеш этабында «старт», «предстарт», «рост», «финиш» дигәнне карап алырга кирәк. Чебиләр бер айга кадәр катнаш ризык ашый, күп су эчә. Аннан соң рационнарына мөмкин кадәр күбрәк яшел үлән, кычыткан кертсәң яхшы. Теләсә нинди кош-кортны үстергәндә истә тотарга кирәкле алтын кагыйдә – чисталык. Чебиләрнең асты һәрвакыт коры, чиста булырга тиеш. Һәм, әлбәттә, алларыннан суны өзмәү кирәк. Моннан тыш, бройлер чебиләрне ишегалдына кызыл тавык кебек чыгарып җибәрергә ярамый. Андый бройлерлар ябык була. Алар өчен махсус челтәр белән уратылган, артык чабып йөрмәслек урын кирәк. Чебиләрнең тере килеш авырлыгы 3,8–4,5 кг булса яхшы. 5 килограммнан арткан кошларның ите каты була. Тәме дә яшь чебинеке кебек тәмле булмый.

:: Казларның нинди токымнарын алырга киңәш итәсез?

– «Линда» токымын алырга киңәш итәм. Алар безнең климатка яраклаштырылган, авыруларга бирешмәүчән. Аның ите дә тәмле, йомшак була. Тиз үсүе белән дә отышлы.

:: Авыру кош алып, аны башкалар янына керткәч, барысы да авырый башлаган очракта, нәрсә эшләргә?

– Кошлар арасында очрый торган иң куркыныч авыру – кош гриппы. Ул хуҗалыкка керсә, бар тырышлыгың җилгә очарга мөмкин. Соңгы кошка кадәр юк ителәчәк. Моннан башка да авырулар очрап тора. Чебиләр сәламәт булып үссен өчен, аларны алып кайтыр алдыннан ветеринар кибетләрдән акбур алып, абзарны эшкәртеп чыгарга кирәк. Бер төр кошны икенчесе белән кушарга һич ярамый. Бигрәк тә каз белән бройлерны. Чөнки казга куркыныч булмаган, җиңелчә генә уза торган чир бройлерны үтерә. Һәм бройлерда булган авыру казны юкка чыгарырга сәләтле. Бигрәк тә бер савыттан ашату куркыныч. Мондый хәлләр еш булып тора. Инде кошлар авырып китсәләр, тиз арада ветеринарга яки даруханәгә барырга кирәк. Аннан соң хәлсез, утырып кына торган чебиләргә игътибарны арттырырга кирәк. Күпләр, барыбер үлә инде дип, кул селти. Болай эшләргә кирәкми. Кеше ветеринарга мөрәҗәгать итсен иде.

:: Кош-корт сатып алганда, ничек алданмаска?

– Кошчылык белән берничә ел шөгыльләнгән танышларыгыз булса, иң элек киңәшне шуннан сорарга була. Күпләп кош алганда, арзанга кызыгып алданмау хәерле. Чөнки яхшы чеби кыйммәт була.

:: Йомырка салмый торган тавык токымы булырга мөмкинме? Тавыкның йомырка салмавына нәрсә сәбәпче була ала?

– Андый токымнар булуын бер дә ишеткәнем юк. Миңа калса, тавыкның йомырка салмавы авыруга бәйле. Шуның өчен тавыкларга да вакытында витаминын бирергә, ашавын карарга кирәк.

Ничек тәрбиялисез?

Зәмәрия СӘЛИМОВА,
Яңа Чишмә районы Зирекле авылы:

– Мин чебиләрне үзебез өчен генә ел да инкубаторда чыгарам. Апрель уртасында, инкубатор бушагач, соры эре каз йомыркаларын урнаштырачакмын. Күркәләрне үзем чыгармыйм. Аларын бер айлыкларны сатып алам, чөнки әлеге кошларны үстерү катлаулырак, бик белеп карарга кирәк. Чебиләрне, чыгуга ук, лампа астына җылыга, тартмага урнаштырам һәм асларын гел алыштырып, чистартып торам. Беренче биш көндә чиста тукыма җәям, аннан вак йомычка яки печән вагы таратам. Беренче көннән йомырка ашатам. 4–5 нче көннәрдә ипи куша башлыйм. Шулай ук бераздан фураж (тегермәндә тарттырылган арпа, бодай, көнбагыш, кукуруз) бирәм. Эчәргә беренче 10 көндә чәй куям. Аннан – кайнаган, 15 көннән соң чиста суга күчерәм.

Гөлүсә ГАБДРАХМАНОВА,
Азнакай районы Беренче Май авылы:

– Безнең авылда бер көнлек чебешләр алучы юк инде. Апрель, майда бер айлыкларны алабыз. Элеккеге елларда февральдә үк бер көнлекләрне алып, өйдә күп үстердек. Тик аның мәшәкате зур. Тәрбия күп сорыйлар, исе дә өйгә сеңә. Хәзер алай мәшәкатьләнмибез инде. Зурларны карап үстерү күпкә уңайлырак.

ТАТАРСТАНДА КОШ-КОРТКА УРТАЧА БӘЯЛӘР

Бер тәүлеклек бройлер – **90 сум**

Бер тәүлеклек күркә – **470 сум**

Бер тәүлеклек каз бәбкәсе – **280 сум**

35 көнлек бройлер – **355 сум**

19 көнлек үрдәк – **230 сум**

20 көнлек «Мулард» токымлы үрдәк – **420 сум**

Күзе түгәрәк булсын

Ветеринар, кош-корт сатучы Зөлфия ШӘЙХЕЛИСЛАМОВАдан киңәшләр

1 Әгәр мөмкинлек булса, кошларны бер генә кешедән сатып алырга тырышырга кирәк. Беренчедән, бу ышанычлы, икенчедән, микрофлора өчен дә яхшы.

2 Шулай ук чебиләрне алып килгән машинаның эче дә чиста булу бик мөһим. Үз-үзен хөрмәт иткән кошчы машинаны гел чиста-пөхтә, тәртиптә тота, кошлар торган тартмаларны юа.

3 Чебешләрнең каурый, йоннары тырпайган булмаска, күзләре тонык, күз агы кызыл түгел, ә ачык, түгәрәк (озынча күзле кош авыру була), чеби үзе тере, хәрәкәтләнүчән булырга тиеш.

4 Тәүлеклек чебине аркасына яткырып тикшереп карарга киңәш итәм. Тиз генә аягына баса икән, яхшы. Ә инде егылгач, озак тора алмый ятса, өметле түгел. Тагын бер төрле сынап карарга мөмкин: бәбкәне аркасына яткырып, кендеген карагыз. Әгәр ул эчкә суырылган һәм караңгы төстә яки төзәлеп бетмәгән икән, авыру булырга мөмкин. Шулай ук кендек шар сыман кабарган да булмаска тиеш.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

БИЛ КЕМ КУЛЫНДА?

Элегрәк сылу буй-сынга ирешү тау кадәр сабырлык сораучы кыен эш саналса, хәзер моның өчен, күп дигәндә, бер ай вакыт җитә. Елдан-ел популярлаша баручы ябыгу марафоннарын оештыручылар шулай дип вәгъдә итә. Яз җитүгә, аларга ихтыяҗ бермә-бер арта. Ләкин белгечләр мондый юл белән ябыгырга теләүчеләргә сак булырга киңәш итә. Марафоннар сәламәтлеккә генә түгел, психикага да зыян салырга мөмкин, дип кисәтә алар. Каш ясыйм дип күз чыгармас өчен ни эшләргә?

vk.com

Коктейль «бүләге»

Бер танышым шундый марафонда катнашып, бер ай дигәндә ун килограммга ябыккан иде. 70 килограмм чамасы авырлыктагы кызның күз алдында 60ка калуына барыбыз да аптырадык. Бер елдан очраклы күрешкәч, шаккаттым. Үзе килеп эндәшмәсә, танымый да идем. Шул ябыкканнан соң бер ел эчендә 87 килограммга кадәр тазарган ул. Баксаң, теге юлы ябыктыручы коктейльләр эчкән булган икән. Коточкыч тазаруының төп сәбәбен дә шуннан күрә. «Гормоннар эшчәнлеге бозылды. Кемгә генә күренеп, нинди генә дарулар эчеп карамадым, файдасы юк. Авырлыгым гел шул тора – тазармыйм да, ябыга да алмыйм», – дип сөйләгән иде ул.

Россиядә ябыгу марафоннары 2014 елларда популярлаша башлады. Хәзерге вакытта безнең илдә тыелган, барыбыз өчен таныш социаль челтәрнең популярлашып кына килә башлаган вакыты иде ул. Мондый төр марафоннарга кешеләрне дә, нигездә, әнә шул кушымтаны кулланучылар арасыннан җәлеп иттеләр. Кесәне әллә ни тишми торган бәягә, юклы-барлы өч-дүрт атна эчендә фәлән килограмм артык авырлыктан котылырга теләүчеләр саны елдан-ел арта барды. Бүген инде ябыгу марафоннарында катнашу гадәти күренешкә әйләнде.

Җайлы бит: махсус төзелгән меню буенча тукланасың, көндәлек нәрсә ашаганыңны тикшереп, контрольдә тоталар. Бик нык тырышсаң, үҗәтлегең өчен бүләк тә бирергә мөмкиннәр. Челтәрле маркетингта эшләүчеләр мондый марафоннарда, гадәттә, үзләре сата торган продукцияне дә төртергә тырыша.

Рәсми саннарга ышансаң, пандемия чорында Россиядә ябыгу марафоннарына ихтыяҗ икеләтә арткан. Мисал өчен, илгә коронавирус үтеп кергән 2020 елның февралендә «Яндекс» сайтында онлайн ябыгу марафоннары сылтамасын 100000 кеше эзләгән булса, март аенда инде аларның саны ике тапкыр арткан. Пандемия аркасында өйдән чыгу, аралашу мөмкинлеге чикләнгәч, күпләрнең онлайн рәвештә генә ябыгасы килүе аңлашыла.

Күреп торабыз: бүген социаль челтәрдә утыручы һәр ике кешенең берсе табиб, коуч, психолог, диетолог. Араларында бу юнәлештә бернинди махсус белеме булмый торып, эшчәнлек алып баручылар да бихисап. Ябыгу марафоннарын оештыручылар да искәрмә түгел. Бүген хәтта артистларга кадәр халыкны ябыгырга өйрәтә.

Белгәннән сорашасы

Татарстанның атказанган артисты Ләйсән Гыймаева язылучылары арасында өч ел рәттән ябыгу марафоны уздыра. Берничә көннән 3–4 атналык марафонның чираттагысы башланачак. Анда катнашу 1490 сумга төшә.

– Дүрт ел элек бер челтәр оешмасында эшләп алган идем. Алар мондый марафоннарны даими уздыра. Шунда: «Андый марафоннарны бернинди БАДларсыз гына да уздырып була бит», – дигән фикер килде. Нутрициолог белән киңәшләштем дә сәламәтлек өчен шундый ябыгу марафоны оештыра башладым. Бездә бернинди БАД, дарулар эчәсе юк. Бары тик дөрес туклану һәм физик күнегүләр ясау хисабына гына ябыгабыз, – ди җырчы.

Кызлар марафон дәвамында уртача 3–4 килограмм авырлык ташлый икән. Гәүдә авырлыгы зур булганнар арасында 10 килограммга кадәр ябыгучылар да булган. Ләйсән – оештыручы. Командаларында туклану буенча киңәшләр биреп, меню төзеп, кызларның көндәлек ашау тәлинкәләрен тикшереп торучы нутрициолог та бар. Тренер яздырган видеолар да кулланыла. Марафонда кызлар белән психолог та эшли икән. Ул ашауга бәйле начар гадәтләр турында сөйли, алардан котылу юлларын күрсәтә. Белгечләрнең берсе дә очраклы кешеләр түгел, кыскасы.

– Марафоннар күп. Алар арасыннан файдалысын сайлап алу, алданмау өчен кайтавазларны укырга, өйрәнергә кирәк, анда катнашып караган кешеләрдән сорашсаң да яхшы, – дип саный Ләйсән Гыймаева.

Психикага бәрә

Психология фәннәре магистры, психолог Чулпан Нигъмәтҗанова-Гарәфиева фикеренчә, кыска вакытлы ябыгу марафоннары – кеше психикасы өчен зур сынау. Бер яктан алар кешедә мотивация тудыра, дөрес туклану, спорт белән шөгыльләнү, сәламәт яшәү рәвеше алып бару кебек яхшы гадәтләр булдырырга ярдәм итә. Әмма марафон көтелгән нәтиҗә бирмәсә, кешенең күңеле кайта, ул хәтта күңел төшенкелегенә бирелергә мөмкин.

– Мондый марафоннарны оештыручылар кешенең иң нечкә кылларына тия торган сүзләрне бик оста файдалана. Безнең марафон ярдәмендә битегезнең тиресе яхшырачак, гәүдәгез төз-матур булачак, гел ризык турында уйлаудан туктыйсыз, дигәнрәк шигарьләр белән үзләренә җәлеп итәргә тырыша. Болар турында кем хыялланмый? Шушы сүзләрдән башы әйләнеп, күпләр ябыгу марафонына килеп эләккәнен сизми дә кала. Ябыгу марафоны оештыручылар максатка ирешүнең җиңел юлын тәкъдим итә. Кеше шуңа каба да. Чынлыкта, нинди дә булса максатка ирешү өчен, бик күп көч, вакыт, белем таләп ителә. Аннары бик күпләр марафонда вәгъдә ителгән айфон, зур күләмдәге акчага кызыгып, ябыгудан бигрәк әнә шуңа алданып кила, – ди психолог.

Марафон тәмамлангач, югалткан килограммнарның кире әйләнеп кайтуын да кеше психикасына килгән зыянга бәйләп аңлата ул.

– Марафон барышында ул ашыйсы килмәгән әйберне ашыйсы килмәгән вакытта ашарга, бер утыруда үзе гадәтләнгәннән азрак күләмдә ризык кабул итәргә мәҗбүр. Шул рәвешле, кеше белән аның тәне арасында элемтә югала. Ул акрынлап ачлык, туклык хисен дә тоемламый башлый, – ди психолог.



Булат ЗАКИРОВ, юрист:

– Ябыгу марафонында катнашучының сәламәтлегенә китерелгән зыян өчен оештыручыны җавапка тартырга мөмкин. Әмма бу процесс җиңел булмаячак. Иң элек, махсус суд экспертизасы уздырып, бу кешегә нәкъ менә марафон аркасында зыян килгәнме-юкмы икәнлеген ачыклаячаклар. Аның нечкәлекләре бик күп. Шуңа күрә экспертизаның сез көткән нәтиҗәне бирмәвенә дә әзер торырга кирәк. Марафонны оештыручы белән язышкан смсларны, чекларны да саклагыз. Алар судта дәлил булып торачак. Чек дигәннән, марафонда катнашу өчен акчаны онлайн рәвештә күчергән булсагыз, аны банк аша да исбатлап була. Кәгазь акча белән түләгән очракта кулыгызда чек яки расписка кәгазе булырга тиеш.

Марафонда катнашыр алдыннан иң элек оештыручыны җентекләп тикшерегез (профильле белеме булу, башка катнашучыларның фикерләре һ.б.) Килешү шартларын (килешү предметы, якларның җаваплылыгы шартлары һ.б.) игътибар белән укыгыз. Ник дигәндә, мондый килешүләр еш кына оештыручыдан җаваплылыкны төшерү өчен төзелә. Әйтик, килешүдә «катнашучы алдан табиб белән киңәшләшергә тиеш» дип күрсәтелгән булса һәм катнашучы кеше табибтан консультация алмаган булса, җаваплылык аның үз өстендә булачак.

«Кисәк ябыгу куркыныч»

Кыска вакыт эчендә ябыгу организмга ничек тәэсир итә? Ябыгу марафоннары кемнәр өчен аеруча куркыныч? Әлеге һәм башка сораулар белән Республика клиник хастаханәсе табиб-терапевты, спорт табибы Анастасия ЯКОВЛЕВАга мөрәҗәгать иттек.

:: Ябыгу марафоннарының файдасы күбрәкме, зыянымы?

– Мондый марафоннарның файдасына караганда зыяны күбрәк. Беренчедән, аны оештыручылар һәр кешегә индивидуаль якын килми, аларның нинди авырулары барлыгын да белми. Марафон башлар алдыннан алар иң элек кешегә аның саулыгының ни дәрәҗәдә икәнен ачыкларга ярдәм иткән анкета тутыртырга тиеш. Анда кешенең буй озынлыгы, авырлыгыннан башлап, кайсы авырулардан интегүе, нинди дарулар эчүе, имгәнү-җәрәхәтләре барлыгы турында тулы мәгълүмат күрсәтелергә тиеш. Һәр кешенең организмы индивидуаль. Бер кешегә туры килгән меню икенче кешегә зыян салырга мөмкин. Күнегүләр белән дә шул ук хәл. Ә марафоннарда һәркемгә бер төрле меню, күнегүләр тәкъдим ителә.

:: Кыска вакыт эчендә ябыгу организмга ничек тәэсир итә?

– Кеше аена, күп дигәндә, 4 килограммга гына ябыгырга тиеш. Кисәк кенә авырлык ташлау – организм өчен зур стресс. Кисәк ябыккан кешенең, гадәттә, гормоннар эшчәнлеге бозыла, бала табу әгъзалары системасына, йөрәк-кан тамырларына зыян килә, иммунитеты начарлана, кәефе үзгәрүчәнгә әйләнә. Ул мускулларга да бәрә. Җиерчыклар да пәйда була.

:: Мондый марафонда катнашыр алдыннан табибка күренергә, ниндидер анализлар тапшырырга кирәкме?

– Әлбәттә, кирәк. Марафонда ябыгырга уйлаган кеше иң элек эндокринологка күренергә тиеш. Моннан тыш, гомуми, биохимик кан анализлары тапшырырга, ЭКГ ясатырга, бөерләрне, калкансыман биз, җенес гормоннарын тикшертергә кирәк.

:: Ябыгу марафоннары кемнәр өчен аеруча куркыныч?

– Булимия (гел тамак ачу, даими рәвештә ашыйсы килеп тору рәвешендә уза торган авыру) диагнозы куелган кешеләргә мондый марафоннарда катнашу гомумән тыела. Аларга иң элек психик якны тәртипкә китерергә кирәк. Хроник йөрәк-кан тамырлары авырулары, шикәр чиренннән интеккән кешеләргә дә ябыгу алдыннан җиде кат уйлап, бер кат кисү хәерле.

3 апрель | Дүшәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 16+
07.00, 18.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.00 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
09.00 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ» 16+
10.00, 23.00 «ВТОРАЯ ЖИЗНЬ» 16+
11.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
11.30 «Заман көзгесе» 6+
12.00, 22.10 «ТӨЛКЕ ЕЛМАЮЫ» 12+
13.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество»16+
14.45 «Музыкаль мәйдан»16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә». «Акыл батл» 0+
16.00 «БӘХЕТЛЕМЕ СИН?» 16+
17.00 «Таяну ноктасы» 16+
17.30 «Татарстан без коррупции» 16+
19.30 Хоккей. Кубок Гагарина. Матч серии play-off. «Ак барс» – «Авангард». Прямая трансляция 0+
22.00 «Вызов 112» 16+
00.00 «Каравай». Портрет современного фольклориста 6+
00.25 «Таяну ноктасы» 16+
00.50 «Ком сәгате» 16+
01.45 «Рыцари вечности» 16+
02.00 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 16+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 16+
04.45 «Җырлыйк әле!» 12+
05.35 «Оныта алмыйм...» Ретро-концерт 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълумати- күңел ачу программасы 16+
08.00 «Уткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 23.10, 04.15 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Туган җир» 12+
12.05, 18.20, 21.25 «АЛМАШ». Телесериал 16+
15.25, 20.30 «Заман көзгесе» 6+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан» 16+
17.30 «Ватандашлар». Фәйзи Галиев. Гомер утә, хәтер кала 16+
19.15 «Музыкаль мәйдан» 16+
19.30 «Калеб» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
22.20, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
00.15 «Калеб» 6+
00.40 «Уткәннәр сагындыра» 12+
02.50 «Караоке татарча» 12+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 16+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское / Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
20.00 Премьера. «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
21.45 Премьера. Сергей Безруков в многосерийном фильме «Шпион» (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
23.45 Премьера. Любовь Аксенова в многосерийном фильме «Почка» (S) 18+
00.15 ПОДКАСТ.ЛАБ «Гори огнем» 16+
00.55 ПОДКАСТ.ЛАБ «Обязательно к прочтению» 16+
01.35 ПОДКАСТ.ЛАБ «По Первое число» 16+
02.15 ПОДКАСТ.ЛАБ «Собрались с мыслями» 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Антропология» 16+
03.45 ПОДКАСТ.ЛАБ «Психика» 16+
04.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «20 лет спустя» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Татьяна Лялина, Нил Кропалов, Алексей Анищенко, Олег Фомин, Ольга Кабо, Анна Большова, Вадим Андреев, Алёна Коломина, Александр Тютин. «ЗАПОЛЯРНЫЙ ВАЛЬС» 12+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 Детективный телесериал «ДУЭТ ПО ПРАВУ» 12+
03.55 Вячеслав Разбегаев, Кирилл Плетнёв, Наталия Быстрова, Анна Гарнова, Андрей Арзяев, Дмитрий Ермак. «ПЫЛЬНАЯ РАБОТА» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 14.25 «Спортивный век» 12+
06.30 «Магия большого спорта» 12+
07.00, 10.00, 12.55, 14.55, 16.40 Новости
07.05, 15.30, 21.45, 00.20 Все на Матч! Прямой эфир
10.05, 12.35 Специальный репортаж 12+
10.25 Дзюдо. Фонбет Российский профессиональный тур. Трансляция из Хабаровска 0+
11.25 Бокс. Bare Knuckle FC. Реджи Барнетт против Даниэля Альвареса. Трансляция из США 16+
13.00 «Есть тема!» Прямой эфир
15.00 Футбол. Журнал Лиги чемпионов 0+
16.45, 01.00 Футбол. МИР Российская Премьер-Лига. Обзор тура 0+
17.45 «География спорта. Сахалин» 12+
18.15 «Громко» Прямой эфир
19.15 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. Финал конференции «Восток». «Ак барс» (Казань) – «Авангард» (Омск). Прямая трансляция.
22.30 «Марадона. Смерть бога». Документальный фильм 16+
02.00 Баскетбол. Единая лига ВТБ. 1/4 финала. УНИКС (Казань) – «ПАРМА-ПАРИ» (Пермский край) 0+
03.55 Новости 0+
04.00 Гандбол. Чемпионат России. OLIMPBET Суперлига. Женщины. «Ростов-Дон» (Ростов-на-Дону) – «Астраханочка» (Астрахань) 0+
05.30 «Наши иностранцы» 12+

НТВ

04.55 Никита Панфилов в сериале «ПОБЕДИТЕЛИ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. РУБЕЖИ РОДИНЫ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 Премьера. Детективный сериал «СТРАЖНИК» (S) 16+
22.15, 00.00 Остросюжетный детектив «НЕВСКИЙ. ОХОТА НА АРХИТЕКТОРА» (S) 16+
00.45 Остросюжетный сериал «УГРО» (S) 16+
04.05 «Таинственная Россия» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.20 «Давай разведём!» 16+
09.20 «Тест на отцовство» 16+
11.35 «Понять. Простить» 16+
12.40 «Порча». «Плохой пример» 16+
13.10 «Знахарка» 16+
13.45 «Верну любимого» 16+
14.15 «Голоса ушедших душ» 16+
14.50 «ДЕВИЧИЙ ЛЕС» 16+
19.00 «НАСЛЕДСТВО» 16+
23.05 «ПАРФЮМЕРША». 1-я – 4-я серии 16+
02.20 «Порча» 16+
02.45 «Знахарка» 16+
03.10 «Верну любимого» 16+
03.40 «Голоса ушедших душ» 16+
04.05 «Понять. Простить» 16+
04.55 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.20 «СИНДРОМ ШАХМАТИСТА». 3-я и 4-я серии 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром». 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня. 16+
09.20, 01.05 «ДЕЛО РУМЯНЦЕВА» 12+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.20, 15.05 «БЕЛЫЕ ВОЛКИ». 15-я – 18-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
18.20 «Специальный репортаж» 16+
18.55 «Бог войны. История русской артиллерии». Документальный сериал. Фильм 5-й 16+
19.40 «Загадки века с Сергеем Медведевым». Документальный сериал 12+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.25 «ДОЖИТЬ ДО РАССВЕТА» 12+
02.45 «Маресьев: продолжение легенды». Документальный фильм 12+
03.35 «БЕЛЫЕ ВОЛКИ». 15-я и 16-я серии 16+

4 апрель | Сишәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
09.00 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ» 16+
10.00, 23.00 «ВТОРАЯ ЖИЗНЬ» 16+
11.00 «Азбука долголетия» 16+
11.15 «Память сердца» 16+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «ТӨЛКЕ ЕЛМАЮЫ» 12+
13.00 «Туган җир» 12+
13.30 «Юлчы» 16+
14.00 «Путь» 16+
14.15 «Не от мира сего...» 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан»16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Төймә» 0+
16.00 «Ватандашлар» 16+
17.00 «БӘХЕТЛЕМЕ СИН?» 16+
18.00 «Казаннан – Казанга» 16+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Татар сүзе» 0+
21.00 «Соотечественники» 16+
00.00 «Видеоспорт» 16+
00.25 «Соотечественники». Сердечная команда Рената Акчурина 16+
00.50 «Каравай». Творческая мастерская 6+
01.15 «Башваткыч» 12+
02.00 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 16+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 16+
04.45 «Ком сәгате» 16+
05.35 «Оныта алмыйм...» Ретро-концерт 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълумати- күңел ачу программасы 16+
08.00 «Уткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 23.10, 04.15 «Җырлыйк әле!» 12+
09.40 «Музыкаль мәйдан» 16+
10.30, 20.30 «Халкым минем» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Ватандашлар». Равил Шәрәфиев. «Әлеге юлны мин үзем сайладым» (субтитрлы) 16+
12.05, 18.20, 21.25 «АЛМАШ». Телесериал 16+
15.25 «Таяну ноктасы» 16+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан» 16+
17.30 «Татарлар» 12+
19.15 «Музыкаль мәйдан» 16+
19.35 «Татарлар» 12+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
22.20, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
00.15 «Тамчы-шоу» 6+
00.40 «Татарлар» 12+
02.50 «Караоке татарча» 12+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 16+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
20.00 Премьера. «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
21.45 Премьера. «Шпион». Многосерийный фильм (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
23.45 Премьера. «Почка». Многосерийный фильм (S) 18+
00.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Легкие деньги» 16+
01.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Жизнь замечательных» 16+
01.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «Первые лица» 16+
02.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Произвольная программа» 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «АстроУмные» 16+
03.45 ПОДКАСТ.ЛАБ «Пусть не говорят, пусть читают» 16+
04.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Мелодии моей жизни» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Татьяна Лялина, Нил Кропалов, Алексей Анищенко, Олег Фомин, Ольга Кабо, Анна Большова, Вадим Андреев, Алёна Коломина, Александр Тютин. «ЗАПОЛЯРНЫЙ ВАЛЬС» 12+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 Детективный телесериал «ДУЭТ ПО ПРАВУ» 12+
03.55 Вячеслав Разбегаев, Кирилл Плетнёв, Наталия Быстрова, Анна Гарнова, Андрей Арзяев, Дмитрий Ермак. «ПЫЛЬНАЯ РАБОТА» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 14.25 «Спортивный век» 12+
06.30 «Магия большого спорта» 12+
07.00, 10.00, 12.55, 14.55, 16.40 Новости
07.05, 15.30, 19.00, 21.45, 00.00 Все на Матч! Прямой эфир
10.05, 12.35 Специальный репортаж 12+
10.25, 01.00 Еврофутбол. Обзор 0+
11.25 Смешанные единоборства. UFC. Исраэль Адесанья против Алекса Перейры. Трансляция из США 16+
13.00 «Есть тема!» Прямой эфир
15.00 «Ты в бане!» 12+
16.45 Футбол. FONBET Кубок России. 1/2 финала. «Урал» (Екатеринбург) – «Спартак» (Москва). Прямая трансляция
19.15 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. Финал конференции «Запад». Прямая трансляция
21.55 Футбол. Кубок Испании. 1/2 финала. «Атлетик» – «Осасуна». Прямая трансляция
02.00 Футбол. Журнал Лиги чемпионов 0+
02.30 «Что по спорту? Тольятти» 12+
03.00 Дзюдо. Фонбет Российский профессиональный тур. Трансляция из Хабаровска 0+
03.55 Новости 0+
04.00 Волейбол. Чемпионат России. Pari Суперлига. Мужчины. 1/4 финала 0+

НТВ

04.50 Сериал «ПОБЕДИТЕЛИ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. РУБЕЖИ РОДИНЫ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 Детективный сериал «СТРАЖНИК» (S) 16+
22.15, 00.00 Остросюжетный детектив «НЕВСКИЙ. ОХОТА НА АРХИТЕКТОРА» (S) 16+
00.45 Остросюжетный сериал «УГРО» (S) 16+
04.05 «Таинственная Россия» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.30 «Давай разведёмся!» 16+
09.30 «Тест на отцовство» 16+
11.40 «Понять. Простить» 16+
12.45 «Порча». «Трещина» 16+
13.15 «Знахарка» 16+
13.50 «Верну любимого» 16+
14.25 «Голоса ушедших душ» 16+
15.00 «ТЕНЬ ПРОШЛОГО» 16+
19.00 «СЕРДЦЕ РИТЫ» 16+
23.00 «ПАРФЮМЕРША». 5-я – 8-я серии 16+
02.15 «Порча» 16+
02.40 «Знахарка» 16+
03.05 «Верну любимого» 16+
03.35 «Голоса ушедших душ» 16+
04.00 «Понять. Простить» 16+
04.50 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.10 «БЕЛЫЕ ВОЛКИ». 17-я и 18-я серии 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа "Сегодня утром" 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня. 16+
09.20, 01.20 «ПРОСТАЯ ИСТОРИЯ» 12+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.20, 15.05 «БЕЛЫЕ ВОЛКИ». 19-я – 22-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
18.20 «Специальный репортаж» 16+
18.55 «Бог войны. История русской артиллерии». Документальный сериал. Фильм 6-й 16+
19.40 «Улика из прошлого» 16+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.25 «ПРЕФЕРАНС ПО ПЯТНИЦАМ» 16+
02.45 «Бомба для Японии. Спасти Дальний Восток». Документальный фильм 12+
03.35 «БЕЛЫЕ ВОЛКИ». 19-я и 20-я серии 16+

ЯЗГЫ СЫНАМЫШЛАР

- Карлыгач иртә килсә, көннәр тиз матурланыр.
- Елгалар язын боздан тиз әрчелсә, ашлык уңар.
- Язын иртә күк күкрәсә, ел яңгырлы булыр.
- Аккош яз көне иртә күренсә, салкын булыр, кар тиз китмәс.
- Язын сыерчык иртә килсә, көннәр җылы булыр.
- Черкиләр яз көне иртә күренсә, һава җылыныр.
- Яз көне елга кырыйларында боз калса, ашлык уңмас.
- Яз көне балык тотканда алабуга беләй юрша күбрәк тотылса, бодай, арпа, арыш, борай уңар.
- Яз көне агачлар бөреләрен астан яра башласа, яз тиз килә.
- Апрель артык җылы булса, май салкын, җилле булыр.
- Апрельнең алтысында торна кычкырса, ел яхшы килә.
- Ай башында яшен яшьнәсә, җәй җылы килер һәм чикләвек мулдан булыр.

pixabay.com

- Апрель яңгырлы булса, гөмбә уңар.
- Апрельдә көндез кызу, төнлә салкынча булса, җылы җәй юрыйлар.
- Ай ахырында төннәр йолдызлы булса, иген уңар. Шулай ук айның соңгы ун көнендә яңгырлар яуса да, ел уңдырышлы булыр.
- Апрельдә каен суы күп акса, җәй яңгырлы килер.
- Апрельдә дә карлыгачлар килмәсә, салкын язга.

РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ ИҖТИМАГЫЙ ПАЛАТАСЫ СЕКРЕТАРЕ ХӘБӘР ИТӘ

Татарстан Республикасы Иҗтимагый күзәтчелек комиссиясе, «Мәҗбүри тоту урыннарында кеше хокукларын тәэмин итүгә җәмәгать контроле турында һәм мәҗбүри тоту урыннарындагы затларга ярдәм итү турында» 10.06.2008 ел, № 76-ФЗ Федераль закон нигезендә, компетентлы составта оештырылган (Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы советының 26.09.2022 ел, № 198-С карары). Аның составына 18 кеше кергән (Әхмәтшин Айнур Азат улы, Балафендиева Гөлия Гомәр кызы, Баязитов Илдар Рәфкать улы, Гаврилкин Евгений Викторович, Гайнетдинов Азат Галимҗан улы, Голяков Александр Александрович, Даренков Александр Александрович, Дмитриев Александр Николаевич, Исмәгыйлев Илһам Фәтхерахман улы, Мартьянов Илья Павлович, Рябцов Максим Владимирович, Сәлимов Дмитрий Марат улы, Сатдинов Илнур Әмирхәйдәр улы, Сафина Зөлфия Нурмөхәммәт кызы, Ульданова Чулпан Әнәс кызы, Хәлфетдинов Илнур Әнәс улы, Харисова Светлана Илфик кызы, Шустрова Анна Николаевна).

Татарстан Республикасы Иҗтимагый күзәтчелек комиссиясенең урнашу урыны: 420029, Татарстан Республикасы, Казан ш., 8 Март ур., 18Б й., 3-2 оф.

Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы секретаре
Л.Ю. Михеева

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ХӘТЕР КИТСӘ...

Кичә нәрсә ашаганың, яңа гына ни эшләргә теләвең онытыла, кайчак кеше исемнәре дә искә төшмичә тилмертә. Бүген күпләр әнә шулай хәтере начарланудан зарлана. Соңгы елларда хәтерсезлек олыларны гына түгел, яшьләрне дә үз итә.

Хәтерне саклау һәм яхшырту юллары турында табиб-невролог, реабилитолог, медицина фәннәре кандидаты Диләрә ШАҺИЕВА белән сөйләштек.

:: Хәтернең начарлана башлавы ничек беленә?
– Хәтере начарланган кеше, иң беренче чиратта, яңа гына булган вакыйга, күренешләрне оныта башлый. Мисал өчен, чәйнеген куя да сүндерергә онытa, бүлмәгә ни өчен чыкканын ясә, кибеткә кергәч, нәрсә алырга җыенганын искә төшерә алмыйча тилмерә. Мондый үзгәрешләрне еш кына янәшәдәгеләр дә сизә.

:: Хәтерсезлек ни өчен яшәрә?
– Яшьләрнең хәтере кан тамырларында нинди дер хилафлыклар булу аркасында начарланырга мөмкин. Ковид та хәтергә бәрә. Шул сәбәпле, соңгы елларда хәтерсезлектән зарланучылар саны бермә-бер артты. Көне буе утырып эшләүче, гел телефонга, гаджетка текәлеп утыручылар да еш кына хәтер китүдән интегә. Бу аңлашыла да. Муен гел кәкрәеп торгач, кан тамырларына авырлык килә, алар бүртә. Бу исә хәтергә бәрә.

:: Бу чир дәвалауга бирешәме?
– Хәтерсезлектән коткара торган махсус дарулар бар. Омега-3 тә файдалы. Дәвалаганда кан тамырларын ныгытучы, кан йөрешен яхшыртучы дарулар да кулланыла.

:: Хәтер тагын кайсы очракларда начарлана?
– Бик каты егылганда, башны имгәткәндә. Бала тапкан хатын-кызларның да еш кына төп зары шул. Наркоз хәтергә тискәре йогынты ясый дигән фикер дә хак. Ул хәтергә генә түгел, бөтен баш миенә тәэсир итә. Дөрес, яшьрәк кешенең организмына наркозның зарары азрак була. Ник дигәндә, яшь организм бик тиз тернәкләнә. Шуңа күрә операция ясаганнан соң берникадәр вакыт узгач, аның хәтере дә яхшырырга мөмкин.

:: Коронавирус белән авырып терелүчеләрнең дә күбесе онытудан интегә.
– Коронавирустан соң кешенең хәтере генә начарланып калмый, ул игътибарын туплый алмыйча тилмерә. Әйтик, моңа кадәр алты сәгать эчендә башкарып чыккан эшне кеше ковидтан соң еш кына ике-өч көндә дә бетерә алмый. Шуңа күрә коронавирус белән авырып терелгәннән соң хәтер начарланса, кичекмәстән неврологка яки реабилитологка күренергә кирәк.

:: Хәтерне ничек яхшыртырга?
– Иң беренче чиратта, моңа кадәр башкармаган эшләргә алынырга кирәк. Мисал өчен, хисапчы булып эшләгән кеше чит телләр өйрәнә башласа, файдага булачак. Баш мие моңа кадәр кулланылмаган нейроннарны да эшкә җигәргә тиеш. Шигырь ятлау да хәтерне яхшырта. Омега-3, Д, В витаминнары, тимер җитмәгәндә дә кеше хәтерсезлектән интегә. Шуңа күрә организмны шушы витамин һәм микроэлементлар белән баету ягын карагыз.

vk.com

БИШ НАЧАР ГАДӘТ

1 **Тәмәке тарту.** Никотин аркасында баш миенең кан тамырлары кысыла, андагы нерв күзәнәкләре үлә, күзәнәкләр кислородка кытлык кичерә. Шул рәвешле кешенең хәтере начарлана, ул игътибарсызга әйләнә, акрын уйлый башлый.

2 **Исерткеч эчемлекләр белән мавыгу.** Әлеге яман гадәт аркасында кешенең организмында матдәләр алмашы бозыла, хәтере начарлана, интеллект дәрәҗәсе кими.

3 **Фаст-фуд, каптагы камыр ризыклары.** Билгеле булганча, аларны әзерләгәндә трансмайлар кулланыла. Алар исә хәтерсезлек чире саналган Альцгеймер авыруы килеп чыгу куркынычын бермә-бер арттыра.

4 **Артык баллы ашарга ярату.** Шикәрне чамадан тыш күп ашау, дөрес тукланмау шулай ук хәтернең начарлануына китерә. Организмга даими рәвештә чамадан тыш күп шикәр кереп торса, баш миенең күләме, бигрәк тә аның хәтер өчен җаваплы өлеше кечерәя.

5 **Йокы режимын сакламау.** Англия галимнәре 10–14 яшьлек ун бала белән хәтерне тикшерү буенча тест уздырган. Аларның бер төркемен кич әзерләп, иртәнге якта сынау алганнар. Икенче төркем балалар исә тестка әзерләнгән дә шул ук көнне җаваплар да язган. Нәтиҗәдә йокысын туйдырып, тест эшләгән балаларның нәтиҗәләре 20 процентка яхшырак булган.

Табигать нигъмәте

Согы да, үзе дә шифалы

☑ Баш авырта башласа, алма ашап карагыз. Авыртуның эзе дә калмас.

☑ Көнгә 1 алма ашау организмның С витаминына булган ихтыяҗының 1/4 өлешен капларга сәләтле. С витамины исә тирегә җыерчыклар чыгудан һәм иртә картаюдан саклый. Алмада B_2 витамины да бар. Әлеге файдалы матдәгә ихтыяҗ булмаса, биткә бетчәләр чыкмас, чәч кавыкланмас, иреннәр ярылмас.

☑ Алмадагы B_1 витамины ару, күңел төшенкелеген җиңәргә, йокысызлык белән көрәшергә ярдәм итә.

☑ Алма – ялкынсынуга һәм микробларга каршы да бик яхшы дәва. Ул кан тамырларын ныгыта, холестерин дәрәҗәсен төшерә һәм организмдагы тимерне арттыра, кан басымын җайлый, ашкайнатуны, матдәләр алмашын яхшырта.

☑ Каты алманы әкрен генә чәйнәп ашау уртларга массаж ясагандай тәэсир итә. Шул ук вакытта авыздагы микробларның 90 проценты үлә.

☑ Ял иттерү өчен, пешереп изелгән алманы күзләргә куеп тору яхшы.

☑ Өч көн дәвамында алма, кипкән арыш ипие ашап, яшел чәй эчеп торган

кеше җәйлы гына тәмәке тартуны ташлый ала. Ул көннәрдә башка ризыклар ашарга һәм эчемлекләр эчәргә ярамый.

☑ Кан тамырлары киңәйгәндә, буыннар сызлаганда, көн саен ашар алдыннан 0,5 стакан җылытылган алма согы эчәргә кирәк.

☑ Бөерләрдә һәм бәвел куыгында ташлар булганда, бәвел кудыргыч чара буларак, алма кабыгыннан әзерләнгән чәй эчәргә киңәш ителә. Әлеге төнәтмә белән тире авыруларын да дәваларга мөмкин.

☑ Бөер авыруларын булдырмас өчен, көнгә 3–4 баллы алма ашагыз. Шешенүләрне бетерү өчен, чи яки пешкән алма ашарга кирәк.

Үзем сынадым

Күздәге «капчык»лар бетте

Күз төбемдә «капчык»лар пәйда булып интектерә иде. Аларны түбәндәге ысуллар ярдәмендә җиңәм. Суыткычта торган кыярны түгәрәкләп кисәм дә, шуны күз төпләренә куеп, 15 минут ятып торам. Угычтан чи бәрәңге уып, шул ботканы 10–15 минутка күз төбенә куеп торуның да файдасы тигәне бар. Вак итеп туралган петрушканы 2 чәй кашыгы каймак белән бутап, күз кабакларына куеп торсагыз да, «капчык»лар юкка чыгачак.

Гөлназ ГЫЙЛАҖИЕВА. Саба

Киңәш

ҮКЧӘҢ ЯРЫЛСА

Парафин. Үкчәсе ярылудан интегүчеләргә: йоклар алдыннан тигез күләмдә парафин, салицил кислотасы һәм балавыз алып, шуны «су мунчасы»нда тотып, җылы килеш үкчәгә ягыгыз. Бер каты кипкәч, икенче һәм өченче кат итеп ягарга кирәк. Аякны бинт белән урап, иртән аякны сабынлы-содалы җылы су белән юарга, үкчәне чистарткыч таш белән ышкырга.

Содалы су. Аның өчен табакка ярты стакан вакланган сабын һәм шулкадәр үк күләмдә чәй содасы алып, өстенә кайнар су агызып, аякны 10 минут тотасы.

Суган. Бер баш суганны урталай бүлеп, бер-ике кат кайнар су белән пешекләп алырга да шуны үкчәгә бәйләп йокларга. Иртән үкчәне чистарткыч таш белән ышкып юарга.

Файдалы

Тромбтан саклану өчен

✓ Көненә ике киви ашасаң, тромбоз ихтималы 30 процентка кими.
✓ Миндаль чикләвеге Е витаминына бай. Ул да тромб пәйда булу куркынычын киметә. Организмны Е витамины белән тулыландыру өчен көненә 55 грамм миндаль ашау җитә.

Валентина СЕМЕНОВА

ВИТАМИННАРДАН БАШЛЫЙБЫЗ

Теплицага помидор, кыяр, борыч, баклажан ише төп «хуҗа»-лар керә утырганчы, анда нәрсәләр чәчәргә һәм ничек итеп тиз генә мул уңыш җыеп алырга була?

«Россельхозцентр» оешмасының Татарстандагы филиалы әйдәп баручы агрономы Гөлия ГАЗИЗОВА безгә шул хакта сөйләде.

– Чыннан да, теплицаны нигә әле буш тотарга? Иртә өлгерешле яшел тәмләткечләр утыртсак, Май бәйрәмнәренә тәүге уңышны да җыеп алырга мөмкин ләбаса! Ә нәрсә утыртырга? Әлбәттә, редис, шулай ук салат, руккола, шпинат, укроп ише яшел тәмләткечләрне. Алар, кыска гына вакыт эчендә өлгереп, безне витаминнар белән сөендерәчәк. Төннәрен һава температурасы –2 градустан түбән төшми башласа, теплицада туфрак эресә, һич шикләнмичә, чәчүгә керешергә кирәк.

Редисның Тепличный, Заря, Жара, Сакса, Ранний Красный дигән тиз өлгерешле сортлары әйбәт. Иртә язда ул ук җибәрми, чәчәкләнми, борчалары да булмый.

Шпинат чәчәргә онытмагыз. Температура –3 градуска төшкән очракта да эһ тә итми үсеп утырачак. Янәшәсенә петрушка, кинза, укроп, кузгалак, рәйхан чәчәргә мөмкин.

Салат һәм руккола да бик яхшы һәм тиз үсәчәк. Болары – аеруча тәмле һәм хуш исле үсемлекләр. Помидор яки борыч күчереп утыртканчы, алар инде шәп кенә уңыш биреп куячак.

Ничек чәчәргә?

Чәчәргә берәр атна чамасы кала, түтәлне үтә күренмәле пленка белән каплап куярга кирәк. Пленка астында җир җылынып, пары туфракны дымландырып торсын.

Башта редис һәм укроп орлыкларын, юеш чүпрәккә салып, бер-ике көн бүрттерергә мөмкин. Орлыкларны туфракка чәчеп, өстен туфрак белән каплап куябыз. Укропны теплица кырыйларына чәчү бигрәк тә уңайлы булачак. Кыяр-помидорлар утырткач та, бернигә комачауламый, әйбәт кенә үсеп утырачак.

Шпинат белән салатны өйдә тишелдерү җайлырак. Теплицага күчереп утырткач, шундук тернәкләнеп китәчәк һәм бик яхшы уңыш бирәчәк.

Ә инде теплицаның туфрагын яңартып, файдалы матдәләр белән тукландырып җибәрергә уйласагыз, яшел тәмләткечләр урынына сидерат чәчә аласыз. Моның өчен горчица әйбәт. Орлыкларын туфрак өстенә чәчеп, тырма белән күмеп куясың.

Хуҗабикә колагына

Тәмле булсын!

* Фарштан шарчыклар әвәләргә җыенсагыз, иң элек уч төпләрегезгә үсемлек мае сөртегез. Болай эшләгәндә, ит кулга ябышмаячак, шарчыклар да матур һәм шома килеп чыгачак.

* Миндаль чикләвеге кулланырга теләсәгез, аларны төнгә тозлы суга салып калдырыгыз. Чикләвекләргә бик тәмле тәм керү генә түгел, аларның күләме дә ике тапкыр артачак.

* Фаршка кипкән рәйхан (1 кило иткә ярты чәй кашыгы) өстәсәң, котлет аеруча тәмле һәм хуш исле булачак.

* Эремчек дучмагы (ватрушка) алсуланып пешсен өчен, өстенә бераз гына чәй содасы сибәргә кирәк.

Аш-су

ЧҮПРӘСЕЗ ЮКА

Алия МӨХӘММӘТВӘЛИЕВА рецепты

Хәзер дөрес туклану турында күп сөйлиләр. Чүпрә куллануны киметергә киңәш итәләр. Кефирда изелгән чүпрәсез юка – шундыйрак ризыкларның берсеһер, мөгаен. Озак искерми дә әле ул. Икмәкне шуңа алыштыручылар байтак хәзер.

Кирәк: *300 г он, 250 г кефир, 3 тырнак сарымсак, 1 чәй кашыгы сода (өймичә), ярты чәй кашыгы тоз, бераз гына укроп, үсемлек мае яки атланмай.*

Иләнгән онга сода салып болгатабыз. Кефирга тоз, вак тишекле угыч аша чыгарылган сарымсак, ваклап туралган укроп салып, барысын бергә катнаштырабыз. Содалы онны әзәләп салып, башта – кашык, аннан кул белән камыр изәбез. Кулга бераз ябышып торган, йомшак булырга тиеш. Камырны түгәрәкләп, пленка белән каплыйбыз һәм 30 минутка өстәлдә калдырабыз.

Шуннан соң камырны дүрткә бүләбез. Һәркайсыннан кабартма ясап, калынрак итеп җәябез. Табаны үсемлек мае яки атланмай белән майлап, манный ярмасы яки он сибәбез дә юкаларны салабыз. Өсләренә сөт сөртеп, һәркайсында өчәр тишем ясыйбыз (артык кабарып китмәсен өчен). 200 градуска җылытылган мичтә 20 минут пешерәбез. Пешеп чыккач, юкаларны үсемлек мае яки атланмай белән майлыйбыз.

Укучы киңәше

«ӘШЛӘПӘ»СЕН САЛДЫРАМ

Кайбер томат һәм борыч үсентеләренең орлык кабыгын «киеп» тишелүләре нәрсәгә бәйле? Беренчедән, орлыкларның сыйфатсыз булуына. «Эшләпә»ле генә түгел, бик нечкә сабаклы, зәгыйфь тә булып «туа» алар. Мондый үсентеләрне һич кызганмыйча йолкып ташларга кирәк. Икенчедән, орлыкларны сай чәчү дә шуңа китерә. Аларны 1,5–2 см калынлыкта туфрак белән күмеп куярга кирәк. Юкса, инде әйткәнебезчә, «эшләпә»ле үсентеләрнең шытып чыгуы көт тә тор. Ә бу аларның үсеше тоткарлый.

Кирәкмәс «баш киеме»ннән коткару өчен, томат, борычларга ничек ярдәм итәргә? Аларны көн дәвамында берничә тапкыр җылы су белән чылатып торырга кирәк. Болай эшләгәндә, орлык кабыгы үзеннән-үзе кубып төшәчәк. Аны энә ярдәмендә сак кына кубарып алырга да мөмкин. Ә менә кул белән орынырга ярамый – үсенте шиңәчәк.

Гөлфия ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА. Балык Бистәсе

Белеп тор!

Шоколады бармы?

Шоколад пастасы – балаларның иң яраткан ризыкларыннан берсе. Аны икмәккә ягып та, тундырмага өстәп тә ашыйлар. Шулай ук татлы ризыклар әзерләгәндә дә кулланыла ул. Ләкин шоколад пастасында шоколад бармы? Ул организмга файдалымы әллә зыянлымы? Гомумән, бу ризыкны ничек сайларга?

Әлеге дә баягы, составына карарга кирәк. Шоколад пастасына карата иң мөһим таләп – какао күләменең 12 проценттан ким булмавы. Махсус кибетләрдә нәкъ шундыен саталар да. Башлыча какао маеннан, уылган какао һәм атланмайдан тора ул. Шул ук вакытта аертылмаган сөт кулланылган булырга тиеш. Составында шундый сөт һәм чикләвек, шикәр комы, какао, лецитин кебек ингредиентлары булса әйбәт. Үсемлек мае, эмульгатор, ароматизатор кушылган икән, димәк, ризык табигый түгел.

Кайсы яхшырак? Белгечләр әйтүенчә, ингредиентлары азрак булганы яхшырак. Табигый эмульгатор – лецитин кушылганын алырга тырышыгыз. Чикләвегенә дә игътибар итегез. Арахисның урынына урман чикләвеге кушылганын яки әрбет чикләвеге белән эшләнгәнен, коры эремчек суы (сухая сыворотка молочная) белән түгел, ә аертылмаган коры сөттән (сухое цельное молоко) ясалганын алырга тырышыгыз. Төсенә килгәндә, никадәр коңгыртрак булса, шуның кадәр яхшырак. Әмма ул карага якын коңгырт булмаска тиеш. Андый төс какао урынына мөгезле агач (рожковое дерево) кулланылганлыгын аңлата.

Саклау вакыты. Ярты елдан бер елга кадәр. Моннан да озаграк икән, составында табигый булмаган өстәмәләр күп, дигән сүз. Ә инде ачылган банкадагы ризыкны ике атна дәвамында гына сакларга мөмкин.

КАЯ БАРАСЫҢНЫ ОНЫТМА

Сәгате суккач, иртәме-соңмы, адәм баласы бу дөньядан мәңгелеккә китәчәк. Шуңа күрә кеше һәрвакыт үлемгә әзер булырга тиеш. Бу кәфенлек әзерләүдән башланса, дөресрәктер. Мәңгелеккә төреп озата торган шушы «кием»гә нинди таләпләр бар? Аны алдан әзерләп кую кирәкме?

Кызыксындырган сорауларга Раил хәзрәт ФӘЙЗРАХМАНОВ ачыклык кертте.

:: Кәфенлекне алдан әзерләп кую үлем сәгатен якынайта, диләр. Киресенчә, гомерең озын булыр, дип сөйләүчеләр дә бар. Хәзрәт, кәфенлекне алдан әзерләп кую кирәкме?

– Үлем сәгатен якынайта дигәнне кешеләр үзләре уйлап чыгарган. Бу – хорафат, уйдырма гына. Безгә язган гомерне Аллаһы Тәгалә без туганчы ана карынында ук билгеләп куйган инде. Күпме ризык ашаячагыбыз, бәхетле булу-булмавыбыз, нинди һөнәр иясе булуыбыз, 80 яшькә кадәр яшибезме, иртәрәк вафат булабызмы – барысы да алдан билгеле. Кәфенлек алу, башка төрле гамәлләр гомерне кыскартмый да, озынайтмый да. Кәфенлек алып кую кешене уйландырырга тиеш. Әйтик, берәр кеше белән аралашмыйча йә булмаса, мәкерлек кылып йөрисең, ди. Кәфенлек алгач: «Минем дә үләсем бар бит. Мине дә шушыңа төреп куярлар. Аллаһы Тәгалә каршына басасым, хисап тотасым бар», – дип уйланырга мөмкин адәм баласы. Кәфенлек безне мөнәсәбәтләр бозылудан, начар гамәлләрдән, гөнаһлардан туктатып та кала, димәк. Пәйгамбәребез (с.г.в.): «Зиратларга ешрак йөрегез, ул сезгә үлемне искә төшерәчәк», – дигән. Үлем турында ешрак уйласаң, киресенчә, үзеңне күпчелек бозыклыклардан тыячаксың, бу дөньяга гына алданып яшәмәячәксең. Кәфенлекне алдан әзерләп кую, өйдәгеләреңнең дә синең кәфенлегең барлыгын белеп торулары яхшы. Адәм баласы, бу дөнья белән хушлашкач: «Тизрәк мине күмсеннәр иде», – дип ашыгып тора. Шуңа күрә, кәфенлек әзер икән, ашык-пошык кәфенлек эзләүләр дә булмас.

:: Кәфенлеккә таләпләр бармы? Әйтик, күпме тукыма кирәк, ул нинди булырга тиеш?

– Динебездә һәр нәрсәнең үз тәртибе һәм таләбе бар. Кәфенлек мәсьәләсе дә искәрмә түгел. Ул ак төстә булырга тиеш. Сөннәт буенча, өч чүпрәк каралган. Кәфенлекнең билгеле метражы юк. Озын кешеләр, бәләкәйләр бар. Иң мөһиме – гаурәтне каплау. Шушы таләпләр үтәлсә, хәерле.

:: Үзеңә дип токкан кәфенлекне башка кешегә бирү дөресме?

– Башка кешегә бирсәң дә була.

:: Кәфенлек саргайса, нишләргә? Яңаны аласымы? Яки юу да рөхсәт ителәме?

– Саргайса, юарга була. Ошамаса, яңаны алырга да мөмкин. Чүпрәкне игеләштерү кирәкми, хорафатларга юл ачмыйк.

islam.ru

:: Кәфенләү тәртибен дә кыскача гына аңлатсагыз иде.

– Мәетне югач, аны азрак корытсак хәерле. Кәфенлек юешләнмәсен өчен кирәк бу. Мәетне куясы җиргә кәфенлекне җәябез, иң башта беренче чүпрәк – лифафә җәелә. Аның өстенә икенче чүпрәк – изар куела. Аннан соң камис күлмәк (ахирәт күлмәге) куела. Муеннан алып аякка кадәр кешене шушы күлмәк капларга тиеш. Аннан соң изар белән гәүдә төрелә. Изарны сул яктан алып, уң якка, аннан уң яктан, сул якка каплыйбыз. Өстән лифафәне шул рәвешле төрәбез. Аннан инде мәетне бәйләп куябыз.

:: Кәфенләүдә күпме кеше катнашырга тиеш? Кәфенләүдә кулланган кирәк-яракларны соңрак нишләтергә?

– Кәфенләү вакытында берничә ярдәмче булса яхшы. Ә кулланган кирәк-яракларны ташларга мөмкин. Яисә берәр җиргә күмеп куярга. Кәфенләүдән калган кирәк-яракларны нииндидер изге әйбер дип, кешене куркытырга ярамый.

Апрель аенда намаз вакытлары

Көн саны	Көн исеме	Таң беленә башлый	Кояш чыга	Икенде намазы	Ахшам намазы	Ясту намазы
1	Шим	03:01	05:15	16:11	18:20	20:09
2	Якш	02:58	05:12	16:13	18:22	20:11
3	Дүш	02:54	05:10	16:14	18:24	20:14
4	Сиш	02:50	05:07	16:15	18:26	20:17
5	Чәрш	02:47	05:05	16:17	18:28	20:19
6	Пәнҗ	02:43	05:02	16:18	18:30	20:22
7	Җом	02:40	04:59	16:20	18:32	20:25
8	Шим	02:36	04:57	16:21	18:34	20:28
9	Якш	02:32	04:54	16:23	18:36	20:30
10	Дүш	02:28	04:52	16:24	18:38	20:33
11	Сиш	02:25	04:49	16:26	18:40	20:36
12	Чәрш	02:21	04:47	16:27	18:42	20:39
13	Пәнҗ	02:17	04:44	16:28	18:44	20:42
14	Җом	02:13	04:42	16:30	18:46	20:45
15	Шим	02:09	04:39	16:31	18:48	20:48
16	Якш	02:04	04:37	16:32	18:51	20:51
17	Дүш	02:00	04:34	16:34	18:53	20:54
18	Сиш	01:56	04:32	16:35	18:55	20:58
19	Чәрш	01:51	04:29	16:36	18:57	21:01
20	Пәнҗ	01:47	04:27	16:38	18:59	21:04
21	Җом	01:42	04:24	16:39	19:01	21:07
22	Шим	01:38	04:22	16:40	19:03	21:11
23	Якш	01:33	04:19	16:42	19:05	21:14
24	Дүш	01:28	04:17	16:43	19:07	21:18
25	Сиш	01:22	04:15	16:44	19:09	21:21
26	Чәрш	01:17	04:12	16:46	19:11	21:25
27	Пәнҗ	01:11	04:10	16:47	19:13	21:29
28	Җом	01:05	04:08	16:48	19:15	21:33
29	Шим	00:59	04:05	16:49	19:17	21:36
30	Якш	00:53	04:03	16:51	19:19	21:40

Искәрмә: өйлә намазы – 12.00 сәгатьтә.

Хикмәтле сүз

- *«Дөреслектә, Аллаһ – кешеләргә фазыйләт (рәхмәт) иясе, әмма кешеләрнең күпчелеге (тиешенчә Аңа) шөкер итми».*
- *«Әгәр Аллаһ биргән нигъмәтләрне санап карасагыз, һич санап бетерә алмассыз».*
- *«Аллаһ – барча колларын җентекләп Күрүче. Ул – алар турында барчасын Белүче».*
- *«Бер кеше бар эшен Аллаһка тапшырса, Аллаһның аның бар эшен дә үтәргә көче җитәдер. Аллаһ – Үзенең эшен җиренә җиткерүче. Аллаһ, шулай итеп, һәр эшкә чик куйды».*

Ураза көндәлеге

?Хәез вакытында ураза тотарга ярамый. Нинди гыйбадәтләр башкарырга була соң?

– Хәез – хатын-кызларда һәр ай була торган табигый күренеш. Бу чорда хатын-кыз чиста булып саналмый. Шуңа күрә дә гүзәл затлар бу вакытта ураза тотмый. Хәез вакытында зекерләр укырга, дога кылырга, яттан белгән аятьләрне укырга һәм кабатларга, тәфсирләр, дини китаплардан гыйлем алырга ярый. Хәез тәмамлангач, хатын-кыз госел ала, ягъни тулысынча юына.

pinterest.com

?Уразалы килеш спорт белән шөгыльләнсәм, ураза бозылырмы?

– Уразаны боза торган гамәлләрдән кала башка гамәлләр белән шөгыльләнү уразаны бозмас. Спорт белән шөгыльләнү, иң элек, сезгә авырлык китерергә тиеш түгел. Ураза сезгә авырлык булып тоелмасын өчен, спорт белән шөгыльләнү, организмны талчыктыра торган авыр хезмәтләрне вакытлыча кичектереп тору киңәш ителә.

?Авыз ачканда хөрмә ашыйбыз. Моның берәр хикмәте бармы? Башка җиләк-җимеш кулланырга ярамыймы?

– Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) авыз ачканда иң беренче булып хөрмә кабып куйган. Хөрмә белән авыз ачу – сөннәт гамәл. Бу җимеш бик файдалы. Шуңа күрә, көн дәвамында ач торганнан соң, аны ашап кую организм өчен файдага булыр.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА әзерләде

ӘЛЕГЕ БИТТӘ КОРЪӘН АЯТЬЛӘРЕ, ДОГАЛАР БУЛУ СӘБӘПЛЕ, КАДЕРСЕЗЛӘМӘВЕГЕЗ СОРАЛА

И туган тел, и матур тел...

Мин = милләт

Асыл

КАМИЛА АЛЕСКЕРОВА, АЗӘРБАЙҖАН, 27 ЯШЬ

Көндәлектә, туры килгән очракта, мин һәрвакыт үземнең азәрбайҗан милләтеннән булуымны әйтәм һәм милли үзенчәлекләрне кием-салымда күрсәтәм. Концертлар белән йөргәндә дә, **МИЛЛИ АТРИБУТИКА КУЛЛАНЫРГА ТЫРЫШАМ**. Әйтик, яулык (кялагаи), хары-бюльбюль (чәчәк) символы белән түштамга. Телефон чехолында да азәрбайҗан әләме һәм гербы сурәтләнгән.

ГАИЛӘДӘ ТРАДИЦИЯЛӘР САКЛАНА. Шулай килеп чыкты: минем әти – азәрбайҗан, әни – грузин милләтеннән. Моңа да карамастан, без ике якның да барлык бәйрәмнәрен билгеләп үтәбез. Моның белән **ГОРУРЛАНАМ!** Һәр бәйрәм – зур өстәл, мул табын.

ТУГАН-ТУМАЧАЛАР БЕЛӘН АЗӘРБАЙҖАН ТЕЛЕНДӘ СӨЙЛӘШӘМ. Рус телен белсәләр дә! Казандагы азәрбайҗаннар диаспорасы вәкилләре белән дә телне югалтмаска, сакларга тырышабыз.

Милләт белән горурлану өчен сәбәпләр булырга тиеш түгел! **УЛ АНА СӨТЕ БЕЛӘН КИЛЕРГӘ ТИЕШ!** Кешене нәрсә өчендер яратмыйсың бит. Милләт белән дә шулай ук. Ул ярату – минем канымда!

Халыклар дуслыгы йортында Якшәмбе мәктәбе эшли. Анда төрле милләт вәкилләре үз телләрен, тарихын өйрәнә. Үземнең балаларымны да шул мәктәпкә йөртер идем. Андагы чаралар ярдәмендә **КҮП НӘРСӘГӘ ӨЙРӘНЕП БУЛА.**

ТАТАРСТАННЫ ЯРАТАМ. УЛ ДА – МИНЕМ ВАТАНЫМ. Мөслим Магомаев әйтмешли, Азәрбайҗан – минем атам, Россия – минем анам. Мин хәтта Татарстан – минем анам, дияр идем. Ул миңа белем бирде, шәхес буларак үстерде.

Телне белмәсәк, тамырларыбызны, мәдәниятебезне, традицияләребезне белмәячәкбез бит. **ТЕЛ УЛ – НИГЕЗ. УЛ – ЭТӘРГЕЧ.**

БЕЗНЕҢ ХАЛЫК КУНАКЧЫЛ. Кешеләр арасындагы мөнәсәбәт – минем өчен иң кадерлесе.

Камила милли аш-су белән дә таныштырды. Бу сурәттә иннаб, шекербура (азәрбайҗаннарның баллы сые), пәхләвә, бадамбура (шулай ук баллы ризык), шор гогал (камыр ризыгы) кебек ризыкларны күрергә мөмкин.

Камила – актриса. «Созвездие – Йолдызлык» үзәгендә труппага җитәкчелек итә. Ул җырларга ярата. Юридик факультетның аспирантурасында укырга да өлгерә.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА әзерләде. Фото: Анна АРАХАМИЯ

5 апрель | Чәршәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 16+
07.00, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
09.00 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ» 16+
10.00, 23.00 «ВТОРАЯ ЖИЗНЬ» 16+
11.00 «Каравай» 6+
11.30, 16.00 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «ТӨЛКЕ ЕЛМАЮЫ» 12+
13.00 «Җырлыйк әле!»12+
14.00 «Туган авылым» 12+
14.15 «Если хочешь быть здоровым» 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан»16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Бергәләп өйрәник» 0+
16.30 Хоккей. Кубок Гагарина. Матч серии play-off. «Авангард» – «Ак барс». Прямая трансляция 0+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Татар сүзе» 0+
21.00 «Соотечественники» 16+
00.00 «Соотечественники». Рустем Яхин. Жизнь как музыка 16+
00.25 «Таяну ноктасы» 16+
00.50 «Каравай». Музей уездного города 6+
01.15 «Җырлыйк әле!» 12+
02.00 «Манзара» 16+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 16+
04.45 «Җырлыйк әле!» 12+
05.35 «Оныта алмыйм...» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00 «Уткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 23.10, 05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
09.40 «Йөрәктән – йөрәккә». Татарстанның халык артисты Равил Шәрәфиев турында телеочерк 16+
10.40 «Туган авылым» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Татарлар» 12+
12.05, 18.20, 21.25 «АЛМАШ». Телесериал 16+
15.25 «Таяну ноктасы» 16+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан» 16+
17.30 «Татарлар» 12+
19.15 «Музыкаль мәйдан» 16+
19.35 «Татарлар» 12+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.30 «Ватандашлар». Равил Шәрәфиев. «Әлеге юлны мин узем сайладым» (субтитрлы) 16+
22.20, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
00.15 «Яшьләр тукталышы» 6+
00.40 «Татарлар» 12+
02.50 «Караоке татарча» 12+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
04.20 «Әниемнең җылы кочагы» 16+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
20.00 Премьера. «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
21.45 «ШПИОН» (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
23.45 «ПОЧКА» (S) 18+
00.15 ПОДКАСТ.ЛАБ «Психика» 16+
00.55 ПОДКАСТ.ЛАБ «Креативные индустрии» 16+
01.35 ПОДКАСТ.ЛАБ «Обязательно к прочтению» 16+
02.15 ПОДКАСТ.ЛАБ «Гори огнем» 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «По Первое число» 16+
03.45 ПОДКАСТ.ЛАБ «Антропология» 16+
04.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Все хотят летать» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Татьяна Лялина, Нил Кропалов, Алексей Анищенко, Олег Фомин, Ольга Кабо, Анна Большова, Вадим Андреев, Алёна Коломина, Александр Тютин. «ЗА-ПОЛЯРНЫЙ ВАЛЬС» 12+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 Детективный телесериал «ДУЭТ ПО ПРАВУ» 12+
03.55 Вячеслав Разбегаев, Кирилл Плетнёв, Наталия Быстрова, Анна Гарнова. «ПЫЛЬНАЯ РАБОТА» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 14.25 «Спортивный век» 12+
06.30 «Ты в бане!» 12+
07.00, 08.35, 12.55, 14.55 Новости
07.05, 15.30, 18.45, 21.30, 00.00 Все на Матч! Прямой эфир
08.40 Биатлон. Pari Чемпионат России. Марафон. Мужчины. Прямая трансляция из Увата
12.05 «География спорта. Сахалин» 12+
12.35 Специальный репортаж 12+
13.00 «Есть тема!» Прямой эфир
15.00 «Вид сверху» 12+
16.15 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. Финал конференции «Восток». «Авангард» (Омск) – «Ак барс» (Казань). Прямая трансляция
19.00 Футбол. FONBET Кубок России. 1/2 финала. ЦСКА – «Крылья Советов» (Самара). Прямая трансляция
21.55 Футбол. Кубок Испании. 1/2 финала. «Барселона» – «Реал» (Мадрид). Прямая трансляция
01.00 Биатлон. Pari Чемпионат России. Марафон. Мужчины. Трансляция из Увата 0+
02.00 Баскетбол. Единая лига ВТБ. 1/4 финала. «Локомотив-Кубань» (Краснодар) – «Пари НН» (Нижний Новгород) 0+
03.55 Новости 0+
04.00 Волейбол. Чемпионат России. Pari Суперлига. Женщины. 1/4 финала. «Локомотив» (Калининградская область) – «Тулица» (Тульская область) 0+

НТВ

04.50 Сериал «ПОБЕДИТЕЛИ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. РУБЕЖИ РОДИНЫ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 Премьера. Детективный сериал «СТРАЖНИК» (S) 16+
22.15, 00.00 «НЕВСКИЙ. ОХОТА НА АРХИТЕКТОРА» (S) 16+
00.45 «УГРО» (S) 16+
04.05 «Таинственная Россия» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.00 «Давай разведёмся!» 16+
09.00 «Тест на отцовство» 16+
11.15 «Понять. Простить» 16+
12.25 «Порча» 16+
12.55 «Знахарка» 16+
13.30 «Верну любимого» 16+
14.05 «Голоса ушедших душ» 16+
14.40 «НАСЛЕДСТВО» 16+
19.00 «ПЕРВАЯ ЛЮБОВЬ» 16+
23.00 «СЛУЧАЙНЫЕ ВСТРЕЧИ» 16+
02.35 «Порча» 16+
03.00 «Знахарка» 16+
03.25 «Верну любимого» 16+
03.55 «Голоса ушедших душ» 16+
04.20 «Понять. Простить» 16+
05.10 «6 кадров» 16+
05.25 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.10 «БЕЛЫЕ ВОЛКИ». 21-я и 22-я серии 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.20, 01.05 «ГОЛУБЫЕ МОЛНИИ» 12+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.20, 15.05 «БЕЛЫЕ ВОЛКИ». 23-я – 26-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
18.20 «Специальный репортаж» 16+
18.55 «Бог войны. История русской артиллерии». Документальный сериал. Фильм 7-й 16+
19.40 «Секретные материалы» 16+
22.55 «Между тем» 12+
23.25 «КАЗАЧЬЯ ЗАСТАВА» 12+
02.30 «После премьеры – расстрел. История одного предательства». Документальный фильм 12+
03.15 «Москва – фронту». Документальный сериал 16+
03.35 «БЕЛЫЕ ВОЛКИ». 23-я и 24-я серии 16+

6 апрель | Пәнҗешәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
09.00 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ» 16+
10.00, 23.00 «ВТОРАЯ ЖИЗНЬ» 16+
11.00 «Каравай» 6+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «ТӨЛКЕ ЕЛМАЮЫ» 12+
13.00 «Кәмит Җәвит» 16+
14.00 «Туган авылым» 12+
14.15 «Рыцари вечности» 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Шома бас» һәм «Алты хәреф» 0+
16.00 «Ватандашлар» 16+
17.00 «БӘХЕТЛЕМЕ СИН?» 16+
18.00 «Татар сүзе» 0+
19.00, 20.00 «Точка опоры» 16+
21.00 «Погружение на 100» 12+
21.10 «Соотечественники» 16+
22.00 «Вызов 112» 16+
23.50 «Видеоспорт» 16+
00.15 «Соотечественники». Альтер Литвин. Реабилитированный дважды 16+
00.40 «Каравай». Лоскутное шитье 6+
01.05 «Башваткыч» 12+
02.00 «Манзара» 16+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 16+
04.45 «Кәмит Җәвит» 16+
05.35 «Оныта алмыйм...» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00 «Уткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 23.10, 04.15 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
09.40 «Кунак БиТ шоу» 16+
10.40 «Туган авылым» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Татарлар» 12+
12.05, 18.20, 21.25 «АЛМАШ» 16+
15.25 «Таяну ноктасы» 16+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан» 16+
17.30 «Татарлар» 12+
19.15 «Музыкаль мәйдан» 16+
19.35 «Татарлар» 12+
20.00 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
22.20, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
00.15 «Юлчы» (субтитрлы) 16+
00.40 «Татарлар» 12+
02.50 «Караоке татарча» 12+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 16+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
20.00 «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
21.45 «ШПИОН» (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
23.45 «ПОЧКА» (S) 18+
00.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Кот Шрёдингера» 16+
01.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Космические истории» 16+
01.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «Собрались с мыслями» 16+
02.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Первые лица» 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Жизнь замечательных» 16+
03.45 ПОДКАСТ.ЛАБ «АстроУмные» 16+
04.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Неформат» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Татьяна Лялина, Нил Кропалов, Алексей Анищенко, Олег Фомин, Ольга Кабо, Анна Большова, Вадим Андреев, Алёна Коломина, Александр Тютин. «ЗА-ПОЛЯРНЫЙ ВАЛЬС» 12+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 Детективный телесериал «ДУЭТ ПО ПРАВУ» 12+
03.55 Вячеслав Разбегаев, Кирилл Плетнёв, Наталия Быстрова, Анна Гарнова, Андрей Арзяев, Дмитрий Ермак. «ПЫЛЬНАЯ РАБОТА» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 14.25 «Спортивный век» 12+
06.30 «Вид сверху» 12+
07.00, 08.35, 12.55, 14.55, 18.05 Новости
07.05, 15.30, 19.10, 22.00, 00.30 Все на Матч! Прямой эфир
08.40 Биатлон. Pari Чемпионат России. Марафон. Женщины. Прямая трансляция из Увата.
11.50, 04.00 Футбол. Кубок Испании. 1/2 финала. «Барселона» – «Реал» (Мадрид) 0+
12.35 Специальный репортаж 12+
13.00 «Есть тема!» Прямой эфир
15.00 «Большой хоккей» 12+
16.15 «Марадона. Смерть бога». Документальный фильм 16+
18.10 «Вы это видели» 12+
19.45 Футбол. FONBET Кубок России. 1/2 финала. «Краснодар» – «Ростов» (Ростов-на-Дону). Прямая трансляция
22.45 Профессиональный бокс. Тим Цзю против Тони Харрисона. Бой за титул чемпиона мира по версии WBO. Трансляция из Австралии 16+
00.00 Автоспорт. СМП РСКГ Эндуранс. Кубок России. Трансляция из Сочи 0+
01.00 Биатлон. Pari Чемпионат России. Марафон. Женщины. Трансляция из Увата 0+
02.00 Баскетбол. Единая лига ВТБ. 1/4 финала. МБА (Москва) – «Зенит» (Санкт-Петербург) 0+
03.55 Новости 0+

НТВ

04.50 Сериал «ПОБЕДИТЕЛИ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. РУБЕЖИ РОДИНЫ» (S) 16+
11.00 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ» 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00, 00.00 Остросюжетный детектив «НЕВСКИЙ. ОХОТА НА АРХИТЕКТОРА» (S) 16+
00.45 «Поздняков» 16+
01.00 «Мы и наука. Наука и мы» 12+
01.50 Остросюжетный сериал «УГРО» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.10 «Давай разведёмся!» 16+
09.10 «Тест на отцовство» 16+
11.25 «Понять. Простить» 16+
12.30 «Порча». «Разбитая чашка» 16+
13.00 «Знахарка» 16+
13.35 «Верну любимого» 16+
14.10 «Голоса ушедших душ» 16+
14.45 «СЕРДЦЕ РИТЫ» 16+
19.00 «СУРРОГАТНАЯ МАТЬ» 16+
23.25 «ТЫ МОЙ» 16+
02.50 «Порча» 16+
03.15 «Знахарка» 16+
03.40 «Верну любимого» 16+
04.10 «Голоса ушедших душ» 16+
04.35 «Понять. Простить» 16+
05.25 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.10 «БЕЛЫЕ ВОЛКИ». 25-я и 26-я серии 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.20, 01.20 «ВСАДНИК БЕЗ ГОЛОВЫ» 12+
11.20, 21.15 «Открытый эфир» 16+
13.20, 18.20 «Спецрепортаж» 16+
14.05, 15.05 «ЧЕРНЫЕ БЕРЕТЫ» 16+
15.00 Военные новости 16+
15.50 «ДРУЖБА ОСОБОГО НАЗНАЧЕНИЯ» 16+
18.55 «Бог войны. История русской артиллерии». Документальный сериал. Фильм 8-й 16+
19.40 «Код доступа» 12+
22.55 «Между тем» 12+
23.25 «ЛЕКАРСТВО ПРОТИВ СТРАХА» 12+
02.55 «КАЗАЧЬЯ ЗАСТАВА» 12+
04.15 «ВНИМАНИЕ! ВСЕМ ПОСТАМ...» 12+
05.30 «Хроника Победы». Документальный сериал 16+

7 апрель | Җомга

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Вести Приволжского федерального округа»
09.15 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.15 «Вести-Татарстан

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 16+
07.00, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 Утренняя программа «Здравствуйте!»16+
09.00 «Яланаяклы кыз». Телесериал 16+
10.00 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
11.00 «Нәсыйхәт» 16+
11.30, 16.00 «Татарлар» 12+
12.00 «Көн сәгате» 16 +
13.00 «Башваткыч» 12+
14.00 «Актуальный ислам» 16+
14.15 «Здоровая семья: мама, папа и я» 12+
14.45 «Музыкаль мәйдан» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Тизрәк! Алга! Житезрәк!» һәм «Алты хәреф» 0+
16.30 Хоккей. Кубок Гагарина. Матч серии play-off. «Авангард» – «Ак барс». Прямая трансляция 0+
19.00 «Туган җир» 12+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Татар сүзе» 0+
21.00 «Юлчы» 16+
22.10 «РОЖДЕСТВО В ШОКОЛАДЕ» 16+
23.45 «ПОХИЩЕНИЕ ЧАРОДЕЯ» 12+
01.25 «Каравай». Народная игрушка 6+
01.50 «ЯҢА ЕЛДА БЕРГӘ БУЛЫЙК!» 12+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 16+
04.45 «Башваткыч» 12+
05.35 «Оныта алмыйм...» Ретро-концерт 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05 «Манзара» 16+
08.00 «Уткәннәр сагындыра» 12+
08.50, 23.10, 04.15 «Көн сәгате» 16+
09.50, 15.25, 00.15 «Нәсыйхәт» 16+
10.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Татарлар» 12+
12.05 «Уроки истории» 6+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан» 16+
17.30 «Татарлар» 12+
18.20 «Җыр ул – хиснең балкышы!» Шагыйрь Наил Касыймов турында телеочерк 16+
19.15 «Музыкаль мәйдан» 16+
19.35 «Татарлар» 12+
20.00 «Туган җир» 12+
20.30 «Заман көзгесе» 6+
21.25 «Уроки истории» 6+
22.10, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
00.40 «Татарлар» 12+
01.05 Ш.Хөсәенов. «ЗӨБӘЙДӘ – АДӘМ БАЛАСЫ». Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле 16+
03.20 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 16+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.40 «Человек и закон» с Алексеем Пимановым 16+
19.45 «Поле чудес» (S) 16+
21.00 «Время»
21.45 Премьера. «ГОЛОС» весны в обновленном составе (S) 12+
23.30 «Вызов. Первые в космосе» (S) 12+
00.30 ПОДКАСТ.ЛАБ «20 лет спустя» 16+
01.10 ПОДКАСТ.ЛАБ «Неформат» 16+
01.50 ПОДКАСТ.ЛАБ «Психика» 16+
02.30 ПОДКАСТ.ЛАБ «Креативные индустрии» 16+
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Легкие деньги» 16+
03.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «Гори огнем» 16+
04.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Пусть не говорят, пусть читают» 16+
04.55 ПОДКАСТ.ЛАБ «Триггеры» 16+
05.30 ПОДКАСТ.ЛАБ «Анекдоты» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Прямой эфир» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.15 Местное время. Вести-Татарстан
21.30 Премьера. «Моя мелодия» 12+
23.35 Премьера. «Улыбка на ночь». Программа Евгения Петросяна 16+
00.40 Марина Денисова, Андрей Фролов, Татьяна Лютаева, Святослав Астрамович, Олег Ткачёв. «СОН КАК ЖИЗНЬ» 12+
03.50 Вячеслав Разбегаев, Кирилл Плетнёв, Наталия Быстрова, Анна Гарнова, Андрей Арзяев, Дмитрий Ермак. «ПЫЛЬНАЯ РАБОТА» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 14.25 «Спортивный век» 12+
06.30 «География спорта. Сахалин» 12+
07.00, 14.55 Новости
07.05, 15.30, 18.45, 22.00, 00.30 Все на Матч! Прямой эфир
10.20 Специальный репортаж 12+
10.40 Лыжные гонки. Кубок России. Финал. Женщины. 10 км. Прямая трансляция из Кировска
12.20 Лыжные гонки. Кубок России. Финал. Мужчины. 15 км. Прямая трансляция из Кировска
14.05 «Лица страны. Светлана Бажанова» 12+
15.00 «Здоровый образ. Хоккей» 12+
16.15 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. Финал конференции «Восток». «Авангард» (Омск) – «Ак барс» (Казань). Прямая трансляция
19.55 Футбол. Прямая трансляция
22.30 Профессиональный бокс. Игорь Михалкин против Артура Осипова. Прямая трансляция из Москвы
01.00 «РецепТура» 0+
01.30 «Третий тайм» 12+
02.00 Баскетбол. PARI Чемпионат России – Премьер-лига. Женщины. 1/2 финала 0+
03.55 Новости 0+
04.00 «Реал» Мадрид. Кубок №12». Документальный фильм 12+

НТВ

04.50 Сериал «ПОБЕДИТЕЛИ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня»
08.25, 10.35 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ» 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «ДНК» 16+
17.55 «Жди меня» 12+
20.00 Остросюжетный детектив «НЕВСКИЙ. ОХОТА НА АРХИТЕКТОРА» (S) 16+
00.00 «Своя правда» с Романом Бабаяном 16+
01.55 «Захар Прилепин. Уроки русского» 12+
02.20 «Квартирный вопрос» 0+
03.10 Остросюжетный сериал «УГРО» (S) 16+
04.45 «Их нравы» 0+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.05 «Давай разведёмся!» 16+
09.05 «Тест на отцовство» 16+
11.20 «Понять. Простить» 16+
12.25 «Порча». «В тени» 16+
12.55 «Знахарка» 16+
13.30 «Верну любимого» 16+
14.05 «Голоса ушедших душ» 16+
14.40 «ПЕРВАЯ ЛЮБОВЬ» 16+
19.00 «КРАСОТА НЕБЕСНАЯ» 16+
23.05 «ПРОПАСТЬ МЕЖДУ НАМИ» 16+
02.40 «Порча». «Ночная жизнь» 16+
03.05 «Знахарка» 16+
03.30 «Верну любимого» 16+
04.00 «Голоса ушедших душ» 16+
04.25 «Понять. Простить» 16+
05.15 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

06.00, 09.20, 13.20 «ГАИШНИКИ». Фильмы 1-й – 3-й 16+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
14.05, 15.05 «ГАИШНИКИ». Фильм 4-й 16+
15.00 Военные новости 16+
16.40, 18.40 «СТО ДНЕЙ СВОБОДЫ». 1-я – 4-я серии 16+
22.00 «Здравствуйте, товарищи!» Премьера! 16+
23.00 «Музыка+». Премьера! 12+
00.10 «АПАЧИ» 12+
01.55 «УЛЬЗАНА» 12+
03.25 «ПО ДАННЫМ УГОЛОВНОГО РОЗЫСКА...» 12+
04.40 «ЛЕКАРСТВО ПРОТИВ СТРАХА» 12+

8 апрель | Шимбә

ТАТАРСТАН

08.00 «Вести-Татарстан»
08.20 Местное время. Суббота

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
07.00 «Сиңа Миннән Сәлам». Музыкаль котлаулар 16+
09.00 «Әй, язмыш, язмыш...» Рузия Мотыйгуллина 16+
10.00 «Кайнар хит» 16 +
11.00 «Туган авылым» 12+
11.30 «Казаннан – Казанга» 16+
12.00 «Каравай» 6+
12.30 «Видеоспорт» 16+
13.00 «Созвездие – Йолдызлык-2023» 6+
14.00 «Мәңгелек юлында». Мөхәммәт Мирзаның 70 яшьлек юбилей кичәсе 12+
16.00 «Уроки истории» 6+
17.00 «Татар халык җырлары» 0+
17.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
18.00 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
19.00 «Tatarstan today. Открытый мир» 16+
19.30 Новости в субботу 16+
20.00 «Адымнар» 16+
20.30 «Җырлыйк әле!» 12+
21.30 Новости в субботу 16+
22.00 «Кунак БиТ шоу» 16+
23.00 «ЧЕЛОВЕК ИЗ РИО» 16+
01.00 «Каравай» 6+
01.25 «Вехи истории». Победа – одна на всех 16+
01.50 Раяз Фасыйхов концерты 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 16+
04.45 «Кәмит Җәвит» 16+
05.35 «Оныта алмыйм...» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00 «Йөрәктән – йөрәккә». Айрат Арсланов турында телеочерк 16+
07.00, 15.00 «Сиңа Миннән Сәлам» 16+
09.00 «Кунак БиТ шоу» 16+
10.00 «Кайнар хит» 16+
11.00, 18.15, 03.00 «Башваткыч» 12+
12.05 «Җырлыйк әле!» 12+
13.00 «Туган авылым» 12+
13.20 «Кайда сез, яшьлек еллары». Зөһрә Шәрифуллина концерты 16+
17.20 «Музыкаль мәйдан» 16+
17.45 «Халкым минем» 12+
19.05 «Җырлыйк әле!» 12+
20.00 «Адымнар» 16+
20.30 «Язмышларым сиңа бәйләнгән». Татарстанның халык артисты Рөстәм Закиров концерты 16+
22.15 «Алмаш». Телесериал 16+
01.45 «Җыр ул – хиснең балкышы!» Шагыйрь Наил Касыймов турында телеочерк 16+
03.50 «Җырлыйк әле!» 12+
04.40 «Йолдыз» (субтитрлы) 16+
05.05 «Халкым минем» 12+
05.30 «Нәсыйхәт» 16+

1 КАНАЛ

06.00 Телеканал «Доброе утро. Суббота»
09.00 «Умницы и умники» 12+
09.45 «Слово пастыря» 0+
10.00 Новости (с субтитрами)
10.15 Премьера. «Поехали!» 12+
11.10 Премьера. «ПроУют» (S) 0+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 «Видели видео?» 0+
13.40 «ПО ЗАКОНАМ ВОЕННОГО ВРЕМЕНИ 3». Многосерийный фильм (S) 12+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Премьера. Концерт к 85-летию Ильи Резника. «Юбилейный вернисаж» (S) 12+
21.00 «Время»
21.35 «Сегодня вечером» 16+
23.35 Оливье Гурме в фильме «Сирано. Успеть до премьеры» (S) 16+
01.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «По Первое число» 16+
02.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Жизнь замечательных» 16+
02.55 ПОДКАСТ.ЛАБ «Мелодии моей жизни» 16+
03.35 ПОДКАСТ.ЛАБ «Произвольная программа» 16+
04.10 ПОДКАСТ.ЛАБ «Обязательно к прочтению» 16+
04.45 ПОДКАСТ.ЛАБ «Анекдоты» 16+
05.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Легкие деньги» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России. Суббота»
08.00 Местное время. Вести-Татарстан
08.20 Местное время. Суббота
08.35 «По секрету всему свету»
09.00 «Формула еды» 12+
09.25 «Пятеро на одного»
10.10 «Сто к одному». Телеигра
11.00, 17.00, 20.00 Вести
12.00 «Доктор Мясников». Медицинская программа 12+
13.05 Ирина Антоненко, Станислав Бондаренко, Дмитрий Исаев, Алексей Суренский. «ЗОЛОТАЯ КЛЕТКА» 16+
18.00 «Привет, Андрей!» Вечернее шоу Андрея Малахова 12+
21.00 Премьера. Марина Коняшкина, Антон Денисенко, Анастасия Веденская, Никита Лобанов, Ирина Таранник. «ПОСЛЕДНИЙ ШАНС» 12+
00.35 Екатерина Данилова, Михаил Химичев. «ЧЕРЕЗ БЕДЫ И ПЕЧАЛИ» 12+
03.50 Лидия Милюзина, Кирилл Плетнёв, Лянка Грыу, Станислав Бондаренко. «ИЩУ ТЕБЯ» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 «Всё о главном» 12+
06.30 «Магия большого спорта» 12+
07.00, 13.30, 16.00, 21.30 Новости
07.05, 13.35, 16.05, 23.45 Все на Матч! Прямой эфир
08.55, 10.55 Лыжные гонки. Кубок России. Финал. Спринт. Прямая трансляция из Кировска.
10.30 «Спортландия». Мультипликационный фильм 0+
10.45 «Талант и поклонники». Мультипликационный фильм 0+
13.55 Баскетбол. Единая лига ВТБ. 1/4 финала. Прямая трансляция
16.45 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. Финал конференции «Запад». Прямая трансляция
19.15 Футбол. МИР Российская Премьер-Лига. «Спартак» (Москва) – «Динамо» (Москва). Прямая трансляция
21.40 Футбол. Чемпионат Италии. «Лацио» – «Ювентус». Прямая трансляция
00.30 Смешанные единоборства. АСА. Махарбек Каргинов против Жосиеля Сильвы. Трансляция из Белоруссии 16+
02.00 Футбол. Чемпионат Германии. «Фрайбург» – «Бавария» 0+
03.55 Новости 0+
04.00 «Вы это видели» 12+
05.00 Смешанные единоборства. UFC. Алекс Перейра против Исраэля Адесаньи. Прямая трансляция из США

НТВ

05.05 «Жди меня» 12+
05.50 Остросюжетный сериал «ВИ-ЖУ-ЗНАЮ» 16+
07.25 «Смотр» 0+
08.00, 10.00, 16.00 «Сегодня»
08.20 «Поедем, поедим!» 0+
09.20 «Едим дома» 0+
10.20 «Главная дорога» 16+
11.00 «Живая еда» с Сергеем Малозёмовым 12+
12.00 «Квартирный вопрос» 0+
13.00 «Модный vs Народный» 12+
14.20 «Своя игра» 0+
15.20 «Игры разумов» 0+
16.20 «ЧП. Расследование» 16+
17.00 «Следствие вели...» 16+
19.00 «Центральное телевидение» с Вадимом Такменевым.
20.20 «Страна талантов». Новый сезон (S) 12+
23.00 «Ты не поверишь!» 16+
00.00 «Международная пилорама» с Тиграном Кеосаяном 18+
00.45 «Квартирник НТВ у Маргулиса». День цыган (S) 16+
02.10 «Дачный ответ» 0+
03.05 Остросюжетный сериал «УГРО» (S) 16+
04.35 «Их нравы» 0+

ДОМАШНИЙ

06.30 «АКВАМАРИН» 16+
09.45 «Пять ужинов» 16+
10.00 «КАТЯ И БЛЭК». 1-я – 8-я серии 16+
19.00 «ВЕТРЕНЫЙ». 236-я – 242-я серии 16+
00.45 «ЛЮБОВЬ С ЗАКРЫТЫМИ ГЛАЗАМИ» 16+
03.50 «ОТ НЕНАВИСТИ ДО ЛЮБВИ». 1-я – 3-я серии 16+
06.15 «6 кадров» 16+

ЗВЕЗДА

06.10 «КОГДА Я СТАНУ ВЕЛИКАНОМ» 12+
08.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
08.15 «Морской бой» 6+
09.15 «Маршалы Сталина». Документальный сериал. Родион Малиновский 16+
10.05 «МАРЬЯ-ИСКУСНИЦА» 6+
11.45 «Легенды музыки». «Музыка из фильма "Обыкновенное чудо"» 12+
12.10 «СССР. Знак качества» с Иваном Охлобыстиным» 12+
13.15 «Не факт!» 12+
13.40 «Война миров» 16+
14.30 «Легенды науки». Валентин Глушко 12+
15.15 «Время героев». Премьера! 16+
15.35 «Главный день». «Чемпионат мира-1954 и Владимир Егоров» 16+
16.20 «Мотоциклы Второй Мировой войны». Документальный фильм 16+
18.30 «ПЕТРОВКА, 38» 12+
20.35 «ОГАРЕВА, 6» 12+
22.30 Всероссийский вокальный конкурс «Звезда-2023». Отборочный тур. Премьера! 6+
23.45 «Десять мгновений». Александр Залдастанов. Премьера! 12+
00.30 «СВЕТ В КОНЦЕ ТОННЕЛЯ» 12+
02.10 «КЛЮЧИ ОТ РАЯ» 12+
03.45 «АЛЕКСАНДР МАЛЕНЬКИЙ» 12+
05.20 «Сделано в СССР» 12+

9 апрель | Якшәмбе

ТАТАРСТАН

08.00 Местное время. Воскресенье

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00 «Син минем тиң ярым». Зинира һәм Ризат Рамазановлар 12+
08.00 «Адымнар» 16+
08.30 «Полосатая зебра» 0+
08.45 «Әти һәм мин» 0+
09.15 «Тамчы-шоу» 0+
09.45 «Яшьләр тукталышы» 0+
10.15 «Ачыктан-ачык» 16+
11.00 «Туган авылым» 12+
11.30 «Тархан». Историко-культурный конкурс для старшеклассников 12+
12.00 «Каравай» 6+
12.30 «Закон. Парламент. Общество» 16+
13.00 «Адымнар» 16+
13.30 «Погружение на 100» 12+
13.40 «Музыкаль мәйдан» 16+
14.00 «Созвездие – Йолдызлык-2023» 6+
15.00 «Татар сүзе» халыкара нәфис сүз телевизион бәйгесенең гала-концерты 6+
17.00 «Әнинемнең җылы кочагы» 16+
18.00 «Ком сәгате» 16+
19.00, 22.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 16+
20.00 «Заман көзгесе» 6+
20.30 «Болгар радиосы» концерты 12+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш...» Рузия Мотыйгуллина 16 +
23.00 «СКАНДАЛЬНОЕ ПРОИСШЕСТВИЕ В БРИКМИЛЛЕ» 12+
01.10 «Видеоспорт» 16+
01.35 «Татар халык җырлары» 0+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00 «Заман көзгесе» 6+
06.30 «Музыкаль мәйдан» 16+
07.00 «Адымнар» 16+
07.30 «Күңелемдә яз». Георгий Ибушев концерты 16+
09.00 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
10.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
10.30 «Калеб» 6+
11.10 «Тамчы-шоу» 6+
11.40 «Бергәләп өйрәник» 6+
12.05 «Яшьләр тукталышы» 6+
12.35 «Халкым минем» 12+
13.00 «Туган авылым» 12+
13.20 «Казанның кадерле кичләре». Татарстанның халык артисты Зөһрә Сәхәбиева концерты 6+
15.10 «Йөрәктән – йөрәккә». Айрат Арсланов турында телеочерк 16+
16.05 «Музыкаль мәйдан» 16+
16.20 «Әнинемнең җылы кочагы» 16+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
18.10 «Кәмит Җәвит» 16+
19.05 «Ком сәгате» 16+
20.00 «Семь дней» 16+
21.00 «Әнинемнең җылы кочагы» 16+
21.50 З. Хәким. «Утрау». Әлмәт татар дәүләт драма театры спектакле 16+
23.45 «Ком сәгате» 16+
00.40 «Яшьләр тукталышы» 6+
01.05 «Манзара» 16+
02.45 «Адымнар» 16+
03.15 Н. Исәнбәт. «ХУҖА НАСРЕТДИН». К. Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры спектакле 16+

1 КАНАЛ

06.00 Новости
06.10 ПОДКАСТ.ЛАБ «Космические истории» 16+
06.55 «Играй, гармонь любимая!» (S) 12+
07.40 «Часовой» (S) 12+
08.15 «Здоровье» 16+
09.20 «Мечталлион» (S) 12+
09.40 «Непутевые заметки» 12+
10.00 Новости (с субтитрами)
10.15 «Жизнь других» (S) 12+
11.10 «Повара на колесах» 12+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 «Видели видео?» 0+
13.50 К 90-летию Жан-Поля Бельмондо. «Бельмондо глазами Бельмондо» 16+
15.50 «Век СССР». Серия 5. «Запад». Часть 2 16+
17.00 Памяти Владимира Жириновского. «Прямая речь» 12+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
19.00 «Две звезды. Отцы и дети». Новый сезон (S) 12+
21.00 «Время»
22.35 «Что? Где? Когда?» Весенняя серия игр (S) 16+
23.45 «На футболе» (S) 18+
00.15 ПОДКАСТ.ЛАБ «Триггеры» 16+
00.55 ПОДКАСТ.ЛАБ «Антропология» 16+
01.35 ПОДКАСТ.ЛАБ «Первые лица» 16+
02.15 ПОДКАСТ.ЛАБ «Кот Шрёдингера» 16+
02.55 ПОДКАСТ.ЛАБ «Собрались с мыслями» 16+
03.35 ПОДКАСТ.ЛАБ «20 лет спустя» 16+
04.10 ПОДКАСТ.ЛАБ «Неформат» 16+

РОССИЯ 1

06.10 Наталья Бурмистрова, Дмитрий Муляр. «ПОЦЕЛУЕВ МОСТ» 12+
08.00 Местное время. Воскресенье
08.35 «Когда все дома»
09.25 «Утренняя почта»
10.10 «Сто к одному»
11.00 Вести
12.00 Премьера. «Большие перемены»
13.05 «ЗОЛОТАЯ КЛЕТКА» 16+
17.00 Вести
18.00 Премьера. «Песни от всей души». Вечернее шоу Андрея Малахова 12+
20.00 Вести недели
22.00 Москва. Кремль. Путин
22.40 «Воскресный вечер» 12+
01.30 «ПОЦЕЛУЕВ МОСТ» 12+

МАТЧ ТВ

06.00 Смешанные единоборства. UFC. Алекс Перейра против Исраэля Адесаньи. Прямая трансляция из США
08.00, 13.05, 16.00 Новости
08.05, 13.10, 16.05, 23.10 Все на Матч! Прямой эфир
10.20 «Команда МАТЧ». Анимационный сериал 0+
10.40 Лыжные гонки. Кубок России. Финал. Гонка преследования. Женщины. Прямая трансляция из Кировска
11.50 Лыжные гонки. Кубок России. Финал. Гонка преследования. Мужчины. Прямая трансляция из Кировска
13.45 Футбол. МИР Российская Премьер-Лига. «Сочи» – «Крылья Советов» (Самара). Прямая трансляция
16.45 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. Финал конференции «Восток». «Ак барс» (Казань) – «Авангард» (Омск). Прямая трансляция
19.15 Футбол. МИР Российская Премьер-Лига. «Локомотив» (Москва) – «Зенит» (Санкт-Петербург). Прямая трансляция
22.00 После футбола с Георгием Черданцевым
23.00, 03.55 Новости 0+
00.00 Смешанные единоборства. UFC. Алекс Перейра против Исраэля Адесаньи. Трансляция из США 16+
02.00 Футбол. Чемпионат Германии. «Боруссия» (Дортмунд) – «Унион» 0+
04.00 Волейбол. Чемпионат России. Pari Суперлига. Женщины. 1/4 финала. «Тулица» (Тульская область) – «Локомотив» (Калининградская область) 0+

НТВ

04.55 Остросюжетный сериал «ВИ-ЖУ-ЗНАЮ» 16+
06.35 «Центральное телевидение» 16+
08.00, 10.00, 16.00 «Сегодня»
08.20 «У нас выигрывают!» Лотерейное шоу 12+
10.20 «Первая передача» 16+
11.00 «Чудо техники» 12+
11.55 «Дачный ответ» 0+
13.00 «НашПотребНадзор» 16+
14.05 «Однажды...» 16+
15.00 «Своя игра» 0+
16.20 «Человек в праве» 16+
17.00 «Следствие вели...» 16+
18.00 «Новые русские сенсации» 16+
19.00 «Итоги недели»
20.20 «Маска». Новый сезон (S) 12+
23.20 «Звезды сошлись» 16+
00.45 «Основано на реальных событиях» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «ЛЮБОВЬ С ЗАКРЫТЫМИ ГЛАЗАМИ» 16+
10.00 «ВЕТРЕНЫЙ». 243-я – 256-я серии 16+
22.45 «АКВАМАРИН» 16+
02.15 «ОТ НЕНАВИСТИ ДО ЛЮБВИ». 4-я – 6-я серии 16+
04.40 «Знать будущее. Жизнь после Ванги» 16+
06.15 «6 кадров» 16+

ЗВЕЗДА

05.30 «ПЕТРОВКА, 38» 12+
07.10 «ОГАРЕВА, 6» 12+
09.00 «Новости недели» с Юрием Подкопаевым 16+
09.25 «Служу России» 12+
09.55 «Военная приемка» 12+
10.45 «Скрытые угрозы» с Николаем Чиндяйкиным. «Альманах №137» 16+
11.30 «Код доступа» 12+
12.20 «Легенды армии» с Александром Маршалом. Талгат Бегельдинов 12+
13.15 «СТО ДНЕЙ СВОБОДЫ». 1-я – 4-я серии 16+
18.00 Главное с Ольгой Беловой 16+
19.40 «ПВО: стражи неба». Документальный сериал 16+
22.10 «Просто Жизнь с Иваном Охлобыстиным». Документальный сериал 16+
23.05 «Фетисов». Ток-шоу 12+
23.55 «ВТОРЖЕНИЕ» 12+
01.35 «НОЧНОЙ ОТСЕКИСТ» 12+
02.45 «КОГДА Я СТАНУ ВЕЛИКАНОМ» 12+
04.10 «Бой за берет» 12+
04.35 «Из всех орудий». Документальный сериал 16+

РАДИО РОССИИ

«ТАТАРСТАН» РАДИОСЫ НИЛӘР СӨЙЛИ?

Казан – FM 99,2 МГц
Чаллы – FM 92,01 МГц
Түбән Кама – FM 101,1 МГц

radiotatarstana.ru

Дүшәмбе, 3 апрель

6.00-8.00 «Яңа көн». Вакыйгалар панорамасы. Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Актуаль әңгәмә»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Туры элемтә
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10 Мөхәммәт Мәһдиев. «Без – кырык беренче ел балалары». Моноспектакль
13.10 «Татарстан дулкынында»
18.10 Яңалыклар
18.25 «Сердәшхонә»
18.35 «Җыр – минем гомерлек юлдашым»

Сишәмбе, 4 апрель

6.00-8.00 «Новый день». Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Актуальное интервью»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.10 Прямой эфир
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 «Пар канатлар»
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 «Фидакарьләр» проекты. 8 нче тапшыру
18.25 Юрий Виноградов әсәрләре

Чәршәмбе, 5 апрель

6.00-8.00 «Яңа көн». Вакыйгалар панорамасы. Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Юллар чатында».
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Туры элемтә
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 «Актуальное интервью»
11.40 Прокуратура разъясняет
13.10 «Татарстан дулкынында».
15.20 «Время молодых»
18.25 Вокаль һәм инструменталь дуэтлар концерты

Пәнҗешәмбе, 6 апрель

6.00-8.00 «Новый день». Панорама событий. Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Перекресток»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Прямой эфир
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 Татарстан: национальные проекты
13.10 «На волне Татарстана»
15.20 «Офыклар»
18.25 «Газиз тавышлар». Рафаэль Җаббаров язмалары

Җомга, 7 апрель

6.00-8.00 «Иртәнге нур». Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00-7.10 Вести радио России
7.10 Туры элемтә
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 Вести ПФО
11.30 «Доброе братство лучше богатства» (на удмуртском языке)
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 «Фидакарьләр» проекты. 5 нче тапшыру
18.25 Кичке моңнар

Шимбә, 8 апрель

8.10 Зифа Басыйрова иҗатына багышланган әдәби-музыкаль композиция
9.00-10.10, 11.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00 Трансляция радио России
10.10 «Гөлбакча»
10.30 «7 көн». Атналык күзәтү
10.55, 13.55 Реклама, прогноз погоды, программа передач
11.10 «Мин әтине өйрәтәм». Радиосериал
11.25 «Игелекле «Балкыш». Концерт
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.10 «Шигърият». Ренат Харис. Бакый Урманчега багышланган шигырьләр
15.35 Хәйдәр Гайнетдинов. «Үкенеч». Хикәя

Якшәмбе, 9 апрель

8.10-9.00 «Между Волгой и Уралом»
9.00-10.10, 11.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-16.10, 17.00 Трансляция радио России
10.10 «Көмеш кыңгырау»
10.30 «7 дней». Обзор событий недели
10.55, 13.55 Реклама, прогноз погоды, программа передач
11.10 Ял концерты
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.10, 16.10 Әмирхан Еники. «КУРКАМ МИН БУ БӘХЕТТӘН»

«КАРПАТКА» һәм «КАРНИКА» токымлы 4әр рамлы умарталар сатам.
Бал корты личинкалары – 2–3 рам.
Бал икмәге – 1 рам.
+7 96 55 99 88 67
+7 96 25 61 60 93
Реклама

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65,
222-09-70.
E-mail:
vtreklama@mail.ru

МИЛӘҮШӘ ЙӨРӘГЕ

БУ ГАИЛӘГӘ БӘХЕТ ЭЗЛӘҮЧЕЛӘР ҖЫЕЛГАН

Аларга күпләр соклана. Үз газизләренә генә түгел, чит балаларга да наз җитә бу кешеләрнең йөрәгендә. Мамадыш районының Олыяз авылында гомер итүче Миләүшә апа белән Фәнис абый Фәләховлар кешеләрне сөендерә белә. Әле яңа гына килен дә төшерде алар. Тәрбиягә алып үстергән уллары Руслан өйләнде.

Үзләренең язмышлары да гыйбрәтле. Миләүшә апа белән Фәнис абый икесе дә шушы авылныкы. Яшьтән яратышып, вәгъдәләр бирешеп йөргәннәр. Фәнисне армиягә алгач та, Миләүшә егетен көтеп алырга сүз бирә. Язмыштыр инде, көтми кыз, авылларына кунакка кайтып йөргән үзбәк егетенә кияүгә чыгып куя. Аннары Үзбәкстанга чыгып китәләр. Матур тормыш турында хыялланган кызның матур уйлары бик тиз чәлпәрәмә килә. Ир дигәне рәхәт күрсәтми үзенә. Гел кул күтәрә. Янында киңәш сорар, ярдәм өмет итәр кешесе дә булмый, җитмәсә.

– Улыбызга Дамир дип исем куштык. Бик авыр яшәдем. Түзеп булмас хәлдә идем. Улыма 1,5 яшь дигәндә, качып диярлек Татарстанга кайтып киттем. Бер апа булышты шул чакта. Әле дә аңа рәхмәт укыйм, – ди Миләүшә апа.

Алабугага кайтып урнаша алар. Үзе тәрбияче булып эшли, улы бакчага йөри. Әмма кинәт Дамир авырый башлый. Табиблар климат алышыну килешми, диләр. Нишләргә соң? Шул чакта Үзбәкстандагы иреннән хәбәр килә. Әйдә кушылыйк, бергә яшик, бүтән кул күтәрмәм, барысы да яхшы булыр, яңәсе. Баланы әтисез калдырырга теләмәгән Миләүшә ризалаша. Малайны Үзбәкстандагы әбисенә илтеп куярга, үзләре Татарстанда яшәргә килешәләр. Ире, баланы ияртеп, юлга чыга.

– Әле дә хәтерлим, 10 сентябрьдә юлга чыктылар, ә берничә көннән куркыныч хәбәр килде. Улымның хәле авырайган. Икенче көнне үк самолет белән Үзбәкстанга очтым. Барып җитсәм, барысы да елап утыра. Улымны җирләгәннәр иде инде, – ди Миләүшә апа.

Татар хатыны бу юлы да язмышына буйсына. Сабыр итеп, янә Үзбәкстанда яшәргә кала. Әмма гаиләсен саклап кала алмый. Ел ярым яшәгәннән соң, Миләүшә апа, аерылып, кире туган ягына кайтып китә.

– Мин кайтканда, Фәнис өйләнмәгән иде әле. Дөрес, күз уңында тоткан кешесе булган аның. Әмма берни барып чыкмаган. Без кабат очраша башладык. Озак та үтми, Фәнис абыебыз: «Чык миңа кияүгә», – дип сүз башлады. Мин шунда ук аны кисәтеп куйдым. «Әгәр гомер буе кияүдән кайттың, мине көтмәдең, дигән сүзләр белән интектерәсе булсаң, өйләнешмик», – дидем. Фәнис бер мәртәбә дә йөрәгемне яраламады. 32 ел аңлашып яшибез инде, – ди Миләүшә апа.

Миләүшә Фәләховаларның шәхси архивыннан

Иң элек уллары Фирназ туа. Язмыш аны да сыный. Малайның тумыштан күзләре начар күрә. Аннары Илүсәлә булалар. Соңрак төпчекләре Сөмбел дөньяга килә.

– Фирназ тугызынчы сыйныфны бетергәч, укырга чыгып китте. Өйдә тынлык. Малай җитми! Бервакыт Фәнис белән телевизордан ятимнәр турында тапшыру карап утырабыз. Шунда икебездә дә бер теләк уянды: бала алырга, – ди Миләүшә апа.

– Русланны озак көттек. Башта документ җыйдык, аннары ятимнәр йортларына барып йөрдек. Авыру балалар бирмәкчеләр иде. Әмма баш тарттык, яшь тә бара бит. Руслан үзе килеп чыкты безнең янга. Иң элек Фәнис янына килде дә: «Әти, мин сине күпме көттем бит, өйгә алып кайтасыңмы?» – дип, кочагына елышты. Фәниснең дә күңеле тулды. Ничек шул баланы калдырып китәсең, ди. Алып кайттык. 6 яшь иде аңа. Әнисе үз юлы белән чыгып киткән, әтисе 3 яшькә кадәр үстергән дә ятимнәр йортына тапшырган. Күпне күргән бала була ул.

Русланны бик кадерләп үстерәләр. Артык шук чаклары да булгалый малайның. «Мине беркая да илтмәгез!» – дип елаган чаклары да була. Миләүшә апа улының тиктормаслыгын хәзер көлеп искә төшерә. Кыскасы, кулына нәрсә тотса, шул ватыла аның. Әмма өзелеп, «әти, әни» дип торуы бар кимчелекләрен юа да төшерә. Ничек итсә итәләр, уртак тел таба үзләре. Ятимнәр йортыннан кайткач, бик озак кулыннан ипи төшми Русланның. Хәтта йоклаганда да янына ризык яшереп куя ул. Монысы – балалар йортында яшәү өчен көрәшкән вакытлардан калган гадәт.

Фәләховларның җылы оясына тартылучылар күп. Руслан, көллияттә укыганда, ял көннәрендә дустын ияртеп кайта. Ял дигәне карантинга әйләнеп, кунакта бик озак тора егет. Унсигезе тулуга, алып үстергән гаиләсе мөстәкыйль тормышка чыгарып җибәргән аны. Киткәндә Владик Миләүшә апасыннан: «Киләсе атнада да сезгә кайтыйм әле», – дип үтенә.

– Кайт, улым, дидем. Үзебез дә якын иттек, ул да. Әти-әнисе исән, абыйлары да, хәтта тәрбиягә алган гаиләсе дә бар. Әмма ул безне сайлады. Армиягә дә безнең йорттан чыгып китте. Шалтыратып, хәлләрен белешеп тордык. Нәрсә сораса, шуны җибәрдем. Аннары туры безгә кайтты. Владик әле дә бездә, – ди Миләүшә апа.

Русланның өйләнгәненә бер ай да юк әле. Әтиләре дә 32 ел элек нәкъ шул көнне никах укыткан. Уллары яр итеп, ятимлек ачысын татыган Ландышны сайлаган. Килеңнең әтисе исән түгел, әнисенең – үз юлы. «Әни» дип эндәшкәнем бар. «Әти»не ничекләр әйтермен икән?» – дип өзгәләнә Ландыш, бу гаиләгә килеп кергәч. Әмма Фәнис абыйның җылы кочагы, кешелекле булуы бар киртәләрне юк итә. Ландыш әтисен кочып ук ала.

– Балаларның бәхетенә сөенеп тору инде. Исән генә булсыннар. Биш бармагым төсле алар. Кайсын тешләсәң дә авырта. Берәүне дә чит итмәдем. Яратулары, хөрмәт итүләре, сүземне җиргә салып таптамаулары кирәк. Алар минем холыкны белә. Әмма мин барысын да алар хакына эшлим. Матур яшәсеннәр, кимсенмәсеннәр, – ди Миләүшә апа. – Йөрәгемдә урын күп. Яхшылыкны кеше белсен, савап булсын дип тә эшләмәдем. Күңел эше бит ул. Аны йә булдыра аласың, йә юк. Алар гына аңласын иде. Миңа күп кирәкми. Рәхмәт, әни, диюләре дә җитә!

Гөлгенә ШИҺАПОВА әзерләде

Булган хәл



vk.com

Улым кайткач...

Ишекне шакыдылар. Берәүне дә көтми идем. Ачып җибәрсәм, полиция хезмәткәрләре белән бер егет басып тора. «Мин – сезнең ташлап калдырган улыгыз», – ди бу егет. Җир ярылса, шунда гына кереп китәр идем. Ничә еллар исемә тә төшереп карамаган улым үзе эзләп тапкан мине!

...Гап-гади татар авылында, укытучылар гаиләсендә үссәм дә, тыелган җимешләрне бик иртә татый башладым. Сыйныфташларым әле бер егет белән йөрмәгәндә, мин инде авыл советы рәисенең сөяркәсе идем. Өйдәгеләр сизенде, әмма берни эшләтә алмадылар. Аптырагач, Минзәләгә алып барып, медицина училищесында калдырып кайттылар.

Өйдән чыгып киткәч, баш тагын да ныграк әйләнә башлады. Хәзер инде янымда күзәтеп-өйрәтеп торучы да юк иде. Хәмит абый да атна саен килеп йөри башлады. Янымда чибәр, яшь егетләр йөргәндә, олыгаеп, чәче коела башлаган, корсагы үскән абзыйны көтеп утырыйммы? Кыскасы, бер егет белән дуслаштым. Тәмәкесе дә тартылды, шәрабын да татыдык, башкасын да. Рәхәт тормышка тиз ияләштем. Укырга бик сирәк йөрдем. Диплом аласы елны әнинең идәнгә ятып елаганын әле дә оныта алмыйм. Ул күз яше түккәндә, миңа кызык иде. Яшермим, азуның тегө ягына чыккан идем.

Алар белән соңгы очрашуыбыз шул булган икән. Башта кинәт әти үлеп китте. Әнине исә апам үз янына алды. Берсенә дә исем китмәде. Чөнки ул чакта барыр урыным күп иде.

Укуны көчкә тәмамладым. Эшкә урнашып, күп тә үтмәде, авырлы икәнемне белдем. Инде нишләргә? Дус кызым кешегә сиздермәскә киңәш бирде. Башта эчемне бәйләп йөрдем. Табар вакыт җиткәндә, ял алып, башка шәһәргә киттем. Бер айлык баланы әбигә калдырдым. Икенче кайтуымда улым үсеп беткән иде инде. Ике елдан тагын авырга уздым. Ул чакта очрашып йөргән кешем бар иде. Әмма гаиләле, ике баласы бар. Хатыны чәчәк кебек чибәр булса да, Марат миңа тартылды. Аборт ясатуны таләп итсә дә, каршы килдем. Ана булу хисе өстен чыкты дисезме? Юк, әлбәттә! Икенче улымны хастаханәдә үк калдырып чыктым.

Марат белән мөнәсәбәтләребез исә элеккегечә дәвам итте. Марат мине какмады, кимсетмәде. Кияүгә чыгуны уйламадым да. Ә былтыр ул юл фаҗигасендә һәлак булды. Мин бөтенләй ялгыз калдым. Әйе, әбидә үскән улым бар бит әле. Аны әтинең туганнары тәрбияләде. Башта миңа кирәк түгел иде. Аннары минем кирәгем калмады.

Ә бүген ишек төбемдә балам басып тора. Мин хастаханәдә калдырып чыккан икенче улым. Бик озак ни әйтергә белми аптырап тордым. Тел бәйләнгән, күз яше дә чыкмый. Әле ярый үзе кочып алды. Бик яхшы гаиләгә туры килгән. Әти-әнисе чын ир-ат итеп үстергән аны. Кызганыч, иртә киткәннәр. Икесе дә исән түгел икән инде. Илдар өйләнгән, ике бала үстерә.

Шөкер, улым мине артык сораулар биреп йөдәтмәде. Кичергәндер дип өметләнәм. Әмма ышанып та бетмим. Кичереп буламы минем кебекләрне? Тезләнеп, барысыннан да гафу сорар идем. Тик әти дә китте, әни дә исән түгел. Ялгышларны төзәтергә соң булса да, догалар кылып, Аллаһы Тәгаләдән кичерүен сорыйм хәзер. Ул чакта никләр ялгыштым икән? Бу язмам башкаларга гыйбрәт булсын иде. Гомерегезне әрәм уздырмагыз.

Гөлнәзирә

МИЛЛИЛЕК КЕСӘНЕ ТЕШЛИ

Шиһабетдин Мәрҗани милләтнең өч билгесе дип туган телне, гореф-гадәтләрне һәм милли киемне атаган. Ни кызганыч, шундый чорга җиттек: бу билгеләрнең өчесе дә саклауга мохтаҗ. Тел дибез икән, сөйләшүчесе, традиция дисәк, аны үтәүчесе, кием дисәк, киючесе аз. Соңгысының, сер түгел, хакы шүрләтә. Милли үзенчәлегебезне, үзаңны ассызыклаучы кием-салымны масс-маркетта табам димә. Шул да милли киемгә кызыксынуны киметмиме икән? Гомумән, Татарстанда милли кием индустриясен эшләтеп җибәрү мөмкинме? «ВТ» шул сорауларга җавап эзләде.

Татар булу хакы

Моннан берничә ел элек Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов журналистлар белән очрашу вакытында: «Без үз милләтебезне, гореф-гадәтләребезне, ризыкларыбызны, динебезне сакларга тиеш. Ашау, дин, җыр-биюдән кала безнең милли киемебез дә бар. Нишләп аны артистлар гына кияргә тиеш? Ул безнең гадәти киемебез булган», – дигән иде.

Узган ел Казанда узган этнофестивальләрнең берсендә Татарстанның мәдәният министры Ирада Әюпова да халыкны көндәлек тормышта милли кием киеп йөрергә өндәде. «Агач тамырсыз үсми. Аңа дым, җир, һава кирәк. Шулай ук мохит тә. Әгәр дә без мең еллар дәвамында камил дәрәҗәгә җиткерелгән әлеге сәнгать үрнәкләрен күргән соңгы буын булсак, безнең буынның бәһасе бернигә дә тормас. Тирән тамырларга ия булган милли киемнәрне кияргә чакырам. Оялмыйк», – дигән иде министр.

Рәиснең дә, мәдәниятебез өчен җаваплы тармак җитәкчесенең дә милли киемсалым турында сүз катуы беренче генә түгел. Әле күптән түгел генә Казан Кремлендә булып узган мәдәният һәм сәнгать буенча совет утырышында бу хакта шактый сөйләштеләр. Үзебездән башларга, киемне күргәзмәдә күрсәтү өчен генә тегәсе түгел дигән фикергә килделәр.

Анысы хак та бит, тик еш кына, милли дигәнең кесәне тешли торган булып чыга. Гадәти кибеттә табып булмаган милли киемне дизайнерлардан махсус тектерергә йә булмаса аларның әзер эшләнмәләрен сатып алырга туры килә. Кул көче, идея, фантазия, белем, вакыт – барысы бергә кушылып барлыкка китергән иҗатның хакы, гадәттә, бик югары була.

Әлегә исемнәрен атап үтми генә, Татарстан күләмендә танылган (кайберләре Россия, чит илләрдә дә) дизайнерлар тәкъдим иткән кием-салымнарның уртача бәяләренә күз салыйк. Саннарга карап, үзебезчә милли итеп киенүнең хакын исәпләп чыгаруны укучы хөкеменә калдырабыз. Бу әле – минимум гына.

Хатын-кызлар өчен

Изү	4500
Калфак	1000
Хәситә	6 меңнән башлап
Милли күлмәк	5 меңнән башлап
Билбау	1500
Чүәк/читек	4–5 мең/15–20 мең
Яулык	500
Чулпы/алка	1500/500
Камзул	7–10 меңнән башлап

Ир-атлар өчен

Түбәтәй	1 меңнән башлап
Каракүл бүрек/папаха	4900/7500
Френч-костюм (утыртма якалы костюм)	15 меңнән башлап

Чын безнеңчә милли… һәм кыйммәт!

Дизайнерлар иҗат иткән милли кием үрнәкләре – һичшиксез, сәнгать һәм матурлык үрнәге. Матур булганның хакы да алтын. Татарстанда милли кием индустриясен массакүләм үстерү мөмкинме? Нинди чаралар бәяләрне авызлыкларга ярдәм итәр иде икән? Милли бренд хуҗаларыннан шул хакта сораштык.

«Buro Banu» брендына нигез салучы һәм баш дизайнеры Элара Шәйхи әйтүенчә, хәзерге көндә республикада татар мәдәниятенең, милли гореф-гадәтләренең күтәрелеше күзәтелә. Шуңа күрә милли кием индустриясен үстерүне мөһим мәсьәлә дип саный дизайнер. Мөһим генә дә түгел, көн кадагында торучы!

– Республика халкы, Россия һәм аннан читтә яшәүчеләр, гасырлар буе камилләшкән, милли бизәкләрне чагылдырган тукыма, көнкүреш әйберләрен, интерьер җиһазларын өстен куя. Аларга ихтыяҗ зур. Бу безнең милли ДНКбызга да бәйле дип әйтер идем. Традицияләребездә әле ачылмаган яклар бик күп һәм безнең киң җәмәгатьчелеккә шуларны танытасы килә, – ди оста куллы әңгәмәдәшебез.

Яшерен-батырын түгел, брендның милли эшләнмәләрен һәркемнең акча янчыгына туры килә дип әйтеп булмый.

Әйтик, чигүләрсез, бизәкләрсез күлмәкне – 17 мең, чигүлесен – 28500, калфакны – 24 мең, милли бомберны – 26 мең, бизәкле кесәләрне – 7500, букчаны – 8 мең, пирчәткәләрне 3 мең сумга саталар.

Шушы брендтан тулы бер образ сатып алам дисәң, шактый акчаны чыгарып саласы икән. Никахка, мәҗлесләргә, рәсми чараларга, фотосессияләргә дип, ир-атлар да, хатын-кызлар да аларның киемнәренә заказ бирә.

Продукциягә бәяне киметергә нинди чаралар ярдәм итәр иде икән соң? Элара Шәйхи берничәсен атады:

– Товарны зур партияләрдә тегү чималны кулай, очсыз бәя буенча сатып алырга, ә товарны тиз арада сатып, үзкыйммәткә якын бәяләрне саклап калырга мөмкинлек бирә. Аннан тармак үсеше өчен җиһазлар һәм чимал сатып алу өчен грантлар кирәк. Хәзерге вакытта грант кысасында чималга каралган сумма бик кечкенә. Бу үзкыйммәткә бик нык тәэсир итә. Тагын бер чара – товар җитештерү һәм сату өчен мәйданчыкларны ташламалы шартларда бирү һәм салымны кимету. Җитештерүчеләр, һөнәрчеләр һәм кулланучылар арасында миллилеккә кызыксыну үсүен күрәбез, шуңа ихтыяҗны канәгатьләндерү җәһәтеннән кыенлыклар белән очрашабыз.

Дизайнер сүзләренчә, алар бизнесларын тагын да киңрәк итәргә тырыша, шуңа күрә дә кием-салым җитештергәндә кулдан чигү түгел, ә машина чигүе кулланыла. Җиңел сәнгатькә ук күчеп бетә алмыйлар. Чөнки мондый милли киемнәр күпләп тегелә алмый.

Рәссам, этнодизайнер Надежда Шәйхисламова Уфа рәссамы Илдар Гатауллин белән татар халкының милли костюмын реконструкцияләү һәм аларның күчермәләрен ясау белән шөгыльләнә. «Millihasite» дигән проект булдырганнар. 2021 елда Надежда «Елның иң яхшы һөнәрчесе» исеменә дә лаек була әле. Эшен яратып, зур кызыксыну белән башкарганы күренеп тора. «Миллилекне халык күңеленә кертәсем, әби-бабайларыбызның киеменә карата кызыксыну уятасым килә. Алар бик матур! Шул киемнәрдән йөрүче кызларга сокланып туймаслык! Безгә милли киемнәрне сакларга, яңадан кулланышка кертергә кирәк. Кешеләр, хатын-кызның киеменә карап, аның нинди милләттән икәнен аңларга тиеш», – ди урамга да хәситә тагып чыгучы Надежда. Сүз уңаеннан, кеч-кенә яка чылбыры – 450, алка һәм яка чылбыры бергә 4500 сумга төшә. Ханбикәләр киеп йөргән баш кияме дә бар. Анысы – 50 мең сум. Изүләрнең бәяләре 5 мең сумнан башлана. Хәситәләрнең бәяләре дә төрле – 6 мең сумга да, хәтта 150 мең сумга да бар!

«Татар модасына ихтыяҗ һәм игътибар бармы соң?» – дип кызыксындык аннан.

– Татар модасы яшьләр арасында да, урта яшьтәге кешеләр арасында да популяр. Әлбәттә, татар модасы белән күбрәк хатын-кызлар кызыксына, әмма ир-атлар да кимен куймый, – дип саный Надежда. – Хәзер милли киемнең аксессуарларына, кайвакыт бөтен костюмга да ихтыяҗ барлыгын күрәбез. Безнең бренд киемнәрен, мәсәлән, никах өчен арендага алып торучылар бар. Заманча, әмма элеккеге традицион аксессуарларны кулланып ясалган образларны сорап килүчеләр күренгәли.

Халык арасында милли киемгә кызыксынуны арттыру өчен нишләргә? Бу сорауга да җавабы бар әңгәмәдәшебезнең:

– Моданы популярлаштырырга. Хезмәттәшлеккә танылган шәхесләрне чакырырга, артистлар, блогер, модельләр белән эшләргә. Әйтик, аларны милли киемгә киендереп, социаль челтәрләр өчен контент төшерергә. Бу җәһәттән Мәдәният министрлыгы да теләктәшлек күрсәтергә тиеш. Татарстанда милли кием индустриясен эшләтеп җибәрү мөмкин хәл, әгәр дә ки моның белән җитәкчелек ясиә инвесторлар кызыксынса. Ясиә моңа акча кертергә әзер булган бик хәлле кешеләр булса. Кызганыч, массакүләм продукция булдыру безнең осталарның көченнән килми. Хәер, бәяләре төрле булыр иде. Бөтен кеше дә сатып алырлыкны ясап була, «люкс» саналганны җитештерергә мөмкин. Зәркән эшләнмәләр мисалында карыйк. Мәсәлән, безнең 3D форматтагы күчермәләрне бөтен кеше дә сатып алырлык хәлдә.

Милли киемне популярлаштыру дигәннән, Надежда Шәйхисламова тагын бер мисал китерде:

– Рус кокошникларын (баш киеме) реконструкцияләүче танылган дизайнер бар – Юханн Никадамус. Кәсебенең башлангыч этабында ул шәхсән үзе артистлар, стилистлар, фотографлар табып, үзенчәлекле сурәтләр төшерде. Тора-бара кокошниклары халык арасында да популярлашты. Ул ясаган баш киеменең бәясе – 200 мең сумнан башлана һәм бер миллион сумга кадәр җитә! Сатып алучысы табылып тора.

Милли эшләнмәләр үз хакын аклый, ди рәссам.

– Милли кәсепчелек, милли кием, мәдәният тарихын, тамырын белгән кешеләргә бәянең нигә шундый булуы шундук аңлашылыр иде. Бәяләр белән килешмәү кешеләрнең мәдәниятне белмәвеннән һәм халык кәсепчелегенең шактый вакыт таләп итүен аңламаудан килә. Күпме хезмәт кергәнен аңласалар, эшләнмәнең хакына бәйле сорауга җавапны табарлар иде. Әмма берәү дә халыкка татарларның кәсепчелеге нинди үзенчәлеккә һәм бәһагә ия булуын аңлатмый, – дип саный Надежда Шәйхисламова.

«Татарча киенәсе килгән, әмма акча ягы такыр булганнарга прокат ярдәмгә килә», – ди әңгәмәдәшебез. Күп кенә милли кием брендлары шулай эшли

ФИКЕР

Илсур САФИУЛЛИН,
«Милли сәүдә маркасы» предприятиесе генераль директоры:
– «Chanel», «Dior» кебек брендларны ишеткәнегез бармы? Ә «Adidas» турында? Алар кайсы халыкның милли киемен җитештерә? Французларның брендлары бар, Италиянең «Gucci»е бар. Безгә менә шулай дөньякүләм танылу алырдай бренд булдырырга кирәк. Милли кием көндәлек кием була алмый. Аның кулланылышы чикле. Милли киемне көн саен киясезме соң? Безнең бөтен проблема да шунда: без киң куллану бренды булган товар җитештерә алмыйбыз. Милли кием юкка чыкмас, булачак ул. Әмма көчләп, фәлән кушты дип, изү тактырып, күлмәк кидертеп булмый. Башта мода һәм теләк тудырырга кирәк. Аннары бу тармак үзеннән-үзе үсәчәк. Теләк юк икән, биш фабрика ачып куй, кулланучы булмаса, нәрсәгә кирәк? Җирле брендларның проблемасы да җитештерүдә түгел. Алар кулланучы таба алмый. Русларда да шулай бит ул. Кокошник киеп йөргән кеше күргәнегез бармы? Хәтерләсәгез, Хрущев вышиванка (традицион славян милли киеме. – **Авт.**) киеп йөргәндә, аның якын-тирәдәгеләре дә шуны кия башлады. Рөстәм Нургали улы да тренд бирде, түрәләр френч-костюм кия. Әмма түрәләребез күп түгел бит.
Милли киемне кеше электән үз куллары белән теккән. Әйтик, кызлар кияүгә чыкканда күлмәк әзерләгән. Ул күпләп җитештерү түгел. Натураль хуҗалык белән көн иткәндә, кешеләрнең үз җире, җирдә үскән киндере булган, милли кием әнә шулай барлыкка килгән дә инде. Хәзер без базар шартларында көн итәбез. Кешегә киемнең уңайлы булуы мөһим.
Бренд бар икән, аны рекламаларга кирәк. Кешенең башына сеңә ул. Бер төр киемне генә популярлаштыру мөмкин түгел.

Раушания СӘҮБӘНОВА,
Казанның халык сәнгате һөнәрләре техникумы директоры:
– Милли киемнәрне массакүләм итү ничек кирәкмәсен? Моны эшләргә була да, кирәк тә. Шоу-рум ише кибетләрдә нинди сыйфаттагы кием сатып алуыңны кайдан беләсең? Массакүләм дәрәҗәдә җитештергән очракта, һичшиксез, ГОСТ таләпләрен үтәячәк, сыйфат тикшерүләрен узачак. Моның эше күп, әлбәттә. Әмма продукцияне күләмле итеп чыгару өчен хөкүмәт ярдәменнән башка булмый. Бина, субсидия, урыннар, дисеңме. Безнең техникумны карагыз. Укып чыккан егет-кызларыбыз, үз эшләрен булдырып, акча эшли. Барысы да җайга салынган. Без бит аларны иң элек эшмәкәр булырга өйрәтәбез. Милли кием җитештерүчеләр бар инде. Әмма аларның күпчелеге – машина бәясе! 25 мең сум хезмәт хакы алып, 40 мең сумга кием алмыйсың инде.

Гөлназ ГАТИНА,
«Татар кызы – 2017» бәйгесе җиңүчесе:
– Минем милли кием, эшләнмәләр коллекциям шактый зур. Бәяләрен санаганым юк, якынча да әйтә алмыйм. Үземне белгәннән бирле тупланып торган коллекция ул. Милли кием, чынлап та, бик кыйммәт. Шул бәя күпләрне бу киемнәрдән ваз кичәргә мәҗбүр итә дә. Ә бит хәзер милли эшләнмәләр белән кызыксынучылар бик күп! Бигрәк тә яшьләр. Кибеткә баргач, «аһ, матур!» дип кызыгып кайталар да, бәясен күргәч, фикерләре үзгәрә. Әйтик, милли бизәкле сумка. Чын күн түгел, эко-күннән эшләнсә дә, хакы төшәр иде. Әлбәттә, бренд, сыйфат дигән төшенчәләр бар инде. Әмма яшьләрнең, студентларның аны сатып алырга акчасы җитмәс. Милли әйберләрне сатып алуга киртә бу һәм шул рәвешле милли продукция кулланучыга барып җитә алмый.

Ольга МИХАЙЛОВСКАЯ,
мода белгече, фэшн-журналист:
– Гадәти кибетләр – масс-маркетны дөньякүләм танылган корпорацияләр яулап алган. Шуңа күрә алар белән көндәшлек итү мәгънәсез. Хәер, соңгы арада шактый лаеклы брендлар барлыкка килгәли, әмма аларның таралу масштабын чагыштырырлык түгел. Локаль (җирле) брендлар үзләренең уникаль, кабатланмас булуы белән көндәшлек итә ала. Андый брендларны аз-азлап җитештерәләр, еш кына кул хезмәте файдаланыла. Ул югары технологияләр заманында бик югары бәяләнә. Масс-маркет ул инде – икенчел продукт өчен.

икән инде. «Хәзер халыкта фотосессияләр өчен кием алып тору да популярлашты. Бу да милли киемне танытуның бер ысулы инде. Халыкта милли кәсепчелек, киемгә карата фикер сөрешен үзгәртергә кирәк. Моның өчен команда белән эшләү мөһим. PR-белгечләр кирәк. Осталар, этнографлар белән эшләү. Халыкта кызыксыну бар ул. Алар күп итеп түләргә генә әзер түгел. Ә кәсепчелеккә байларны җәлеп итәр өчен, бәлки, мәгълүмат тапшыру эшен башкача алып барырга кирәктер», – дип саный Надежда Шәйхисламова.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Таңсылу Галимова

ЕЛ УКЫТУЧЫСЫ АРМАН КОСТАНЯН:

«БДИдан баш тартырга кирәкми»

Югары Ослан районындагы Иннополис лицеенда эшләүче Арман КОСТАНЯН «Ел укытучысы – 2023» республика бәйгесе җиңүчесе булып танылды. 28 яшьлек мөгаллим балаларга математика өйрәтә. Сентябрь аенда Мәскәүдә узачак бәйгедә ул Татарстан данын яклаячак. Республиканың иң шәп укытучысы белән замана укучылары, ватанпәрвәрлек, бүгенге мәктәп турында сөйләштек.

:: Арман Артурович, бүген мәктәпләрдә ватанпәрвәрлеккә аерым игътибар бирелә башлады. Чипсы ашап, кулларыннан телефон төшермәгән балаларда бу хисне тәрбияләп буламы?
– Ә алар ватанпәрвәр түгел дип сезгә кем әйтте? Бик тә патриотлар. Тик замана баласында ул икенче төрлерәк чагыла. Хәзер патриотик тәрбиягә аеруча зур игътибар бирелә. Тик бу эшне әле генә башладык дип әйтә алмыйм. Ул электән үк алып барыла. Әмма гаиләдә булмаса, мәктәп кенә таләп итсә, бу көчләп тагылган фикер булачак. Бергә тәрбияләргә кирәк.

:: Замана балалары социаль челтәрләрдә яши. Алар белән интернетта аралашасызмы? Нәрсәгә өстенлек бирәләр?
– Социаль челтәрләрдән качып булмый. Качарга да кирәкми, бары дөрес кулланырга өйрәтергә генә кирәк. «Ютуб», «Телеграм» каналларында сәхифәләрем бар. Анда математикадан бердәм дәүләт имтиханнарына әзерләнү өчен видеороликлар куям. Балалар өчен файдалы мәгълүмат бирәм.
Алар үзләрен иштүне тели. Социаль челтәр – фикер белдерү, үзләрен күрсәтү, җавап алу өчен мәйданчык. Чын тормышта менә боларны эшли алмаганга күрә, социаль челтәрләрдән җавап табарга тырышалар, дип уйлыйм. Укытучылар, әти-әниләргә шуны әйтәсем килә: балаларны тыңлый һәм ишетә белегез!

:: Хулиган балалар элек тә булган, хәзер дә бар. Андыйларны ничек тыңлатырга?
– Дәрестә карандаш атучымы, әллә сугыш чукмарымы? Хулиган – киң мәгънәгә ия төшенчә. Безнең уку йортында андый нәрсә юк. Әгәр укытучы кызык булса, аның фәне дә укучыда кызыксыну уятачак. Без шәхес үстерергә, балаларны мавыктыру юлларын эзләргә тиеш. Менә шул вакытта укучылар белемгә дә тартылачак. Хулиганлыкка да, телефон белән мавыгырга да вакытлары калмас.

:: Әти-әниләр – укытучы өчен кем ул?
– Әти-әниләр укытучыны хуплаучы булырга тиеш. Әти-әни – бер, укытучы икенче төрле сөйләгәндә, алга китеп булмый. Шөкер, барлык әти-әниләр дә сүземне тыңлый, фикеремә колак сала. Бергәләп укучыларны үстерергә, кирәкле юнәлеш бирергә тырышабыз.

:: БДИ турында бәхәсләрнең беткәне юк. Ничек уйлыйсыз, аннан баш тартырга кирәкме?
– Юк, баш тартырга кирәкми. Ул инде ун елдан артык уздырыла. Елдан-ел камилләшә бара. Узган ел беренче тапкыр унберенче сыйныфларны чыгардым. Минем сыйныфта иң зур балл 94 булды. Республика буенча математикадан уртача иң зур балл безнең лицейда – 86 балл.

:: Укытучы бәйрәмдә укучылардан чәчәк, бүләк алырга тиешме?
– Бабам еш кына: «Бирәләр икән, ал, кыйныйлар икән, кач», – дип шаярта. Рәхмәт әйтсәләр, һәрвакыт күңел була. Әгәр чәчәк, шоколад бирәләр икән, ник алмаска? Туган көнгә бүләкне алабыз бит.

:: Мәктәпкә очраклы гына килеп эләктем, дидегез... Үкенмисезме?
– Яңа гына университетны тәмамлаган чак. Җәй көне танышым, математика укытучысы Надир Курамшин: «Иннополис лицеена математика укытучысы кирәк, әйдә, эшләп карамыйсыңмы?» – дип тәкъдим итте. Башта каршы килдем. Ни өчен дигәндә, укытучы булу уема да килмәгән иде. Тик әлеге тәкъдим атна буе истән чыкмады. Барып карарга уйладым. Әңгәмә уздырып, сайлап алдылар. Бер дә үкенмим, эшемнән канәгать мин. Лицейдагы барлык укытучыларны остазларым дип саныйм. Алтынчы ел укытам инде.

:: Яшьләрне, ир укытучыларны мәктәпкә ничек җәлеп итәргә?
– Риторик сорау. Мәктәпләрдә хезмәт хакын арттырырга кирәк. Кызганыч, эш хакы югары түгел. Ир-ат укытучылар саны арта. Мәгариф үзгәрә, яңа мәктәпләр төзелә, заманча җиһазлар белән баетыла. Мәктәптә балага гына түгел, укытучыга да кызык булырга тиеш. Менә мине дә җәлеп итте бит әле.

:: Арман, сез туган телегезне беләсезме? Гаиләдә гореф-гадәтләр, мәдәниятләрне ничек саклыйсыз?
– Тамырларым – Әрмәнстаннан, әмма Бөгелмәдә тудым. Казанда үстем, укыдым. Туган телемне бик яхшы беләм. Кечкенә чакта гаиләдә барыбыз да әрмәнчә генә сөйләштек. Туган тел югалмый, онытылмый. Бу минем өчен бик мөһим. Милли бәйрәмнәрне дә үткәрәбез.

:: Татар телен ничек өйрәндегез? Кыенлыклар булдымы?
– Татарчаны мәктәптә үк өйрәндем. Студент елларында «Сәләт» лагерена эләктем. Андагы мохит татар телен үстерергә булышты. Үземчә яхшы гына беләм дип саныйм. Татарстанда яшибез, шуңа күрә белмичә ярамый.

:: Мәгариф системасында нәрсәне үзгәртер идегез?
– Мәгариф системасында әкренләп барысы да үзгәреп бара. Дөнья үзгәргәндә, без генә бер урында туктап кала алмыйбыз. Элек бер һөнәр буенча укып, гомер буе шул тармакта эшләсәләр, хәзер алай түгел. Кеше үз гомерендә 5–6 төрле яңа һөнәр ала. Укуга караш та, алымнар да үзгәрә.

Әңгәмәдәш – Сәрия МИФТАХОВА

ГАМИЛ ӘСХӘДУЛЛА:

«ЮМОРНЫ АҢЛАМЫЙ БАШЛАДЫК»

Татарда юмор бармы, бүген ул ни дәрәҗәдә актуаль? Шушы өлкәдә табышлар һәм проблемалар турында «Мунча ташы» театры җитәкчесе, Татарстанның халык артисты Гамил ӘСХӘДУЛЛА белән сөйләштек.

:: Гамил абый, халык көлүне онытмадымы әле? Кеше көлдерү ансатмы?

– Дөнья коточкыч тизлек белән алга бара һәм аңа ияреп, күп кенә яңа нәрсәләр килеп чыга, искеләре, еш кына файдалылары, төшеп кала. Бу халык кәефендә, үзүзен тотышында да чагыла. Әйтик, бүген үзара мәзәк сөйләшү бетте диярлек. Элек эштә дә, кайда да булса очрашсаң да, мәзәк сөйләшеп алыш бар иде. Үзенә күрә җорлыкта, зирәклектә көч сынашу иде ул. Фикерне эләктереп аласың да шуңа туры килерлек мәзәкне сөйлисең. Хәзер үзара сөйләшү юк, телефонда утырабыз. «ТикТок»ише социаль челтәрләргә чыккан мәзәк дисәң, мәзәк булып та җитмәгән хәлләрдән көләргә азапланабыз. Интернетта төрлесе бар, яхшысы да, яманы да, дигәндәй. Әмма аның белән генә чикләнергә ярамый. Ә халыкның көләсе килә. Авырлыкларны шуның белән җиңәсе, көнелендәге шикшөбһәне шулай таратасы килә аның. Мин моны быелгы концерт программасыннан чыгып әйтәм. Казанда 11 көн чыгыш ясадык, халыкның бик сагынганына инандык. Пандемия чорында да туктап калмаска тырыштык, авырлыгы бик күп булса да, йөрдек. Туктап калу – артист өчен иң начар нәрсә.

> Халыкны көлдерү ансат түгел. Дөнья шулкадәр тизлек белән үзгәрә, кичәге юмор бүгенгә ярамый. Әйтик, бүген пенсия реформасы турындагы мәзәк белән көлдереп булмый. Кичә шаярткан темаларга бүген кагылырга ярамый. Монда инде юмордан бигрәк сатира турында сүз бара.

:: «Сатира» дигән жанр исәнме?

– Сатира бар, әмма дәрәҗәсе элеккеге кебек түгел. Халык та бик яратып бетерми аны. Сәхнәдән дә авырткан җиренә кагылсыннар әле. Сатира бит ул – кешеләрнең, җәмгыятьнең, хөкүмәтнең җитешсезлекләреннән әче көлү, ни дисәң дә. Әмма сатирасыз юмор була алмый. Чөнки халыкның дөреслекне дә ишетәсе килә. Шуңа күрә без, телефон аферистларын, төрле алдауларны юморга төреп, халыкка җиткерергә тырышабыз. Өлкәннәр, кара әле, миңа да "акча сал әле" дип шалтыраталар бит дип, күңеленә салып куя. Менә шундый тормышчан хәлләргә тукталырга тырышабыз. Искерми торган темалар арасында җитәкчеләрнең балаларын «җылы» урыннарга урнаштыру бар. Атасы урнаштырган, ә теге эшли алмый. Халык андый мисалларны тормышта да очраткан, шуңа көлә инде ул.

:: Гамил Афзал, Фәнзаман Баттал сатирасы, Зөлфәт Хәким, Марат Кәбиров юморы сәхнәдә кулланылыкмы?

– Юмор-сатира әсәрләре белән «Чаян» журналында таныша идек. Хәзер анда яңа исемнәр бар микән, әйтә алмыйм шул. Һәрхәлдә шәп сатирик барлыкка килгәнлеге турында хәбәрнең миңа ирешкәне юк. Гамил Афзал, Фәнзаман Баттал, Зөлфәт Хәким, Марсель Галиев, Камил Кәримов, Марат Кәбиров, Алмаз Хәмзин әсәрләре монологлар өчен әйбәт, әмма сәхнәдә уйнарлык түгел. Туксанынчы елларда иң чәйнәлгән тема армия хезмәте булса, бүген инде аның тирәсендә шаярып булмый. Хәтта такмакларның да күбесе яраксыз. Хәзер һәр халыкта телне саклау проблемасы бар. Димәк, ул темага миниатюралар артачак. Бу җәһәттән кызыклы күзәтүләр ясадым әле. Мәсәлән, башка милләт кешесе татар телен өйрәнсә, ул татардан чистарак сөйләшәчәк. Шул кешене татар кешесе белән сөйләштерсәң, бот чабып көләрлек хәл килеп чыгарга мөмкин. Безнең телдә нинди генә паразит сүз, нинди генә алынма юк чөнки! Чечня башлыгы да әнә «дон» дигән сүзне кушып сөйләшә. Алла белсен аның нәрсә аңлатканын!

Аннан соң залда утырган яшенә дә, картына да аңлаешлы мәзәк табарга кирәк. «Чат саен ч@т» дигән тамашада без әнә шул максатка ирештек кебек. Җырчылар яңа аранжировка ясап, җырга яңа сулыш өрә ала, без мәзәкне заманчалаштыра алмыйбыз шул. Үзебезнең багаж да саллы, әмма аның барысы да хәзерге заманга яраклы түгел. Алай да бу сезонда өйләнү темасына кагылышлы миниатюраны яңарттык. Халыкка «тиде», рәхәтләнеп карады.

:: Сезнең юмор ничек туа? Импровизацияме, китаптан аласызмы?

– Китаптан бик алыр идек, аларны сәхнәдә уйнап булмый. Хәтта КВНщиклар белән дә элемтәгә чыгып карадык. Аларның да хәлләре бик яхшы түгел. Хәер, бездә генә түгел, Россия буенча шул ук хәл. «Беренче канал»да бара торганының да рәте бетте. Юморның эчтәлеге калмады. Көлке кризисы яшерен-батырын түгел, бар инде ул. Илдәге вазгыятькә дә бәйле ул. Җәелеп китеп шаяртырга да ярамый, кысаларга кердек. Интернет «юмористлары» да, көлдерәм дип, әллә кайларга төшеп бетә. Җим булмасмы дип, инде аларын да күзәтеп барырга тырышам. Ир белән хатын булып шаяручылар бар, пародия ясаучылар. Җырчы Диләрә Иалетдинова безгә пародия ясаган иде. Шалтыратып рәхмәт әйттем, үзебезгә эшләргә дә чакырдым хәтта. Куркыбрак калды әле. Хәер, пандемия чорында туган күп кенә интернет образларның кызыгы бетте. Шул ук Шәрәпҗан да ул кадәр аудитория җыймыйдыр дип уйлыйм мин.

:: 1 апрель – сезнең өчен нинди көн ул?

– Элек ул көннең ниндидер бер шатлыгы, берләштерү көче бар иде. Гәрчә уйлап чыгарылган көн булса да. Үзең алдансаң да кызык иде. Хәзер аның асылын гына түгел, көлкенең асылын аңлау да бетеп бара. Без бәләкәй чакта язын урамда чокыр казый идек. Үткән-сүткән кеше шунда төшеп чума. Хикмәт нәрсәдә: суга төшкән кеше дә, тәки каптырды бит мине, дип көлә, син дә. Хәзер шулай эшләп кара әле: кыйммәтле ботинкасы белән төшеп киткән кеше артыңнан күсәк тотып куарга, үзеңне судка бирергә мөмкин. Элек шаяруны кабул итү бар иде. Хәзер кеше белән шаярырга куркыныч. Минем үземә ошый Көлке көне. Әмма адәм баласы шаяртуның бәеклеген һәм көчен белеп шаярырга, кешенең чынлап та кәефен күтәрергә тиеш. Шаяруда да чама бар.

:: Алдау көнендә кемнәрне төп башына утыртканыгыз бар?

– Бәләкәйдән шуграк бала булганмын. Әтине дә төп башына утырткан булды. Өмә ясап өй җиткерәләр иде, бардым да: «Әти, сарык бәрәнләде», – дип әйттем. Әти, кайтып килергә дип, бура өстеннән төшә башлады. Үзе: «Буаз сарык та юк бит, тәкәләр генә калдырдым», – дип уйлый икән. Шуннан кире борылды инде. Гаиләдә без биш малай үстек. Берәр нәрсә эшли башласак, берәр вакыйганы күпертеп сөйләргә ярата идем. Авызларын ачып тыңлыйлар иде инде. Хәзер Көлке көнендә хезмәткәрләр белән берәр мөгез чыгарабыз. Мине алдасалар, алдый алсалар, шатланам гына.

:: Сезнең өчен тыелган темалар бармы? Кемнәрдән, нинди күренешләрдән көләргә ярамый?

– Шәхесләрдән исемнәрен әйтеп көләргә ярамый. Дин дә кушмый аны... Җитәкченең кимчелекләреннән көләсе булса, Гали Галиеч дигән образ ярдәмгә килә. Татарда бит Гали Галиеч гомумән була алмый. Бездә балага атасы исемен кушмыйлар. Шулай да Чаллыда Ренат Ренатович дигән кеше табылды әле. Изге әйберләрдән, диннән көләргә ярамый. Ләкин дин әһеленнән көләргә ярый. Дин әһеле дә кимчелекләрдән азат түгел. Бигрәк тә тормыш тәҗрибәсе булмаган кешеләрнең вәгазь сөйләве, сине тормышка өйрәтүе мәзәк. Әниләрдән көләргә ярамый. Ялгышса да, әни әни булып кала. Кимчелектән көләргә кирәк. Урамга чыксаң, күзгә ташланган иң зур кимчелек нәрсә? Яшьләрнең «вейп» дигән нәрсәне суырып йөрүләре. Менә – көлке объекты. Ләкин аны сәхнәгә менгерсәң, ник алай эшлисез, дип гаепләүчеләр дә бар. Имгәк ирләрдән көләргә кирәк. Хатыны тормыш алып бара, ә ул бармакка бармак та сукмый. Аннан сезнең журналист халкы, сәхнәгә тагын сәрхуш ир чыгардылар, дип яза инде. Ә без аны эчмәсен дип күрсәтәбез. Элек клуб янына килеп туктыйсың, берәрсе: «Син нәрсә анда безне күрсәттең?» – дип сорый. «Кайда?» – дигән булам. «Теге ябык малай безнең Рафиска охшаган бит», – ди. Үзләрен күреп айнысалар, шәп бит инде.

> Мин авылда яшим. Капка төбендә бөдрә тал үсә, янына эскәмия дә ясап куйдым. Шуңа кич чыгып утыручы яшьләр юк. Егет белән кыз хәзер кайда күрешә икән? Машинададыр инде... Мөгаен, мәхәббәт тә сүрелгәндер хәзер. Ә бит мәхәббәт темасына юмор да бик күп. Ир белән хатын, егет белән кыз, берсе гадәттә җебегәнрәк була. Шундыйларны хәзер уйнап булмый инде. Безнең яшьләр аңламаячак аны.

:: Яшьләр күбрәк «Stand up» жанрын үз итә. Стендаперлар турында нинди җылы сүз әйтерсез?

– «Stand up» начар нәрсә түгел, әгәр эчтәлекле булса. Әле беркөн генә шуны карарга дип махсус бардым. Кеше көлдерер өчен сүгенделәр дә, кыскасы, булдыра алганның барысын да эшләделәр. Ә бит алар яшьләр аудиториясенә эшли. Шуны рәхәтләнеп, «Мунча ташы»ннан да ныграк көлеп карадылар. Чөнки анда оятсызлык, сүгенү. Мин аны кабул итә алмыйм. Андый юморның урыны – мунчада. «Stand up» башкача да була ала. Без аны «Мин – юморист» дигән проектта эшли башлаган идек. Теләктәшлек булмагач, тукталып калды.

Яшерен-батырын түгел, 20 еллап элек безнекеләр дә сүгенә башлаган иде. Үзләрен тотып сүктем. Шактый вакыт узгач, шул малай, ярый әле туктатткансың, дип рәхмәт әйтте.

:: Татар юмористы дигәч, кем күз алдына килеп баса?

– Татарда бөтен театрлар да юморны бик оста куллана. Бусы – күмәк юмор. Ә эстрадага килсәк, Салават Фәтхетдинов һәм Җәвит Шакиров үзләренең программасында юморны оста куллана. Рифат Зарипов җыр арасында юмор сөйләп ала. Бездән кала миниатюра уйнаучы Данир Сабиров бар. Кызганыч, Әбри Хәбриев тә җырга күчте. Репертуар таба алмагач, юмористлар да бетә торгандыр. Язучылар юк. Юморист дигәч, күпләрнең күз алдына калын кашлы Рәшит Шамкай килеп басадыр. Ул да мәрхүм инде. Равил Шәрәфи... Хәзер инде ул да сәхнәдән юмор сөйләми. Якташым Алмаз Хәмзин бар.

:: Театр дигәннән, Казахстанда 6 юмор театры бар, бездә бер «Мунча ташы». Сәбәбе нәрсәдә?

– Казахстан белән без элемтәдә. Нәрсә диим, алар булдыра. 1978 елдан бирле телевидениедә, «Уральские пельмени» шикелле мәгънәле шоу алып баралар. Минем дә телевидениедә шундыйрак тапшыру эшлисем килгән иде, барып чыкмады. Югыйсә татар каналларында юморга кагылышлы бернәрсә дә юк. Ерак китәсе түгел, Башкортстанда да юмористларга кытлык. Анда баргач, безне күтәреп кенә йөртәләр. Халык көлүдән бизмәсен, ә юмор төсмерләргә баесын өчен, радио-телевидение дә шул юнәлештә эшләргә тиеш. Бездә ул юк. Матбугатта да жанр буларак ул күтәрәм хәлендә. Безнең бит тәҗрибә бар, уртаклашырга җай юк. Бездән соң кем кала? Мәктәпләргә барсаң, балаларның да «юморить» итәргә теләге бар. Оештырып эшлисе генә. Сәбәбе, дисең. Аның сәбәбе бездә түгел, без эшләргә әзер. Калганын үзең белешеп бетер инде.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

< Ахыры. Башы 17, 24 март саннарында

– Алинә, син, әлбәттә, боларның барысына да күнеккән. Ә мин биредә фаҗига күрәм. Аңлыйсыңмы мине?

– Аңлыйм да кебек. Тик чебеннәр, башка бөҗәкләрне юксынганда аңламыйм да.

– Әтиең бал кортларының да санаулы, сирәк урыннарда, оазис ише җирләрдә генә калганлыгын әйтте. Мин сиңа шул кортлар хакында бер нәрсә сөйлим хәзер. Андый бөҗәк турында ишеткәнең булдымы?

– Әлбәттә, булды. Бал да авыз иткәнем бар. Файдалы җан иясе икәнен дә беләм. Тик безнең якта алар чыннан да юк шул...

– Ә минем дәвердә күп кеше умарта тота, бал аерта, кортлар болын-кырлардан нектар ташый иде. Кызурак көнне артык иркенәеп, авызыңны ачып йөрсәң, чагып китәргә дә күп сорамыйлар иде. Ни өчен? Чөнки корт цивилизациясе – катып калган тоталитар җәмгыять, анда ирекка дә, гаделлеккә дә урын юк. Умартада абсолют күпчелекне тәшкил иткән эшче кортның гомере – нибары өч-дүрт атна. Ул канаты тузганчы эшли-эшли, нектарны ташый-ташый да үлә, юкка чыга. Ул нәсел калдырырлык итеп тә яратылмаган. Кайткан бални ашап ятучы ана корт, аны аталандыручы сорыкортлар эшләми, ләкин күпкә озаграк яши. Кешеләр арасында андый мөнәсәбәтләр урнаша алмый, тиеш тә түгел, чөнки без гаделлек категорияләре буенча яшибез.

Әмма, шуңа да карамастан, кайбер галимнәр һәм сәясәтчеләр безнең чорда ук инде, кешелек гомерле, әйләнә-тирәгә зарарсыз булсын өчен, аңа да корт оясындагы тоталитарлык кирәк, дигән теория әвәләгәннәр иде. Күңелемә шик төште әле менә: биредә – егерме икенче гасырда, Дөньяви хөкүмәтләр оештыра-оештыра, ул теорияне гамәлгә ашырып

НАИЛ ШӘРИФУЛЛИН

ЯКУТЛАРГА КИТКӘН ВАКЫТЛАР

(ПОВЕСТЬТАН ӨЗЕК)

– Ышанам, булгандыр. Нәрсә сөйләмәкче идең?

– Менә тыңла. Сезнең буын онытып бетергән диннәр, шуларның берсе – ислам дине кануннарын билгеләгән, кешене дөрес яшәргә өндәгән изге Коръән китабында, сүрә дип аталган бүлекләрнең берсендә: «Бал кортларына һичкем дәрес бирә алмас, ләкин кешеләргә бал кортларыннан дәрес алу ләзем», – дигән мәгънә, сүзләр бар. Бик тә дөрес сүзләр. Корт гаиләсе – табигать салган программа-инстинкт буенча, табигатькә бары файда гына китереп яшәүче үтә дә камил организм. Алар яшәешенең төп максаты, бал җыюдан да бигрәк, үсемлекләрне серкәләндерү. Ул эш башкарылмаса, үсемлек орлык яисә җимеш бирми – кеше рационына кергән күп төрле ризыклар юкка чыга. Биредә, сезне урап алган тирәлектә мин нәкъ шул сурәтне күрәм. Алдыгыздагы ризыклар йә ясалма, йә читтән китерелгән, биредә үсмәгән. Әлбәттә, бу хәлдә беренче сәбәп булып Җирнең җылынуы тора. Әмма һава торышы, климат үзгәрүне иң әүвәл кортлар сизә, беренче булып алар юкка чыга. Хәл үзгәрмәсә, бераздан сез оазис дип атаган урыннар да калмаска мөмкин бит. Нәрсә ашарга, ничек яшәргә җыенасыз?

– Зөфәр, төсләрне артык куертмыйсыңмы? Мин барысын да белмим, бу – егерме икенче гасыр, үсемлекләрне серкәләндерүнең башка юлын, әмәлен тапканнардыр, балның да табигыйдан ким булмаган ясалмасын күптән җитештерәләрдер.

Кыз беренче тапкыр аңа исеме белән дәште. Бу хәл Зөфәрнең йөрәгенә сары май булып ятты. Ул инде аныкы төсле исемнәр кулланыштан төшеп калгандыр да, кыз ят исемне оныткандыр дип уйларга да өлгергән иде. Алай түгел икән бит. Шунлыктан җавапның да соңгы җөмләсен генә ишетте кебек.

– Чын балны ясалмасы беркайчан да алыштыра алмый, күпме тырышма, бары суррогат кына килеп чыга. Әйтәсе килгәнемне әйтеп бетермәдем. Бал кортларына кайтканда, алар чыннан да дәрескә, өйрәтүгә мохтаҗ түгел – Изге китап дөрес әйтә. Тик кешеләр алардан дәрес ала, алар цивилизациясе кануннары буенча яши алмый дип уйлыйм. Кайберәүләр мөмкин ятмыйсызмы? Яткан очракта инде бөтенләй соңга калмадыгызмы? Табигатькә салынган зыян артык масштаблы: шаулап иген үсә торган күз күреме җирләр мүкка тартым сәер кәләм астында пошлызып ята. Болары – беренчедән...

– Аңладым. Бер, ике гасыр элек кенә дөрес яшәгәннәр, хәзер исә без кыек юлга кереп киткәнбез, гөнаһка батканбыз...

– Элекке вакытларда да тормыш хилафлы юлдан барган. Табигатькә, тереклек ияләренә, аның аша үзенә, үз токымнарына зыян салыр мөмкинлеге генә булмаган адәми затның. Салганда да күпкә азрак салган. Моннан унҗиде-унсигез гасыр элек үк яшәгән Хозер Августин дигән кеше: «Аллаһы тудырган дөнья камил. Бар начарлык та – кешедән», – димәс иде.

Алинәнең төртмәле сүзенә егет шулай тыныч кына, үзенчә дәлилле итеп җавап бирде.

– Ә икенчедән?

– Икенчедән, Табигать-ана, ягъни эволюция барлыкка китергән диктатура белән кеше төзегән диктатура арасында аерма ифрат та зур. Кешелек бары яңа «сорыкорт»лар хакимияте – башкалар хисабына яшәп, башкалар өстендә торган юньсез режим барлыкка китерергә генә сәләтле. Андый системадан табигатькә дә, халыкларга да, бәндәгә дә файда юк. Анда, биредәге кебек, чәчәкләр дә бары клумбаларда гына үсә. Табигать бар иткән диктатура гына дөрес, ул гына хаҗәт: бал кортлары Җирдә инде дистә миллион еллар оча. Ә кешелекнең кичкән гомере әлегә, күп булганда, сигез-ун мең ел. Ул үзен homo sapiens, ягъни аңлы зат дип атый. Әйе, ул аңлы. Аның хәтере, хис-кичерешләре бар, ул нәтиҗәләр ясый, чыгара белә. Тик ул үз ягына гына аңлы. Аңлы, тик акыллы түгел. Кайбер шартлар булганда гына акылга сәләтле. Тик андый шартларны «материалист»лар – матди якны гына кайгыртканнар тудыра алмый. – Зөфәр шул урында туктап калды. Һәм биш-алты адым үтүгә, озакка киткән җитдилектән качып, йөзенә үзенә хас көләч елмаю кайтарды да сүзне уенга борасы итте:

– Башкаларга ышанмаганда да, миңа – йөз дә унбиш яшьлек аксакал сүзенә син ышанырга тиеш.

– Бәяңне күтәрмә инде ул кадәр. Биредә син минем яшьтәш. Сөйкемле генә түгел, бик гыйлемле, акыллы да күренәсең. Соңрак кай якларың белән ачылырсың тагын? – Алинә аның шаяртуын аңлады һәм кабул итте. Егет әле башкаы да аңлады. Әти кешедә дә, аның кызында да, шушы коточкыч үзгәрешләр кичергән дөньяда яшәүгә дә карамастан, яхшыны аңлау, аны начардан аеру, сиземләү сәләте, хәтта милли аң да, бик гаҗәп тоелса да, калган, бар кебек иде...

Санаулы вакыт тиз үтә. Алар янәшә атлаган, Алинә, аның җылы мөнәсәбәте, гүзәллеге, ихлас әңгәмәдәш булуы аркасында хәзер инде алай ук чит-ят тоелмаган кичке авыл урамнары, инеш суының салмак чылтыравы, егет белән кызның озакка сузылган, төрледән-төрле темаларга кереп киткән әңгәмәләре дә аргта калды. Гадәти булмаган сәяхәтнең азагы якынлашканын искәртеп, егерме икенче гасырның яңа көне туды. Аның беренче сәгатьләре узып, Зөфәрләр дәверендәгедән бер дә аерылмаган, шундый ук якты да, кайнар да булган кояш шактый гына күтәрелергә өлгерде. Кунакка юлга җыена башлар чак җитте. Ул үзе белгән, алар «вакыт порталы» дип атаган, кичә килеп төшкән урынга, үзе билгеләп калдырган квадратка барып басарга тиеш иде.

– Без алынган проект ашык-пошык эшләнә торган гамәл түгел. Эш әле елларга сузылачак. Шунлыктан биредәге чынбарлык та тиз генә үзгәрмәс. Ничек яшәгән булсагыз, шулай яшәячәксез. Син дә әле хәтсезгә бүгенге Алинә булып калачаксың. Барысы да без дигәнчә барса, мин озакка сузмый гына тагын бирегә килеп чыгарга тырышырмын. Мине көтәрсеңме?

Кыз дәшмәде. Аның күзләрендә моңсулык иде. Ул күзләрен күтәреп, керфекләрен бер дә какмыйча, озак кына егеткә карап торды да башын үзенә каршы торган Зөфәрнең башына терәде. Алинә җавабын шул рәвешле бирде.

– Сине тәмам туйдырганчы, йә булмаса үзебезнең чорга урлап киткәнче аллы-артлы хәтсез йөрермен әле мин... – Зөфәр, үзендәге элекке гадәтне куып, киеренкелекне җиңәсе килеп, шаяртып алды.

– Икенче килгәндә озаккарак килергә тырыша күр, яме.

– Әлбәттә! Күчешләрнең куркынычсызлыгына тәмам инансак, сине үзебезнең чорга кунакка чакырсам, барырсыңмы, Алинә?

– Башта әйләнеп кил әле. Аннан соң сөйләшербез...

Бу кыска диалог ахырына алар инде тагын нәкъ кичәге кичтәге кебек, капмакаршы басып, күзләр томырылып күзгә баккан, куллар кулга тотынган хәлдә торалар иде. Шул мәлдә Зөфәрнең күңелен аңлашылмас кичереш билән алды. Әле кичә кенә кайтып, кургәннәрен сөйләргә, бар дөньяга кычкырырга ашкынган егетнең бу минутларда биредән китәсе бер дә килми иде. «Һич югы тагын бер генә тәүлеккә ничек каласы соң?» Тик бу мөмкин түгел иде. Аның бары бөтенләйгә калу мөмкинлеге генә бар. Вакыт коридорына эләгү өчен билгеләнгән ноктага билгеле минутта, хәтта секундта барып басу мөһим. Монда калганда алар миссиясе уңышсызлыкка юлыгырга, хәтта ябылырга да мөмкин. Проектны шик астына кую һич мөмкин түгел. Калу – аңа ышанган, аны монда җибәргән кешеләргә хыянәт.

Егет артына соңгы тапкыр әйләнеп карады да адымын кызулатты. Күңеленә уелып калган сурәтнең кире бирегә әйләнеп кайтканчы сакланачагын, күз алдында торачагын Зөфәр белә иде инде. Ул сурәттә өстенә сары җирлеккә ак чәчәкләр төшерелгән күлмәк кигән зифа буйлы гүзәл кыз, җил тараткан чәчләрен бер кулы белән тотып, икенче кулын аңа тыйнак кына итеп болгый иде...

Шигърият

Сания ӘХМӘТҖАНОВА

ХАЛӘТ

Очам диеп күтәрелгән кошның,
Тотып, канатларын кистеләр...
Кемнәр диген – күккә меналмаган,
Очалмаган түбән хисләләр.

Бәгыренә туңнар булып катты
Әйталмаган рәнҗү-каргышы.
Көнләшерлек иде аның җыры –
Шушы булды иң зур «ялгыш»ы. <...>

Тынмасмы дип әрнү-сызлануы,
Үзен үзе кошым юатты.
Үзәк өзгеч моңлы җырын җырлап,
Үзе кебекләрне елатты.

Сайрар урыны күктә булмаса да,
Җаны мәңге түбән буламас.
Канатларын кисеп атсалар да,
Җырын беркем тартып алалмас.

(«Җырчы кош» шигыреннән)

КЕШЕ ХАКЫ

Күрше хакы – Алла хакы, дибез,
Кеше хакы йөри нинди хакка?
Кадерсезгә калганымны тоям,
Сукбай эттәй җан улаган чакта.

Читләштек без никтер якыннардан,
Күршеләрдән биздек акрын-акрын.
Балтырганга батырдык без илне,
Таптап йөреп читтә юл такырын.

Кайтсаң – кунак, китсәң – ерак, диеп,
Без ул туган йортны атап йөрткән!
«Күрше хакы – Алла хакы» сүзен
Онытдык та бугай инде күптән.

«Җир бәгыре, су кадере» диеп
Әйтер микән без үстергән буын?!
Туфрак арчып татып карамагач,
Җирдән кайнап чыккан чишмә суын.

Түбән төште ил абруе-даны,
Очсызланды аксакаллар сүзе.
Яшәү хакын даулап, ни кырабыз,
Якалаган чакта үлем үзе?!

Аңлый белсәң, «гомер» дигән юлның
Газиз икән хәтта карышы да.
Сулар сулышка да бәя арта
«Яшәү» белән «үлем» ярышында.

Олыгая бу да, дисез булыр,
Хаклык бардыр, яшьне санап баксаң.
...Уйдык-уйдык уйлар сара җанны,
«Төннек» аша күккә карап ятсаң,
Иртәгегә нәүмиз караш атсаң...

КЕШЕ БУЛЫП!

«Бу галәмдә без бик кечкенә шул,
Ә яшисе килә зур булып...»

Кадыйр Сибгатуллин

Күз карашым «укый» әңгәмәдәш,
Шикләнгәндәй: дусмы, «дошман»мы?
Әллә үз фикере ми сырыдна,
Әллә сөйли «зур»лар кушканны?

Сүзен үлчәп кенә ычкындыра,
Юкса мине сатлык саныймы?
«Син хаклы», – дип, бармак төбәвеме,
Әллә әләк белән яныймы?

Аңлашабыз санлашмыйча гына,
Җитте бигрәк сәер замана.
«Айт» дигәнгә, «тайт» дип җавап бирсәң,
Бик тә килеп тора таманга.

«Олы»ларның сүзе һәрчак өстен,
«Кече»ләргә каршы дәшмисе!
...Бу дөньяда зур йә кече түгел,
Кеше булып килә яшисе!

30 ЯШЕҢӘ
булырга тиеш

- «ВКонтакте»да ташландык аккаунт.
- Элеккеге эшләреңнән берничә пропуск.
- Кулланмый торган электрон акчада калган 50 сум.
- Өстәлеңнең беренче тартмасында буталган төрле чыбыклар.
- Гел сине каядыр сулга өстерәүче иске дустың.
- Флешкада папкалар буенча бүленмәгән меңләгән фото.
- Һава торышы үзгәрүен сизүче аяк-буыннар.

Әз-мәз мәзәк

Кеше 25 яшькә кадәр үсә. Вертикаль буенча. 25 яшьтән соң горизонталь буенча үсә башлый.

* * *

– Эшләүчеләрне саклагыз. Аларны югалтсак, тикшерүчеләр һәм контрольдә тотучылар гына калачак.

* * *

– Мин хатыныма алтын алка бүләк иттем. Ә ул минем белән инде икенче атнасын сөйләшми.
– Ник?
– Бүләгемнең шарты шул иде.

Бәхеткә омтылырга түгел, ә үзеңне бәхетле хис итә белүгә омтылырга кирәк!

Сканворд җаваплары

Горизонталь: сырганак, Акчарлак, батыр, гомер, Марс, Елас, Идегәй, Антарктида, Болгар, ВИА, еш, мавр, Азат, Днепр, оя, чи, Ра, Янковский, илә, шар, Рәйхана, Иләбәр, Нәсим, Бәкер, өс, Рәйсә, Диләвер, Иттифак.

Вертикаль: Сафиуллина, Чирмешән, Диля, чебен, әй, Гошер, мәл, паша, айгыр, Ан, айбагар, яран, бөре, Сарман, әсәр, ятим, корсак, егет, Си, карар, Лавров, мөртәт, Ари, ясли, СКА, Алинә, Нияз, җә, кабартма, тай, Рафилә.

КАТНАШ АЗЫК, АШЛЫК

ФИНИШ БРОЙЛЕРЫ өчен

(26 көнлек һәм аннан зуррак бройлерлар өчен)

КАТНАШ АЗЫК

Глазов һәм Богданович шәһәрләре заводларында җитештерелгән терлек азыгын (бройлерлар, йомырка салучы тавыклар, бытбылдыклар, йорт куяннары, мөгезле эре терлек, күркәләр өчен), шулай ук аертылмаган сөтне алыштыручы ризык, мөгезле эре терлек өчен тоз һ.б. сайлап алу мөмкинлеге зур.

Казан, Техническая урамы, 15. **тел.: +792-704-99-706**

Чаллы, Магистральная урамы, 1а/1. **тел.: +792-767-27-366**

** сыер рәсеме төшерелгән сары баннерны эзләгез!*

Безнең сайт: agroline1.ru

реклама

Этиәнисе

Татар облепихасы

Габделфәт газетасы

Кеше тормышы

Сабантуй герое

Көнбагыш

... Макаров

Рәис иҗат җимеше

Оча торган ачу китергеч

Зәкятнең бер төре

Аның сүзе бер була

Мари Иле авылы

Татар ризыгы

Дастан

Югары даими лекле

Зәянең мәсәлман абыйсы

Уен кораллы ансамбль

Хоккей клубы

Җир шарының көньягындагы континент

Мизгел

... Нигъмәтуллина

Фарсы титулы

Ат

Нәниләр балалар бакчасы

РФ өчен уйнаган Бразилия футболчысы

Пешмәгән

Украинада елга

Татарстан районы

Африкадагы халык вәкиле

Кошлар йорты

Тимершәех

Башыңа ул типте мәллә?

Белән

Кояш Алласы

Очкыч

Актер Олег ...

... син, картлык, тимә әнигә!

Һавалы бәйрәм түгәрәге

Ашагач кабара

Тычкы эшләр министры

Саба районы авылы

«Ә» диңгенә әйтәләр

Аш-су блогеры Шәмсетдинова

Татар хатын-кыз исеме

Үз дине нә хыянәт итүче

Булачак яфрак

Гөл

Әдәби язма

Шәп шифаханә

Асныл арьгы

Язучы ... Ишморатова

Аксубай күршесе

Кытай илбашы

Язучы ... Османов

Ильяс Гаффаров рок төркеме

Беләсең килсә...

1 «Бишенче республика» дип кайсы илне атыйлар?
а) Франция;
б) Австрия;
в) Польша.

2 Булат Окуджаваның балачак кушаматы нинди булган?
а) Бүре;
б) Балык;
в) Күке.

3 Бу илдә атна 8 көннән тора, чөнки чәршәмбеләре икегә бүленгән:
а) Камбоджа;
б) Мьянма;
в) Уругвай.

4 Сталинның улы Василий Джугашвили Казанда кайсы урамда яшәгән?
а) Пушкин;
б) Гагарин;
в) Свердлов.

Җаваплар: 1. а); 2. в); 3. б); 4. б).

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 15281 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 245

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+